1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2019 ДЕКАБРЬ № 12

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ИР-АТ – МАНИКЮР ОСТАСЫ
эшнең ертыгы юк

ОБЪЕКТИВ АША КАРАШ
фотограф күзәтүләре

ЯҢА ЕЛ ТАБЫНЫ
тутырган бытбылдык

Лилия МУЛЛАХМӘТОВА:

МАТУРЛЫК КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕННӘН БАШЛАНА

PRESSA



СӨЕМБИКӘ







ГЫЙНВАР

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	31
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

ФЕВРАЛЬ

	3	10	17	24
	4	11	18	25
	5	12	19	26
	6	13	20	27
	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	

МАРТ

	2	9	16	23	30
	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	

ИЮЛЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	31
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

АВГУСТ

	3	10	17	24	31
	4	11	18	25	
	5	12	19	26	
	6	13	20	27	
	7	14	21	28	
1	8	15	22	29	
2	9	16	23	30	

СЕНТЯБРЬ

	7	14	21	28
1	8	15	22	29
2	9	16	23	30
3	10	17	24	
4	11	18	25	
5	12	19	26	
6	13	20	27	

Ренессанс
Антикварный салон
www.antik-renessans.ru
antiksalon
РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Лилия Муллахмәтова
Фото: Анна Арахамия

Лилия Муллахмәтова өстендә «Александр Богданов» бренды киемнәре.

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 9.12.2019 ел.
Заказ О-3421
Тираж 5015

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир сүзе





Кадерле укучым!

Журналыбыз сезгә килеп ирешкәндә бөтен дөнья Яңа елны каршылау дулкынына күчеп, бәйрәмгә әзерләнү мәшәкатьләре белән кайнап торачак инде.

Беркөнне бу санныбызга фото төшерү өчен Кремль буйлап барганда, фотографыбыз Аня, борчылып: «Монда Кыш бабайга язылган хатларны җыю өчен почта тартмасы эленеп торды. Малайларым язган хатны мин дә салган идем. Безнекеләр, әлбәттә, рус телендә инде... Ничек уйлыйсыз, Кыш бабай кире бормас микән?» – диде. «Аңлар, ул бит толерант безнең», – дип тынычландырдым аны... Әйе, Яңа ел алдыннан барыбыз да могҗиза көтә. Дөрес, еллар узган саен, кешеләрдә могҗизага ышану кими, яхшылыкка өмет кенә кала кебек. Әмма барыбер... Ул могҗизаны башта балачакта безгә әти-әни бүләк итә, аннары инде балаларыбыз өчен без аны үзебез тудырабыз: балалардан Кыш бабайга хат яздыру, эштән соң кибеттән кибеткә чабып (дөрес, хәзер әти-әниләргә могҗиза тудыру шактый җиңеләйде – интернет-кибетләрдә барысын да табып була) бүләк эзләү, балалар күрмәгәндә ул бүләкләрне чыршы астына урнаштыру... Соңрак аларның ихластан сөенүен күзәтеп, үзебез бәхет дулкынында йөзәбез... Һәм балаларыбызның ул әкияткә мөмкин булганча озаграк ышануларын телибез...

Олы кызыбыз Кыш бабайны шактый озак чынга санады, ә менә кечкенәсе әкият белән иртәрәк саубуллашты. Тугыз-ун яшьләр булгандыр. Өйдә инде чыршылар куеп, бәйрәм көткән вакыт. Без әтисе белән телевизор карап утырганда, кызыбыз яныбыздан узып китте һәм Кыш бабайга язган хатын «ялгыш кына» төшереп калдырды... Ул бүлмәдән чыккач, тапкырлыгыннан көлдек рәхәтләнеп. «Кыш бабай юклыгын беләм, әмма сездән барыбер бүләк көтәм», – диюе булды бит. Ләкин моңсуланып та куйдык. Димәк, кечкенә кызыбыз өчен дә әкият тәмамланды...

...Бу санныбыз – узып баручы елда сезнең белән соңгы очрашуыбыз. Алдагы елларда да бергә булыйк! Ә иске елны озатып, яңа елга аяк басканда теләкләребезне икеләнмичә телик. Хәтта могҗизага тиң булырлыкларын да!

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Безнең тышлыкта



«Эш дип әйтәсем дә килми, бу бит иҗат! Пациентлар күзендәге очкынны яратам! Алар атлап бармый, оча бит андый чакта!»

12 Матурлык – күңел халәте
Гөлнур Сафиуллина

Заман һәм без



6 Вакыт җиткән, күрәсең...
Мәдинә Авзалова



16 Асыл иргә бар да килешә
Чулпан Галиәхмәтова

Тар сукмактан – зур юлга 20
Лилия Гәрәева

24 Объектив аша... яки Фотографның күргәннәре
Раилә Хәялиева

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы




28
Бердәнбер
Гөлнур Хәсәншина

Мәдәни тормыш

34
Кремль... Борынгы, балкышлы, безнеке!
Эльмира Закирова





44
Театрга билет
Раилә Сабирова

Яшәеш

48
Ватык пыяла өстеннән...
Мәдинә Авзалова



52
Миллионерлар янәшәсендә
Гөлнур Сафиуллина

Хуҗабикә

58



Яңа ел табынына – бытбылдык



60
Рәхим ит, Яңа ел!



ВАКЫТ ҖИТКӘН, КҮРӘСЕҢ...

Дәүләт Думасы депутатлары залим ирләргә карата яңа закон проектын карауга керештеләр. Кайта-кайта каралган бу мәсьәләгә нокта куярга кирәктер. Әледән-әле булып торган сискәндергеч мисаллар шул хакта сөйли.

«Законның кирәклеге бәхәссез»

Әлбәттә, гаиләдәге җәбер-золым дигәндә, без залим иренең йодрыгы астында яшәгән хатын-кызны гына күз алдына китермибез. Ул сексуаль характерда да, икътисадый якка да бәйле булырга, шәхеснең эчке дөньясын җимерә торган психологик рәвеш алырга да мөмкин. Шуңа күрә аның корбаннары да төрле. Мисаллармы? Алар җитәрлек. Татарстанда Кеше хокуклары яклау буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Харис кызы САБУРСКАЯ алдыма шуны дәлилләүче бер өем кәгазь китереп куя. Андагы хәбәрләргә күз төшерә-төшерә, вәкаләтле вәкил белән көн тәртибенә килеп баскан җитдидән-җитди темага гәп куертабыз. Мондый хәлләр белән ул көн саен, сәгать саен очрашып тора.

Сәрия Харисовна, гаиләдәге җәбер-золымны кисәтү чараларын закон кысаларына кертергә кирәклеге турында беренче генә әйтмибез. 2016 елда бу закон проекты хәтта беренче укылышка да куелмады. Һәм менә тагын... тагын иске яңалык. Кирәкме ул безгә дигән сорауны бирмим. Кирәк! Ләкин нинди формада булырга тиеш ул? Чөнки бу законга аяк терәп торучылар, кискен каршы чыгучылар да шактый бит. Дәүләт органнары, әйтик, шул ук полиция гаилә эшенә кирәгеннән артык тыкшынмасмы, вазгыятьне тагын да катлауландырмасмы, дип шикләнүчеләр дә юк түгел.

– Дөресен әйткәндә, бу мәсьәләнең көн үзәгеннән төшкәне дә булмады. Ирләрнең хатын-кызга, кызларга карата физик, психологик һәм сексуаль һөҗүме, залимлык кылуы корбан булучыга гына түгел, туганнарына, якыннарына, танышларына, алай гына да түгел, һәрберебезгә әйтеп бетергесез җан тетрәнүләре китерә. Үзебез, ир белән хатын-кыз тигез хокуклы, дип сөйлибез. Ә тормышта?.. Законның кирәклеге бәхәссез. Ни өчен дигәндә, җәбер-золым очраклары бар һәм алга таба да булачак. Бер безнең илнең генә проблемасы түгел бу. Башка илләрдә дә шулай. Ә бәлкем, кискенрәктер дә әле.

Дәүләт Думасы тыңлауларында экспертлар: «Кыйнады дип гариза биргән ун зыян күрүченең алтысы, ә кайчак сигезе гаризасын кире ала», – дип белдерде. Шуңа күрә полиция хезмәткәрләре мөрәҗәгатьләрнең 56 процентын гына терки ала. Ягъни чынбарлык пәрдә артында кала.

«Саклангнны саклар өчен»

Чит илләрдә инде күптән хатынын кыерсыткан ирне аңа якын җибәрмиләр. Ә бездә алар, аерылышкан очракта да, бер фатирда – икесе ике бүлмәдә яшәргә мәҗбүр.

– Әлеге закон проекты агрессорларга үз корбанына якын килүне тыя торган «саклагыч ордер» бирүне күз алдында тота. Ул ничек эшләр? Әйтүе кыен. Ордерны җәбер-золым корбаны булган хатын-кызга хокук саклау органнары һәм суд бирә. Мондый документ, әйткәнемчә, агрессорга корбанына якын килүне тыя. Дәүләт мондый хәлгә төшүчеләрне вакытлыча яшәп тору урыны белән дә тәэмин итәчәк. Монысы да бүгенге көндә зур проблема бит әле.

> Татарстанда хәйрия фонды ярдәмендә барлыкка килгән кризис үзәкләре җәбер-золым астында яшәгән **хатын-кыз өчен зур терәк ул.**

Күптән түгел генә Швециядә – Стокгольмда булып кайттым. Баруымның максаты – бу илнең гаиләдә хатын-кызны җәберләүгә каршы көрәшне көчәйтүгә юнәлдерелгән законнары, сәяси чаралары, программалары белән танышу иде. Без шулай ук зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү хезмәтенең эшчәнлеге, Швециянең бу өлкәдә тупланган тәҗрибәсе белән дә таныштык. Бу мәсьәләдә аларның үз көрәш стратегиясе бар. Һәм ул безгә сабак булырдай, бик гыйбрәтле. Стратегия дүрт максатны күз алдында тота: җәбер-золымны нәтиҗәле кисәтү чаралары; аны барлау һәм шуңа дучар булучыларны яклау; җинаятьчелеккә каршы кискен көрәш; белемне яхшырту һәм методик эшләнмәләр булдыру. Миңа калса, соңгысы безнең өчен аеруча мөһим. Тагын бер мөһим нәрсә: бу илдә гаризаны кире алу гадәте юк, чөнки закон рөхсәт итми. Аларда бу нәүбәттән махсус программа эшли. Ә безнең хатын-кызлар гариза бирәләр дә шундук кайтып төшәләр. Швециянең югары уку йортларында сигез төр белгечлек буенча укыталар. Өстәмә рәвештә психология фәннәре һәм социаль хезмәткәр өчен кирәкле һөнәр дә бирелә. Кызганыч, үткәрелә торган әлеге чаралар да, законнарның кырыс һәм катгый куелуы да залимлык кылу очракларын киметми.

Гаилә кыйммәтләре турында – балаларга

Ни өчен дип уйлыйсыз? Баштарак уйларга кирәк булмаганмы безгә? Нинди генә законнар, программалар кабул итмә, гаиләдә бала тәрбияләүгә тиешле игътибар булмаса, боларның барысы да бер мизгелдә чәлпәрәмә килергә мөмкин бит.

– Нәкъ шулай. Әйтәсе килгәнем дә шул. Без һаман: «Гаилә ул – дәүләтнең бер ячейкасы. Гаилә ул – үзе бер кечкенә дәүләт», – дип кабатларга яратабыз. Бу – шулай. Ул, чыннан да – үз законнары, үз кагыйдәләре, үз яшәү рәвеше, үз тормыш кыйммәтләре булган дәүләт. Һәркайсы бер нәни дәүләт. Бала-чага әти-әнисенең, әби-бабасының кем булуын, кайда укыганын, кем булып эшләгәнен белергә, гаилә гореф-гадәтләрен күз карасыдай сакларга тиеш. Әгәр дә ул әтисенең әнисен кыйнавын, йә булмаса

Фото: Анна Арахамия

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

«Оясында ни күрсә...» дибез. Бала нинди шартларда үсә бит, ни күреп үсә бит... Барысы да үзебездән тора.

үзенең җәберләнүен күреп-кичереп үсә икән, үсеп җиткәч, ул аны инде үзе кемгәдер карата кабатлаячак, әтисе йә әнисе кулланган кыерсыту алымнарын кулланачак. Барысы да гаиләдән, тәрбиядән башлана. Аннан соң инде син нинди генә законнар кулланып карама, нәтиҗәсе ташка үлчим була. Ул бәләкәй дәүләт һәркайсыбыз өчен мәҗбүри булган гомуми законнарга, кагыйдәләргә буйсынырга, шулар ярдәмендә эш итәргә тиеш, дип әйтүем. Карагыз индениләр бар бүген дөньяда?! Кемдер хатынын кыйнап үтерә, кемдер баласын, үзенең йөрәк парәсен йозак астында – тоткында тота. Кайсыдыр ир үз баласын көчли. Гомер буе ир йодрыгы астында изелеп яшәгән хатыннар бар. Ни дип түзәләрдер?! Шуларны ишетәсең дә, хәлиткеч-кискен чаралар кирәклегенә тагын бер кат инанасың. Без бу эшләрнең кайсын – балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссияләренә, кайсын опека һәм иганәчелек органнарына җибәрәбез. Һәм, әлбәттә инде, җитди контрольгә алабыз.

Швециянең гаиләдә ирексезләү-көчләүләргә каршы стратегиясе турында сөйләгәндә, «соңгысы безнең өчен аеруча мөһим», дидегез. Татарстанда бу уңайдан ниләр эшләнә, нинди милли проектлар гамәлдә? Аеруча уңышлы дип фаразланганы арасыннан кайсын атый аласыз?

– 2012–2013 елларда Мирный бистәсендә урнашкан 129 нчы рус-татар мәктәбе һәм Казан шәһәренең 93 нче гимназиясе базасында укучыларны гаилә мәсьәләләре белән якыннан таныштыру максатыннан «Семьеведение» программасын кертү инициативасы белән чыккан идек. Гаилә нигезләрен өйрәнү барышында унынчы сыйныф укучылары белән уздырылган сораштырулар балаларның гаилә турындагы төшенчәне бөтенләй башка итеп күз алдына китерүләрен күрсәтте. Гаилә тулы булырга, һәркем – әти дә, әни дә гаиләне алып баруда бертигез җаваплы булырга тиешлеген аңладылар. Әлеге программа үзенең тормышчан, бик тә кирәкле булуын күрсәтте. Хәзер аны Россиянең Мәгариф Академиясе илнең башка белем бирү учреждениеләрендә дә куллану турында сүз алып бара. Ә бүген исә безнең республикада бу программа буенча 1500 дән артык кеше белем алды инде. Алар арасында балалар бакчасында эшләүчеләр дә, техникум һәм мәктәпләрдә укытучылар да бар.

Милли проектлар турында сөйли башлаганбыз икән, шунысын да әйтим: без әледән-әле халыкның сәламәтлеген саклауга һәм коммуналь-торак хуҗалыгы эшчәнлегенә кагылышлы видеоконференцияләр уздырып торабыз. Табибта булып кайткан пациентлар түбәндәге сорауларга җавап бирергә тиешләр: табибка керергә озак көттегезме, регистратура хезмәткәрләре һәм шифакать туташларының мөнәсәбәте нинди, табиб ничек карый? Сораштыручыларның күбесе чиратлардан зарлана. Халыктан кабул ителгән шикаятьләрне без чара күрү өчен тиешле органнарга җибәрәбез. Болары сүз уңаеннан гына...

Кризис үзәкләрен – зур шәһәрләрдә

Күптән түгел генә Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» берләшмәсе депутатлары белән берлектә «Хатын-кыз игътибары» дигән «кайнар элемтә» үткәрүегез дә әлеге теманың ни җитди булуын күрсәтүче мисал. Ниләрдән зарланалар? Нәрсәгә мохтаҗ кыерсытылган хатын-кызлар?

– Уңышсыз гаиләләрдәге хәлне кисәтү һәм килеп чыккан низагларны көйләү мәсьәләләре буенча быел ике мәртәбә үткәрелде инде ул кайнар элемтә. Биредә сүз ата-ананың бала тәрбияләүгә салкын карашы, кемнәрнеңдер тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган ситуацияләр турында бара. Телефоннан сөйләшкәндә әйтелгән бер генә үтенеч тә кире кагылмый. Без аерым да, «Мәрхәмәт» берләшмәсе депутатлары белән дә эшлибез. Үзебезнең тәкъдимнәрне дә кертәбез. Бездән конкрет ярдәм көтәләр. Һәм без аны озакка сузмыйча, конкрет булышырга да тиеш. Депутатлар белән берлектә алып барыла торган быелгы эш планына җәбер-золым күрүчеләргә бушлай юридик ярдәм күрсәтү; хатын-кызның хезмәт хокукларын саклау; «мин – әни» акциясендә йөкле әниләргә, яшь әниләргә баланы бакчага урнаштыру, сөт кухнясы белән тәэмин итү һәм башка мәсьәләләрдә булышу; яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшырту; «Хатын-кыз сәламәтлеге» турында кайгырту чараларын кертергә тәкъдим иттек. Соңгы тема буенча «кайнар элемтә» вакытында 124 кеше (?!) шалтыратты. Алынган мәгълүматлар шундук полиция бүлекләренә җиткерелә. Менә инде ничәнче мәртәбә битараф булмаган гражданнар бала тудыру йортлары каршында бэби-бокслар урнаштыру мәсьәләсен күтәрә. Караучысыз калган бәбиләр турында да күп шалтыраталар. Әйтәм ич, җәберзолымны хатын-кыз гына түгел, яңа туган гөнаһсыз сабыйлар да кичерә.

Мөрәҗәгать итүчеләр кризис үзәкләрен белешә, кайда психологик ярдәм алырга мөмкин булуы белән кызыксына. Чаллыдан шалтыратучылар шәһәрдә кризис үзәге оештыру кирәклеген әйтте. Алиментлардан качып йөрүче ирләр турында да сүз булды. Һәммәсен телефон аша җиткерделәр. Ә менә язма мөрәҗәгатьләр санаулы гына. Кызганыч, гаиләдәге мондый хәлләр турында бик сирәге генә дөньяга чыгарырга әзер. Бу тема тирәнгә яшерелгән. Ул бездә генә түгел, бөтен дөньясында шулай. Һәм бөтен проблема шуңа

килеп төртелә аннары. Кыерсытылган хатын-кызлар хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә курка. Шунда бармас өчен мең сәбәп табалар. Кемдер өйдәге ызгыш-талашларны, кыйналып яшәүләрне җинаять дип санамый. Иң мөһиме – кеше белмәсен. Ире аны башка кыйнамас, шуның белән бетәр дип өметләнүчеләр бар. Аннары... ул бит әле балаларының әтисе дә... Үз-үзеңне алдау бу. Мондый очракта үзең турында гына түгел, иң беренче чиратта балаларың турында уйларга кирәк. Әйе, килешәм, республиканың зур шәһәрләрендә, әйтик, Чаллыда, Түбән Камада, Алабугада, Әлмәттә кризис үзәкләре ачарга кирәк. Шунсыз булмый. Җәберләнгән һәр хатын-кыз Казанга чыгып йөгерә алмый бит инде. Әле Казанда да әллә ни күп түгел алар. Элек «Фатыйма» кризис үзәге бар иде. Хәзер ул да психологик ярдәм генә күрсәтә. Вакытлыча сыендырып тору үзәкләре мәчетләр, чиркәүләр каршында эшли. «Умиление» үзәге дә уңышлы гына эшләп килә. Аларның һәркайсы хәйрия фонды исәбенә яши. Дәүләт структурасына караган үзәкләр юк.

Югалып калмаска...

Хатын-кызга залим корбаны булуын ничек расларга? Юридик яктан моны проблема итеп санамыйлар ич, аерым бер кешенең гаепләве итеп кенә кабул итәләр.

– Иң элек югалып калмаска... Үтәр әле димәскә. Үтми ул. Бер суккан – гел суга. Шундук полициягә яки мировой судьяга мөрәҗәгать итәргә, кыйналуы турында гариза язарга кирәк. Ә аңа кадәр травматология пунктына барып белешмә алу зарур. Төрле документлар җыю, бигрәк тә адвокат яллау андый хатын-кызның хәленнән килми дә әле ул. Шул сәбәпле, эшләрнең судка кадәр барып җиткәне бик сирәк була. Моңарчы бит Россия законнарында «гаиләдә җәбер-золым» дигән аңлатма юк иде. Хәзер дә яңа законның концепциясе элеккечә калачак. Әмма аның норматив актлары иң беренче чиратта җинаятьне кисәтүгә юнәлдерелгән. Хатыннарына кул күтәрергә яратучыларның җинаять җаваплылыгына тартылуын, ирегеннән мәхрүм ителүен дә искәртик. Закон проектының иң зур яңалыгы – залим корбанына якын килә алмаячак. Югыйсә эзәрлекләү дигән нәрсә дә бар бит. Ирләр качып киткән хатыннарын хәтта кризис үзәкләреннән эзләп таба. Шунда да тынычлык бирми. Бер сүз белән әйткәндә, барысы да хатын-кызның үзеннән тора. Ә законнар бүген – алар ягында!

Әңгәмәдәш – Мәдинә АВЗАЛОВА.

2019: СОКЛАНДЫРДЫЛАР!

Октябрь аенда Американың Сан-Франциско шәһәрендә бөтен дөнья күләмендә зур вакыйга булып узды. Дөньяның төрле илләреннән күз табиблары – офтальмологлар җыелган иде биредә. Алар арасында Татарстаннан да вәкил бар: Республика клиник офтальмология хастаханәсенең табиб-офтальмологы, Казан дәүләт медицина академиясенең офтальмология кафедрасы ассистенты Элина Минхуҗина!

Америка офтальмология академиясе, ягъни күз табибларының профессиональ медицина ассоциациясе дөньяның 32 мең табибын берләштерә. Исеменнән үк күренгәнчә, биредә төрле күз авырулары һәм аларны заманча дәвалау ысуллары белән шөгыльләнәләр.

Элина Ленаровна быел Татарстанның «Алгарыш» гранты нигезендә АКШның Тампа шәһәрендәге күзләр банкында (бүген дөньядагы иң зур банк) стажировка үтеп, тәҗрибә туплап кайткан иде. Фәнни хезмәтләрен, тәҗрибәсен искә алып, Американың Мөгез катлау ассоциациясе (Cornea Society of USA) әлеге академия кысаларында уздырган симпозиумда катнашырга чакырган аны.

– Мине күзнең мөгез катлавына (роговица) ясалган операцияләр кызыксындыра иде. Америкада аны яңача ысул – өлешчә алыштыру юлы белән ясыйлар. Стажировка вакытында бу операцияләрнең ничек ясалганын өйрәндем, күзләр банкын булдыру системасы белән кызыксындым. Россиядә күзләр банкы системасы әлегә юк. Моннан тыш, кератопластиканы, ягъни күзнең мөгез катлавының арткы өлешен алыштыруны безнең илдә әлегә фәкать Мәскәүдә һәм Санкт-Петербургта гына ясыйлар. Беренчедән, материал җитми, икенчедән, аны эшли белүче хирурглар юк. Тиздән әлеге ысулны Татарстанда да куллана башларга ниятлиләр. Мондый операция вакытында кеше авыртуны сизми, нәтиҗәләр дә бик күпкә яхшырак була.

«Алгарыш» гранты нигезендә Америкадан шушы методны өйрәнеп кайттым. Өч ай эчендә берничә фәнни проект әзерләнде. Аларның берсе Сан-Францискода үткәрелгән конгресста тәкъдим ителде. Конгресс вакытында «Wet lab» – төрле илләрдән килгән офтальмологлар алдында күзнең мөгез катлавын өлешчә алыштыру операциясе күрсәтелде. Мин дә өйрәтүче кураторлар сафында булдым.

Элина Минхуҗина: «Республикабыз исемен дөньяның зур клиникалары арасында күрсәсем килә».






Ярты миллионлы тираж белән бөтен СССРга таралучы журнал тышында сурәтләре басылып чыкканнан соң тормышларында нинди үзгәрешләр булды икән аларның? Бу проект шул хакта да... Татарстан тарихында аларның – ул чорда «Азат хатын», бүген инде «Сөембикә» булып басылучы журналыбыз геройларының да салган эзләре бар. Еллар сарысы сеңгән фотолардан елмаючы ул сөйкемле хатын-кызлар – республикабыз кичкән юлларның тере шаһитлары.

ЯШӘҮ ЯМЕ – ХЕЗМӘТТӘ



























Фото: Анна Арахамия

Суфия Шәяхмәтова: «Тормышымның иң авыр минутларында кулыма «Азат хатын» журналының үз фотом басылган санын алсам, җаныма ниндидер тынычлык, ышаныч иңә иде. Күңелем төшкән, кулларым салынган чакларда ул миңа киләчәккә өмет уятты».

1969 елның июне. Кукмара районының Ядегәр авылына сугыштан гарипләнеп кайткан, кулыннан һәртөрле эш килә торган гаилә башлыгы, өлгергәнлек аттестаты алган уртанчы кызын янына утыртып, җайлап кына сүз башлый: «Председатель Гафият абыең: «Суфия булдыклыга охшап тора, фермага сыер саварга менмәсме икән?» – ди. Олы кешенең сүзен аяк астына салып таптау килешмәс, әллә тәвәккәллисеңме?» Суфия карышмый. Унбиш сыерны кулдан саву да куркытмый аны. Әнә шулай даны илгә таралган «Восток» хуҗалыгының алдынгы савымчысына әйләнә ул. Исеме Мактау тактасына менә, рәсеме республика газеталарының беренче битендә басыла, эшен Казан телевидениесе яктырта. Бөек Җиңүнең 30 еллыгын бәйрәм иткәндә, ТАССРның хезмәт алдынгыларын, хөрмәтләп, Мәскәү Кремленә, Җиңү байрагы янында фотога төшәргә алып баралар. Араларында уңган савымчы комсомолка Суфия Абдуллина да бар. Зур кара күзле, озын толымлы, алма битле кызга СССРның төрле төбәкләрендә яшәүче егетләрдән хатлар ява. 1974 елның мартында кызның фотосы «Азат хатын» журналының тышлыгында дөнья күргәннән соң да бик күпләр аның белән танышырга тели. Ләкин Төрекмәнстаннан ук хатлар язган Илдар Шәяхмәтов дигән егет барысыннан да өлгеррәк булып чыга. Яшьләр, кавышып, Илдарның туган җире – Әлмәт районы Мактама бистәсендә төпләнә, ике балалары туа. Тормыш авырлыкларын да шактый татырга туры килә аларга: авыру булып туган кызларын аякка бастыру өчен больница юлын күп таптый яшь ана. Мәскәүгә кадәр алып барып, кызына берничә операция ясата. Аннары... язмышның тагын бер сынавы. Ирен җирләгәч, туган авылы Ядегәргә кайтып сыена Суфия Шәяхмәтова. Иртә-кич эштә булса, төннәрен тегү машинасын текелдәтә. Әтисеннән откан бу һөнәре тормышта төп таянычына әверелә.

Әле дә тегү машинасы тынып тормый аның. Бакча эшеннән бушаган арада (ә бакчалары зур, ниләр генә үстерми анда Суфия ханым, хәтта селекция белән дә шөгыльләнә), улы Радикка, килене Гөлнарага, оныкларына кирәк-ярагын тегә, авылдашларының гозерен кире какмый. Авыл уртасында балкып торган аларның яңа йортларында өч буын тату гына көн күрә бүген. Улы – шофер, ягулык системасы операторы, машина төзәтүче, күмәк хуҗалыкның ашлык амбарында электрик, килене Гөлнара – педагог. Суфия ханым үзе дә мәчеткә йөреп, дин сабакларын үзләштергән, дөнья хәлләре, сәясәт белән кызыксына, яраткан газета-журналларын алдыра. «Кайда яшәсәм дә, яшьлегемдә үземә канатлар куйган, хезмәтемне югары бәяләгән, язмышымны тамырдан үзгәрткән, авыр чакларымда күңел юаткычым булган «Азат хатын»нан, соңрак «Сөембикә»дән аерылмадым. Әле дә һәр санын көтеп алып, кулдан-кулга йөртеп укыйбыз, гаиләбезнең сердәше, ярдәмчебез, рухи терәгебез ул», – ди Суфия ханым.

Хәмидә ГАРИПОВА.
Казан–Кукмара–Ядегәр–Казан.

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

МАТУРЛЫК – КҮҢЕЛ ХАЛӘТЕ


Фото: Анна Арахамия

Косметологларны «матурлык профессорлары» диләр. Ягъни матурлыкның нинди булырга тиешлеген, аны саклауның юлларын белүчеләр. Безгә әкрен генә, матур килеш кенә картаерга булышучылар. Кайвакыт хәтта галиҗәнап вакытның үзен алдаучылар! Алар моңа ничек ирешә? Вакытны, чынлап та, туктатып буламы? Хатын-кызның матурлыгы исә аның тышкы кыяфәтенә генә бәйлеме? «Аль-Варис» медицина косметологиясе һәм трихология клиникасы баш табибы Лилия Тәбрис кызы МУЛЛАХМӘТОВА белән шулар хакында сөйләшәбез.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Матурлык салоннары безнең илдә чагыштырмача күптән түгел ачыла башлады. Косметолог һөнәре сезнең өчен дә балачак хыялы ук булмагандыр, мөгаен.

– Казан медицина институтының 1-2 нче курсында укыганда туды миндә бу хыял. Косметология буенча курслар бар иде инде – шуны эзләп таптым, укыдым. Ә V курста эшкә урнаштым. Косметолог булып! Кая дип сорагыз – «Wella Табакчи»-

га! Ул чакта Казандагы иң билгеле салонга! «Ишеген ничек ачып керергә?» – дип куркып уйлаганымны әле дә хәтерлим. Тик миңа анда ничек тә керергә кирәк иде! Телевизордан «администратор эзлибез» дигән белдерүләрен күреп калдым – барырга сәбәп шулай табылды. Директор мине үзе кабул итте. Барысын да сорашты, медицина институтында белем алуымны, курсларда укуымны белде. Яшь, янып торган матур вакытым иде бит. «Баскетболчы – озын, каратэ белән шөгыльләнүче – нык бәдәнле, ә косметолог синең кебек чибәр булырга тиеш. Без сине косметолог итеп алабыз», – диде ул. Мин теләгәнне үзе тәкъдим итте! Лекцияләрем беткәч, сәгать дүрттән соң көн саен эшкә килә идем. Шимбәякшәмбеләрнең берсендә дә ял итмәдем. Медицина институтында уку болай да җиңел түгел иде, әлбәттә. Аның каравы, кулыма диплом алганда ике ел эш тәҗрибәм бар – аякта нык басып тора идем.

Гөлнара Табакчи, җитәкче буларак, миңа бик күпне бирде. Хәер, миңа гына түгел. Ул чакта аның кул астында эшләүчеләрнең күбесе соңыннан үз эшен ачты. Безне ул дисциплинага, ягъни, ничек тиеш – шулай эшләргә өйрәтте. Аның өчен профессиональлек һәрвакыт беренче урында торды. Шул чактан калган гадәт: клиникабызның ишеген ачып кергән һәркем минем өчен – вип-пациент.

Биш ел эшләгәннән соң, «Wella Табакчи»дан киттем – арендага кабинет алдым. Яшьлегем белән тәвәккәлләгәнмендер инде... Аннан соң шушы клиниканы ачарга өлгереп җиттем.

Конкурентларга бик тыныч карыйм, дөресен әйткәндә, хәтта конкуренция сүзен белмим дә. Сәбәбе бик гади: пациентка һәрвакыт ул алырга килгәннән күбрәкне бирергә тырышам. Ә моның өчен, әлбәттә, белем кирәк. Мин табиб-дерматовенеролог та, косметолог та, физиотерапевт та. Мәскәү халыклар дуслыгы университетының эндокринология кафедрасында да белем эстәдем.

Хатын-кыз өчен иң мөһиме – гаилә дип саныйм, минем өчен дә ул беренче урында.

Кешенең тышкы матурлыгы аның эченнән, эчке әгъзаларының торышыннан башлана. Шуңа күрә дә җыерчыклардан котыласы иде дип килгән пациентның организмын тулаем карарга кирәк. Микроэлементлар, витаминнар җитәме, гормональ фоны тәртиптәме? Бәлки, аны башта гинекологка яки эндокринологка җибәрергә кирәктер? Соңгы вакыт Израиль косметологы Полина Лайтерның уникаль методы буенча эшлим – аңарда белем алдым. Reface Laitlift методы битне операцияләрсез генә яшәртүгә нигезләнгән. Бу метод белән эшләүче косметологлар Казанда түгел, Мәскәүдә дә юк әле. Пациентларымда нинди үзгәрешләр күзәтелүен социаль челтәрләрдә даими сөйләп барам – карый аласыз. Яшь барган саен, башыбыз үзенең торышын үзгәртә, буебыз чүгә. Боларга бәйле рәвештә бит тиресенең дә сыйфаты үзгәрә. Ә бу метод ярдәмендә баш һәм иңбашының торышын элеккеге хәленә кайтарырга мөмкин. Нәтиҗәдә, пациентның муены гына озынаймый, шунын аркасында бит тиресе матурлана, баш авыртулары, башның торышы дөрес булмау аркасында килеп чыккан хроник авыртулары уза. Дөрес, картаюны берничек тә туктатып булмый – барысы да вакытлыча. Әмма пластик операцияләрнең дә файдасы озакка бармый бит. Бу очракта нәтиҗәләр исә шактый тотрыклы. Пациентка кайбер физик күнегүләрне ясап торырга һәм ара-тирә миңа күренгәләргә генә кирәк. Хирург пычагы астына ятарга әзер булып та, аның алдыннан безгә килгәч, бу уйдан баш тартучылар хәзер байтак. Хатын-кыз үзеннән канәгать булсын өчен барысын да эшлим! Канәгать булсын һәм чәчәк атсын! Балкысын! Һәр хатын-кыз үзенчә матур бит, күпләр моны белми генә. Үскән чакта әниләре аларга: «Син чибәр!» дигән сүзне әйтмәгән. Аның матурлыгын ачу, аны шуңа инандыру хәзер минем кулда. Төрле табиб моңа төрлечә ирешә. Кемдер башта куркытып куя: «Сезнең хәлләр шундый начар, әмма мин моны үзгәртәм», – ди. «Начар» дигән сүздән үк куырылып каласың... Мин, киресенчә, хатын-кызны матурлык дулкынына көйләргә тырышам. «Сез чибәр, әмма тагын да матуррак булачаксыз», – дим. Әйе, хатын-кызның матурлыгын ачарга һәрвакыт пластик операция кирәкми.

Безне нәрсә күбрәк картайта: стресслар, аз хәрәкәтләнү, тазарумы?

– Сез санаганнарның барысы да дияр идем... Болар янына тагын «дисциплина булмау аркасында» дип тә өстисем килә. Монысы беренче урында тормыймы икән әле?! Бездә кеше үзен тәрбияләргә яратмый. Моның өчен вакытын кызгана. Шуңа да үземә килгән пациентлардан төгәллек, һәр кушканымны җиренә җиткереп үтәүләрен таләп итәм. Мин, гомумән, бик таләпчән табиб. Аралашкан кешеләрем белә: тормышта мин – перфекционист, һәрнәрсәдә камиллеккә ирешергә омтылам. Килгән пациентларым да шундыйлар. Юкка гына, пазллар кебек, бер-беребезгә тартылмыйбыз бит инде... Миңа бөтен Казанның йөрүе кирәкми: эшемнең сыйфаты мөһимрәк.

Хатын-кыз косметологка күбрәк кайчан килә, берәр төрле стресс кичергәчме?

– Төрлесе бар. 25 яшьләр тирәсендә мөрәҗәгать итә башлыйлар, чөнки тиренең беренче картаю билгеләре шул вакытта инде күренә. Мин бик күп сәяхәт итәм, барган җирләремдә гел хатын-кызларны күзәтергә яратам. Алар матурлыкларын ничек саклый, моның өчен ниләр эшли? Соңгы вакытта шун-

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Организм йокларга ятканда һәм уянганда бик сизгер. Тормышта нәрсәгә ирешергә теләгәнеңне шул минутларда үз-үзеңә әйтергә кирәк.



■ Әни – тормышымда иң зур саклаучым, догачым. Аның янында күңелем белән гел ял итәм. Һәр күзәнәгем яшәү дәрте белән тула.

дый нәтиҗәгә килдем: үзен иң тәрбияләгән хатын-кызлар бездә – Россиядә яши. Европада, гомумән, тышкы кыяфәткә бик тыныч карыйлар. Ничек бар – шулай картаялар. Яшьлекне, матурлыкны озаккарак сузуны дөресрәк дип саныйм.

Пациент: «Миңа шушы процедура кирәк», – дип килә, ә сез аңа башканы билгелисез...

– Мондый хәлләр бик еш була. Әйтик, 23 яшьлек ябь-яшь кыз: «Ботокс кадатырга телим», – ди. Ул сорады дип кенә моны эшләсәм табиб буламмы?! «Психотерапия белән нигә шөгыльләнәсең?» – дип гаҗәпләнүчеләр бар, билгеле... Минем өчен сәламәт матурлык мөһимрәк! Мөгаен, шуңа миңа чират торалардыр... Безнең клиникада «мода» дигән сүз юк. Мин модага, аның агымнарына иярүче түгел. Шуңа күрә: «Хәзер нинди процедураларга күбрәк йөриләр, нәрсәне сайлыйлар?» – дигән сорауга җавап бирә алмыйм. Нәрсә билгелим – шуңа йөриләр.

Процедураларның нәтиҗәсе нәрсәләргә бәйле?

– «Дус кызым сездә булган, ул бик канәгать», – дип килгән пациентларымны яратам. Кагыйдә буларак, алар инде нәтиҗәнең уңай буласына ышанып килә. Һәм ул чынлыкта да шулай килеп чыга. Ышануның көче искиткеч зур... Сезнең баш миенең миңа ярдәм итүе дә бик кирәк. Әлбәттә, бит тиресен өйдә ничек тәрбияләвегездән дә күп нәрсә тора. Ничек, нинди позада, ничә сәгать йоклавыгыздан. Күпме чиста су эчүегездән. Саф һавада күпме йөрүегездән... Йөзегезгә карагач, мин инде боларның барысын да күрәм. Кешенең йөзендә аның бөтен тормыш рәвеше чагыла.

Сездән һәркем үзгәреп китәдер...

– Үзгәреп дип... Ходай кешене, аның тышкы кыяфәтен үзгәртергә кушмаган. Мин шуңа да пластик хирург була алмас идем... Аллаһы Тәгалә адәм баласын яралтканда аны камил итү өчен тырышкан. Минем бурычым – Ходайдан җибәрелгәнне саклау гына. Артыгын эшләүдән куркам. Ходай каршында соңыннан җавап бирмәс өчен, нинди дә булса карар кабул иткәнче, барысын да алдан уйлап бетерергә телим. Хәзер йөзләрне әнә ничек кенә үзгәртмиләр. Мин моңа каршы – пациент үзенең йөзен югалтырга тиеш түгел.

Хатын-кыз косметиканы гел төрләндереп торырга тиешме?

– Бит тиресен еш кына хатын-кызның үзе белән чагыштырам. Бертөрлелектән бик тиз туябыз бит... Пациентларыма һәр юлы яңа линия билгеләргә тырышам, әмма һәр яңа препарат артыннан чапмыйм. Күргәзмәләргә бик күп йөрим, коллегаларым белән еш аралашам – аларның тәкъдимнәренә колак салам. Тик барысын да башта үзем кулланып карыйм. Ике-өч айдан соң гына клиникада сатуга куям. Күбрәк профессиональ косметикага тукталам, аларда биологик актив матдәләр бермә-бер күбрәк: BABOR (Германия), ATB Lad (Швейцария), Meder... Рестилайн препаратын яратам, аның белән күптән эшлим. Ул медицина косметологиясендә 1996 елдан билгеле: вакыт сынавын узган, тикшерелгән. Һәм үзенең сыйфаты белән елдан-ел куандыра гына. Һәр клиентның үзенә туры килгәнен сайларга тырышам. Ялгышканым юк диярлек. Моның өчен алардан күпме рәхмәт сүзе ишеткәнемне белсәгез?! Продуктны табиб сайлавы, ул билгеләве бик мөһим.

Ә үз косметологыңны ничек сайларга?

– Ул беренче чиратта табиб-косметолог булырга тиеш. Табиб сүзенә басым ясап әйтәм! Эзләүне шуннан башларга кирәк... Бүген күпләр курсларга йөреп тә косметолог булырга мөмкин дип саный. Белеме булмаган килеш тә ирен ясарга тотынучылар бар. Ә бит ничә дипломың бар килеш тә шприцны кулыңа икеләнеп кенә аласың. Кеше сәламәтлеге белән бәйле эш гади буламыни?! Сайлаган табибның тышкы кыяфәте үк ошарга тиеш сезгә. Мәсәлән, мин пациентның йөземә карап: «Башта үзен тәртипкә китерсен әле, аннары миңа тотыныр», – дип уйлавын теләмим! «Миңа да сезнеке кебек маңгай кирәк!» – дисен ул! Миңа 40 яшь



һәм әле бер тапкыр да ботулотоксин салдырганым юк. «Аны күпме иртәрәк кадасаң, шулкадәр әйбәтрәк», – дип өйрәтәләр хәзер. Алай дип санамыйм. Ансыз да матур булып була. Әйе, бу авыррак юл, әмма бит моңа ирешү мөмкин. Пациентлар миңа карап шуңа инанырга тиеш. Шул очракта гына ике арада ышаныч туачак. Ә ахыргы нәтиҗәнең ышанычка никадәр бәйле икәнен алдарак әйттем инде. Клиниканың ишеген ачып кергән һәркемгә: «Бернәрсә турында да уйламагыз, сезнең өчен хәзер мин уйлыйм», – дим. Аларга бу бик ошый. Очкычка утыргач, безнең өчен барысын да пилот хәл итә бит, монда да шулай. Һәр пациентыма беренче очрашуда: «Әйбәт нәтиҗә сездән бигрәк минем үземә кирәк», – дим. Кушканнарымны өйдә үтәп, миңа ярдәм итүләрен генә сорыйм.

Косметологка хатын-кыз беренче тапкыр ничә яшьтә килергә тиеш?

– Әгәр кызым булса, мин аны беренче тапкыр косметологка 12-13 яшьтә алып барыр идем. Битне ничек дөрес тәрбияләргә икәнен ул әнисеннән түгел, табибтан ишетергә тиеш. 15 яшьтә нинди косметик чаралар кулланырга ярый, 16 да, 18 дә... Табиб аңа тән тиресенең нинди типка караганын әйтәчәк. Битне ничек юарга, чистартырга икәнен өйрәтәчәк. 15 яшьтә кыз бала макияжны ничек юып төшерергә икәнен инде белергә тиеш. Әйтик, бит тиресе өчен чыгарылган гель белән күз тирәсенә кагылырга ярамый. Күз тирәсендә тире бик сизгер: әгәр без аны башка типтагы бит тиресе өчен чыгарылган гель белән чистартабыз икән, ул тизрәк сулачак, картаячак. Шуңа күрә кемнәңдер инде 25 яшьтә үк җыерчыклары күренә... Ярый әле хәзер солярий модасы узып бара. Берара шунда йөрү белән мавыктылар бит. Япь-яшь кызларның йөзендә беренче җыерчыклар солярийда дөрес кызынмаганнан соң чыкты. Болар хакында табиб авызыннан ишетсә, кыз бала аны гомергә хәтерләп калачак. Ә алдарак әйтелгән таләпләрне бөтен әниләр үзләре дә үтәми, шулай булгач, кызларын берничек тә моңа өйрәтә алмыйлар. Кызганыч, әлегә алар безгә бит тиресе бозылган очракта гына шулай иртә мөрәҗәгать итә.

«Аль-Варис» клиникасының бер юнәлеше – трихология диелгән...

– Трихология – чәчне дәвалау белән шөгыльләнүче фән ул. Безнең очракта чәчләргә профессиональ ярдәм күрсәтү турында сүз бара. Чәч коелу күбрәк ир-атларга гына кагыла дип уйлый күпләр. Клиникага исә хатын-кызлар ешрак та килә. Бәби көткәндә, бала тапканнан соң, стресслар кичергәч коела аның чәче. Сәбәпләре бихисап! Чәч тә яшь барган саен көчсезләнә, аннан ул стресска да бик тиз бирешә. Шуның өчен аны ефәк кебек чагында ук тәрбияләргә керешергә кирәк. Мин бу фикергә тәҗрибә белән килдем. Пациентларыма: «Чәчегез менә дигән, берни дә эшләргә кирәкми», – дигәнем булды. Кемнеңдер игезәк баласы туды, икенчесе зур югалту кичерде һәм... болыт кебек чәчләреннән бер учма калды. Маска ясау турында гына әйтмим. Гөлнең яфраклары коела башлагач, аларны кире ябыштырып куярга тырышмыйсыз, ә гөлнең тамырын дәвалыйсыз бит. Монда да шулай. Ике елга бер тапкыр булса да чәч тамырларын табибтан дәвалатырга кирәк. Чәч бик рәхмәтле ул: профессиональ дәрәҗәдә аз гына тәрбияләдеңме, яңгырдан соң калыккан гөмбә кебек үсеп китә.

Еш кына кайбер клиникалардан шалтыратып: «Бушлай битегезне чистартабыз, килегез», – дип чакыралар...

– Мондый очракта башта: «Үземне кем кулына тапшырам икән?» – дип кызыксынырга кирәктер. Тәҗрибәле докторга гел чират аңа... Минем үзем өчен пациент каршында да, Ходай каршында да йөзем ак булу барысыннан да өстен. Клиникага исем сайлаганда Аллаһының 99 исеменең берсенә – «Аль-Варис»ка тукталдым. Эшкә Ходайның ризалыгын алып тотыну кебек санадым моны. Корабка нинди исем кушасың, шулай йөзеп тә китә бит... Рәмзия апам шул 99 тугыз исемнең барысын да кертеп, ә уртага зур итеп «Аллаһ» сүзен урнаштырып шәмаил чикте. Өч ел буе! Ул шәмаил клиника бусагасыннан керүгә һәркемне каршы ала. Дога белән яшәү, эшләү бөтенләй башка бит ул. Дини тәрбия гаиләдән киләдер. Әнидән... Әти белән әнинең соңлап кына тудырган дүртенче баласы мин. Ике апам да минем кебек үк табиблар. Әтиебез миңа 11 яшь чакта ук мәрхүм булды. Әнием, шөкер, исән-сау, аңа 81 яшь. Иң якын дустым, киңәшчем – ул!

Үз һөнәрегезне беренче чиратта нәрсә өчен яратасыз?

– Клиникага бәйрәмгә килгән кебек киләм. Эш дип әйтәсем дә килми, бу бит иҗат! Пациентлар күзендәге очкынны яратам! Хатын-кызның эчке ресурслары ачылуын. Алар атлап бармый, оча бит андый чакта! 66 яшьлек бер пациентым бар. Reface Laitlift методы буенча яңа процедура узды һәм шуннан соң ялга китте. «Лилия Тәбрисовна, күз алдыгызга китерәсезме: 45-50 яшьлек ир-егетләр минем белән танышырга тели!» – дип яза. Ул бит безнең клиникага килгәннән соң ачылды. Королевага әйләнде! Уңыш бит бу!

Әйе, эшемне бик яратам, әмма кичке җидедән дә калмыйча өйгә ашыгам. Ирем янәшәсендә, балам янында буласым килә. Гаделгә әле 7 генә яшь, кичләрен дәрес әзерлисебез, тамак карлыкканчы китап укыйсыбыз бар. Ул да минем кебек китап ярата. «Аль-Варис»ны ирем Рөстәм белән бергә ачтык. Ансыз мин – ике кулсыз... Клиникагызны зурайтырга кирәк диләр. Бәлки... Бөтен процедураларны да үзем эшләмим, кайберләрен янымдагы белгечләр, шәфкать туташлары да башкара. Мин моны исә бары тик ышанычлы кулларга гына тапшыра алам... Клиника берничә булган очракта моңа ирешү авыррак булачак. Аннан – тормыш артыннан куу, ашыгу юк миндә. Бертуктамый чаба башласаң, кайчан яшәргә соң? Мин исә һәр көннең ямен тоеп яшәргә телим..

Тышлыкта: Лилия Тәбрис кызы Муллахмәтова «Александр Богданов» бренды киемнәреннән.



Фото: Анна Арахамия

АСЫЛ ИРГӘ БАР ДА КИЛЕШӘ



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Һөнәрне гендер билгесе буенча бүлеп карау искелек калдыгына әйләнеп бара. Чәчтараш, маникюр остасы, визажист, бала караучы, китапханәче, секретарь, модель... Бу һәм башка эшләрне инде күптән ир-атлар да башкара һәм кайберләре гүзәл затларның борынына чиертә. Тик хатын-кыз һөнәре дип саналган хезмәт урыннарында эшләгәннәргә әле һаман да кырын караучылар бар. Янәсе, болганып йөри инде хатын-кыз арасында; йә булдыксыз дип бәяләнә, йә иң куркынычы – берәр ярлык тагып куялар. Мондый шикләнүләргә нокта куярга булдык. Ир-атларныкы итеп кабул ителмәгән һөнәр ияләрен табып аралаштык. Әңгәмәдәшләребезнең барысы да – чын ир-егетләр. Иң мөһиме: тормышта үз миссияләрен үтәүче затлар – хөрмәтле гаилә башлыклары һәм туйдыручылар. XX гасырда җәмгыятьнең асылы үзгәрә. Хатын-кызлар үз хокуклары өчен көрәштә җиңә һәм җиң сызганып дөнья яуларга керешә. Кулларына көрәк, корал алалар, трактор-машина йөртергә өйрәнәләр. Партиягә керәләр, министрлар һәм президент булалар. Ниһаять, галәмгә очалар! Хәзерге заманда хатын-кыз аягы басмаган, аның кулы тимәгән бер генә өлкә дә калмагандыр. Бүгенге көндә җәмгыятьтә кире тенденция башлану исә һичничек тә ир-атларның вакланууы, күпләрнең ялгыш фикере булган сексуаль ориентация белән бәйле түгел. Ир-ат акрынлап элек-электән үзенеке булган һөнәрләрне кире кайтара һәм яңаларын үзләштерә. Бары шул гына. Психолог Алсу Ханнанова, һөнәр сайлау темперамент белән бәйле, ди. Ә ул гаиләдә, кечкенәдән үк формалаша. «Хатын-кыз һөнәрен сайлаганнарның темпераменты башкачарак була», – ди психолог. Бу һич тә аларда ир-ат башлангычы түбән дигән сүз түгел!



Кранчы маникюр остасы

25 яшьлек Рамил Вәлиуллинның яңа һөнәр үзләштерүенә уеннан уймак сәбәпче. Хатыны Әлфинә – маникюр остасы. Арендага кабинет алгач, ремонт ясашырга килеп йөри башлый ул. Хатынының эше беткәнен көтеп утырган бер кичтә уйнап кына пилка алып, тырнакларын тигезләргә тотына. Моны күргән Әлфинә аны видеога төшерә башлый. Эш көлешү белән тәмамлана. Тик бу икесенең дә исендә кала, күрәсең. Әлфинәнең маникюры бозылгач, иреннән ярдәм сорый: «Бәлки тырнагымны ясап карарсың?» Рамил риза була.

– Хатыным – беренче клиентым, – ди ул көлә-көлә, ярты ел элек булган хәлләрне искә төшереп. Ул вакытта Әлфинә өйрәтеп тора, Рамил пилка, кайчы алып эшкә керешә. Рамилнең куллары ювелир эшенә туры килеп тора – төзелештә кранчы ул. Анда да бит һәр миллиметр мөһим. Дөрес, моннан берничә ел элек, хатын-кызларга маникюр ясаячаксың, дип әйтсәләр, ул һич тә ышанмас иде. Кечкенә чакта рәсем дә ясарга яратмаган Рамил бары ир-ат эшләре генә башкарып үскән. Үз йортлары белән яшәгән гаиләдә егеткә балта да, чүкеч тә тотарга туры килгән.

– Яңа һөнәрегезне әтиегез ничек кабул итте соң? – дип сорыйм.

– Бик тыныч. «Өйгә акча алып кайтасың икән, нигә әле эшләмәскә», – диде.

Рамилгә теләктәшлек белдерүчеләр дә, нигездә, ир-атлар. Маникюрга килергә генә теләкләре бик юк. Ә менә аңа гына йөрүче хатын-кыз клиентлары бар инде. Алар: «Син җайлап кына, йомшаграк ясыйсың», – диләр икән. Һәрберсе ир-ат маникюр остасы белән селфи төшми калмый. Маникюр ясау буенча осталыгын арттыру өчен тагын укырга җыена ул. Педикюрга тотынырга да уе бар. Клиентлары сорый икән. Әлеге һөнәрне үзләштергәннән соң, Рамил, кранчы хезмәт хакыннан тыш, өйгә өстәмә ун мең сум акча алып кайта башлаган.

– Рамилнең чынлап эшли башлавына бик ышанып бетмәгән идем. Күрәм: кулы килешеп тора. Күптән уртак бизнес турында хыяллана идем. Бергәләп эшли башлагач, уртак кызыксынуларыбыз да, сүзләребез дә артты. Ир-атларның мондый эш башкаруында бернинди начарлык күрмим. Эшне бергәләп алып баруыбызга шатланам гына, без тагын да якынайдык, – ди Әлфинә.

– Финанс ягыннан исәпләгәндә салонда эшләү отышлырак була икән, нигә эшләмәскә, – ди танылып килүче маникюр остасы. Аны әле федераль каналларның берсендә эфирга чыгучы тапшыруга да чакырганнар. – Анда керфек ясаучы, шугаринг белән шөгыльләнүче ир-атлар да килгән иде. Мин ялгыз түгел икәнмен бит. Клиент базам күбәйсә, төзелешне ташларга да ризамын...



Шәл бәйләдем, шәл бәйләдем...

– Ник аптырыйсыз инде, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, – дип каршы алды безне Кукмара районы Аш-Бужи авылында яшәүче Мөхлисулла абый Корбангалиев. – Без үскәндә авылда бөтен кеше шәл бәйли иде. Гаиләдә өч малай, бер кыз идек. Әти шабашкадан кайтып кермәде, әни, авылдагы башка хатыннар кебек, шәл бәйләп сатты. Заказлар булганда, тиз генә бәйләп бирергә кирәк. Шуңа безне дә өйрәткәндәр. 12 яшьләрдә шәл чите бәйли идек. Кая ул, бәйләмим, өйрәнмим, дип киреләнеп утыру. Андый гадәт юк иде безнең. Башка малайларның бәйләгәнен хәтерләмим. Әмма без өчебез дә бу һөнәрне үзләштердек. Кич утырып бәйли идек. Дөрес, оялу кебегрәк хис бар иде барын. Кешегә бик күрсәтәсе килмәде, тик бөтен авыл белә иде. Күрше апалары: «Наилә, җитешә алмыйм, малайларың шәл чите бәйләп бирсен әле», – дип керә иде. Көн ярым эчендә шәл чите әзер. Аның өчен 4 сум акча бирәләр. Ул вакытта 4 сумга бер капчык ипи тия. Эшләгән акчамны җыеп, миңа велосипед алдылар. Армиягә киткәнче кулдан энә төшмәде. Аннан кайткач, бик сирәк бәйләдем. Комбайнда да эшләдем, балта остасы булып шабашкаларда да йөрдем, агач кашыклар да ясадым, киез итек тә бастым. Бар эшне дә өйрәндем, самолет кына йөртмәдем...

Иренә ягымлы гына карап утырган Тәслимә апа сүзгә кушыла:

– Без өйләнешкәч, шәл уртасын машина белән бәйләү чыкты. Мин читен бәйлим, ул ике сәгать

эчендә уртасын бәйли. Йонны гел Мөхлисулла аялап бирде. Без бәйләгән шәлләрнең чуты юк. Хәзер базарда носки сорыйлар. Мин үкчәсен уздырып бирәм дә, ул калганын «әйт» дигәнче бәйләп куя.

– Балта тоткан бармаклар ничек энә дә тота ала соң ул? – дип сорыйм Мөхлисулла абыйдан.

– Кулга кашык тотып ашарга өйрәнәбез дә, шуны гомер буе онытмыйбыз бит. Энә белән эш итү дә менә шулайрак ул. Иялләнгән инде. Аннан соң... бәйләү бик тынычландыра. Әле менә оныкларымны өйрәтә башладым. Өйрәнсеннәр, һөнәр кирәк ул. Һөнәрле үлмәс дип, тикмәгә генә әйтмәгәннәр.



42 ел буе сыер сава

– Ул заманда 16 яшьлек үсмер трактор руле артына утырырга хыялланган булдыр йә булмаса атлар белән җенләнгәндер. Ә сез нигә фермага килдегез?

– Менә син кечкенә чагыңда кем булырга теләдең?

– Журналист...

– Син дә бит хыялыңа тугры калгансың. Мин дә шулай...

Әтнә районы Күшәр хуҗалыгының «Татарстанның атказанган терлекчесе» Мәннан абый Шәяхмәтовның тормыш фәлсәфәсе әнә шулай гади һәм ихлас.

Машина-трактор турында хыялланмаган, гомере буе руль артына утырмаган, теләге дә булмаган. 5 нче сыйныфтан сыер сава башлаган улларының мәктәптән соң фермага сыер савучы булып урнашуына әти-әнисе дә каршы төшмәгән. Беренчедән, эше бар, икенчедән, өйгә акча кайта. Өйләнгәннән соң да хатыны белән икәүләп сыер сауганнар. Һәм гомер буе бергә эшләгәннәр. Эштә хатыныннан уңганрак та булып чыга әле – дәрәҗәле исемгә лаек була. Мәннан абыйның кулларына күз иярми. Аның белән бергә эшләгән Резеда Галимҗанова: «Яшь булсак та, безне уздыра, чиләк тә күтәрткәне юк», – ди.

– Көнгә бишәр йөз баш сыер савабыз. Аяклар калмый. Ник аны хатын-кыз эше дип саныйлардыр? Россиядә генә шулай кабул ителгән. Ул ир-ат эше югыйсә. Чит илләрдә ир-атлар сава, диләр.

Дөрес, чиләк тотып, бидон күтәреп йөрүләр инде тарихта калды. Хәтта исеме дә сыер савучы дип түгел, ә сыер саву операторы дип атала. Шуңа карамастан, ул хатын-кыз хезмәте санала. Бу һөнәр ияләренә карата элеккеге хөрмәт тә бетте. «Безнең әниләр эшләгән заманда, җыеп, сезон саен шәһәргә концертларга алып баралар иде. Ел буе бер ялсыз эшлибез, концерт күргән дә юк инде. Фермада эшләргә кирәк шул, шуңа да авылда эшсез ятсалар яталар, ә монда төшмиләр», – ди операторлар. Гомер буе фермадан кайтып кермәгән Мәннан абый елмаеп кына басып тора. Белә, күпме генә авыр булса да, фермадан китмәячәк. Иялләнгән хезмәт. Пенсия яше җитте дигәндә генә, тагын өстәп куйдылар куюын. Саулыгы булса, лаеклы ялга да чыгар. Әлегә үзе әйткәнчә, эшнең ертыгы юк. Ел саен республика күләмендә югары күрсәткечләргә ирешә.

– Бар кеше дә начальник була алмый ул. Тормыш шулай җиңел генә барсын иде дә бит... Эшеңне яратып башкарырга кирәк. Башкача булмый.



«Балалар миңа энергия бирә...»

– Тугызынчы ел эшләсәм дә, беренче эш көнемне әле дә хәтерлим, – ди Казан шәһәренең 311 нче балалар бакчасының музыкаль җитәкчесе Юрий Шулятьев. – 3 яшьлек сабыйлар белән җырларга өйрәндек. Соңыннан шарлар белән уен уйнадык. Ахырда балаларга кызык ясарга уйладым. «Әйдәгез, балалар, кем тизрәк кабарткычны шартлата», – дим. Алар миңа күзләрен түгәрәкләндереп карап тора. Янәсе, үрнәк күрсәтәм: тоттым да бер кабарткычны шартлаттым. Авызларын җәеп еларга тотынмасыннармы... Аптырап калдым. Малай кешенең шар шартлатудан куркып елавын һич кабул итә алмадым. Эшли-эшли аңладым инде, кечкенә сабыйлар белән эшләү техникасын белмәгәнмен.

Юрий армиядән кайткач, музыка көллиятен тәмамлап, Н. Җиһанов исемендәге Казан консерваториясенә тромбон классына укырга керә. Икенче курста укыганда балалар бакчасына музыкаль җитәкче кирәк дигән белдерүне күреп ала да шалтырата.

– Ир-ат? Бик кызык! Килегез, карап карыйк, – диләр.

Балалар бакчасы мөдире Гөлсинә Җәвид кызы соңыннан гына әйтә Юрийга: балалар белән ничек шөгыльләнгәнен бер ай буе ишекнең теге ягыннан тыңлап йөргән

икән. Юрий үзе дә беренче атналарда: «Нишләп йөрим инде мин монда», – дип икеләнә. Коллегаларының хөрмәтен, мөдирнең һәрвакыт эше белән кызыксынуын күреп, калырга карар кыла. Ә икенче елны «Иң яхшы тәрбияче» бәйгесенә әзерләнгәндә эшкә башы-аягы белән чумганнан соң, аңа балалар бакчасында эшләү тагын да ныграк ошый башлый. Китмәскә тагын бер сәбәп чыга: хезмәт хакын арттыралар. Сыйныфташлар очрашуында дус егетләренә үзенең кем булып эшләвен әйткәч, тегеләре аптырап кала. «Хәер, үземнең урында башка бер егетне күз алдыма китерсәм, миңа да кызык булып китә», – ди Юрий. Гаилә корганнан соң, бераз авырлыклар булып ала алуын. Ире хатын-кыз коллективында бердәнбер педагог булып эшләгән хатынның хәлен аңлыйсыздыр инде. Утырып сөйләшкәннән соң, аңлашалар тагын үзе.

Без дә аның балалар белән эшләгәнен карап тордык. Ул әле җырлап җибәрә, әле синтезаторы артыннан сикереп торып, нәниләр белән бии-бии уйный. Күренеп тора: балалар аны ярата, ләкин шул ук вакытта аның ир-ат икәнен аңлыйлар. Шук малайлар да Юрий Александровичның карашын тоюга шым була.

– Усалмы укытучыгыз?– дип сорыйм алардан.

– Усал... – ләкин шунда ук әйтергә ашыга башлыйлар. – Ә без аның белән уйныйбыз, ул безгә күп җырлар өйрәтә. Юк, усал түгел, аның белән кызык...

Бантиклы бер кыз оялып кына: «Юрий Александрович чибәр!» – ди.

Юрий дүрт эштә эшли. Балалар бакчасыннан тыш, шәхси үсеш мәктәпләрендә хезмәт куя, ике көнгә бер төнге каравылда тора. «Каравылда җырлар язам», – ди Юрий. Балалар өчен бик күп җырлар авторы да әле ул. Россия күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә балалар белән дә, үзе генә дә катнашып, күп җиңүләргә ирешкән. Әнә шулай, җитез тиен кебек бөтерелә-бөтерелә, ике ипотека түли. Улына әле 4 яшь кенә, ә ул инде аның киләчәге хакында уйлана. «Студент яшенә җиткәндә улымның фатирлы булуын телим. Минем кебек тулай торакларда яшәмәсен иде», – ди 33 яшьлек ата.

– Ир-ат башым белән нишлим соң монда дип уйлаган чакларым да булды. Ләкин балалар бакчасында үземне таптым. Эшне алыштырып торырга кирәк, диләр. Бу хакта уйланам. Минем әлегә энергиям күп, балалар белән эшли алам. Ә картая башлагач, алар белән уйнап йөри алмаячагымны аңлыйм. Шуңа да әкренләп җирлек әзерлим. Казан инновацион университетында педагогик белем алам. Әлегә эшемне, балаларны бик яратам. Алар да миңа яратулары белән җавап бирә...

...Һәр героебыз – үз эшенең остасы. Сокландык, яңа яктан ачтык аларны. Бу – хатын-кыз һөнәре, дигән уй башларына да килми. Чын күңел биреп, аңлы рәвештә сайлаган һөнәрләрен яратып башкаралар, шуңа да уңышларга ирешәләр. Һөнәрләрне җенескә карап бүлү дөрес түгел. Хәзер карьерада да унисекс хакимлек итә. Иң мөһиме – профессиональлек. Ә... яхшы кеше һәм итагатьле ир булу өчен сайлаган һөнәрнең әллә ни әһәмияте юк, минемчә.

2019: СОКЛАНДЫРДЫЛАР!

Ресторан сервисы буенча иң оста бала Татарстанда яши! 15 яшьлек Илария Баһаветдинова быел Казанда узган WorldSkills Juniors Бөтендөнья һөнәри осталык чемпионатында әлеге компетенциядә беренче урынны алды.

Узып баручы ел Яшел Үзәндәге 7 нче мәктәптә укучы Иларияне ң хәтерендә мәңге сакланыр. 8 нче сыйныф укучысы үзенең тырышлыгы нәтиҗәсендә бөтен дөньяга танылды.

Казан сәүдә-икътисад техникумында белем алган апасы WorldSkills хәрәкәтендә катнаша. Осталыгын раслаган Аринага эксперт булырга тәкъдим итәләр һәм үзенә укучы сайларга кушалар. Бөтен белгәненнe бертуган сеңлесенә дә өйрәтәсе килә шул. Шулай итеп, ул Иларияне сайлый. Бер-берсен ярты сүздән, бер караштан аңлаган апа белән сеңелнең тырышлыклары бушка китми: Илария чемпионатның төбәк этабында беренче урынны яулый. Җиңү җиңел бирелми аңа. Мәктәптә дә дәресләрне калдырырга ярамый, республика дәрәҗәсендә үткән бәйгеләрдә дә катнашасы, көн саен алтышар сәгатьлек тренировкаларда тәҗрибә туплыйсы... Иларияне Бөтендөнья чемпионатында катнашырга Россия командасына алалар. Ярышта ул бар осталыгын күрсәтеп, беренче урынга лаек була. «Чемпионат алдыннан да, бүләкләү тантанасы вакытында да бик дулкынландым, чөнки бер дә җиңелергә яратмыйм», – ди Илария. 15 яшендә шундый зур уңышка ирешә алуы белән бик горурлана, тәҗрибә туплый алуына шатлана. Ул вакытларны хәзер сагынып искә ала. Команда белән җыелуларын, психологлар белән эшләүләрен, яңа дуслар белән аралашуларын... Хәер, көндәшләре белән дуслык җепләре ныгыган – социаль челтәрләрдә төркем төзегәннәр, аралашып торабыз, ди. Хәзер тагын бер җиңүгә әзерләнә Илария – алда чыгарылыш сыйныф имтиханнары. Аларны уңышлы тапшырып, Санкт-Петербургка укырга китәргә хыяллана. Иларияне ң чемпионатка кадәр ресторан сервисы буенча эшләячәкмен дигән хыялы да булмаган. Ләкин әзерлек барышында, бөтен серләрне төшенгәч, шуның хәтле мавыгып китә ки, хәзер бу өлкәдә профессионал булырга уйлый. Укып кайтып, Татарстанда ресторан бизнесын югары дәрәҗәгә күтәрүдә үз өлешен кертәсе килә аның.


Илария Баһаветдинова: «Җиңелергә яратмыйм...»

PRESSA



ТАР СУКМАКТАН – ЗУР ЮЛГА



Лилия ГӘРӘЕВА

«Авыл хуҗабикәсе» сәхифәсе – Матбугат һәм массакүләм мәгълүмат чаралары федераль агентлыгы булышлыгы белән оештырылган уртак проектыбыз иде. Бер ел буе журнал битләрендә дөнья күреп килгән ул язмаларның төп геройлары – бүгенге авылның хуҗабикәләре. Башкарган эшләре төрле аларның: кемдер терлекче, кемдер яшелчәче, бал кортлары үрчетүче, токымлы үрдәкләр йә чебешләр үстерүче, икмәк пешерүче, милли курчаклар ясаучы... Эш-шөгыльләре төрле булса да, бер яклары уртак – көчле рухлы, тырыш бу ханымнар «авылда эш юк», дигән заманда, шәһәрдән читтә үз бизнесларын ачып, авылдашларына эш урыннары булдыручылар.
Бу язма – әлеге проект нигезендә әзерләнгән язмаларның ахыргысы. Проект тәгәлләнсә дә, уңган-булган ханымнар турында язуыбыз тукталмас анысы. Аларның эшләре аша, әнә бит, кайда яшәсәң дә, үз юлыңны табарга мөмкин дип әйтергә телибез.

…Бер шалтыраттым: «заводта», диделәр, аннары цехны тикшерергә кереп киткән булып чыкты, икенче шалтыратканымда киңәшмәгә җыена иде… Менә нинди икән ул авылның бүгенге хуҗабикәсе – эшмәкәр ханым! Күз алдына нык ихтыярлы, коры холыклы, башы-аягы белән эшкә чумган, теләсә кайсы четерекле мәсьәләдән чыгу юлын таба белгән «тимер леди» образы килеп басты.

Кайбыч районының Чүти авылы – бу тирәләрдәге берданбер мишәр авылы, чәйне дә «цәцәкле цәйнек»тән эчәләр монда. Тырыш кешеләр яши Чүтидә, халкы күп итеп мал-туар асрый, каз-үрдәк үстерә, бал кортлары тота… Чүти – мишәрлегe белән генә түгел, Шәкүр каракның туган авылы булуы белән дә атаклы. Аның турындагы легендалар әле бүген дә халык телендә. Урлашу мактаулы шөгыль булмаса да, чүтилеләр Шәкүр каракны онытмый. Узган гасырның беренче яртысында иҗат иткән язучы, шагыйрь Зариф Бәшири дә – Чүтинеке. Менә аның белән чынлап горурлана авылдашлары. Хәер, горурланырлык кешеләр бүген дә үз араларында җитәрлек. Бу язманың геройлары – әнә шундыйлардан.

Дөресен әйткәндә, бүген монда каз йолкышырбыз дип килгән идек. Ләкин без килгәндә казлардан кара җир өстенә чәчелгән ак каурыйлар гына калган иде инде. Авыл халкы бөтен эшен иртүк торып бетереп куя шул. Аның каравы, каз итеннән пешкән шулпага җитештек. «Тимер леди», каз йолкучы кызлар белән берочтан, безне дә кыстый-кыстый сыйлый. Баксаң, бер дә «тимер» түгел, бик тә кунакчыл һәм үтә дә нечкә күңелле гап-гади татар хатыны булып чыкты ул. Шушы авылда туып-үсеп, колхозда эшләгән, сыерын да сауган, кайнана-кайнатасына килен хезмәте дә күрсәткән, балаларын да үстергән, үзе әйтмешли, тормышның алдын да, артын да күргән кеше Рәмилә ханым Щукина. Фамилиясенә бер дә аптырамагыз, бу авылда чеп-чи татар гаиләләре дә Уткиннар, Козловлар, Щукиннар булып йөри. Кайчандыр халык таккан кушамат русчага әйләндерелеп, әнә шулай фамилия булып киткән. «Без – Щүкәләр нәселеннән», – ди үзләре.

– Экскурсияне кайдан башлыйм икән? – ди крестьян-фермерлык хуҗалыгы җитәкчесе Рәмилә ханым. – Фермаларны карап чыгыйкмы, заводка сугылыйкмы?

Безнең исә барысын да күрәсе килә. «Сез завод дип сөйләгәч, бигрәк кызык булып китте. Авыл җирендә ниткән завод икән ул?!» – дип, хуҗабикәгә иярәбез. Эх, Рафаэль әфәнденең генә өйдә юк чагына туры килдек. «Безнең хуҗалыкның моторы ул. Мотор тукталса, бөтен эш туктала, – ди Рәмилә ханым. – Табасын – табучы, барлыйсын – барлаучы да ул. Мин исә – муен, юнәлеш кенә биреп торам…»

Яныбыздан гына өр-яңа зәңгәр «Беларусь» кычкыртып уза. «Улым Риназ! – дип елмая әнисе. – Фермалар аның карамагында хәзер…»

Бүген 150 баш мөгезле терлек асралучы – аның 40 башы савым сыерлары – бу бина кайчандыр «Йолдыз» колхозының ашлык амбары булган. Маллар асрарга дип түгел, ата-бабадан калган бал кортларын кыш көне тоту өчен сатып алган булган аны Щукиннар.

Хәер, әйдәгез, барысын да баштан башлыйк әле, 2003 елдан ук. Ул елны алар авылдан сөт җыярга керешә. Моның өчен мичкәле УАЗ машинасы алына, Щукин Рафаэль исеменә «ИП» ачыла. Моңарчы сөтне кая урнаштырырга аптыраган авыл халкы рәхмәт укый үзләренә. Соң, шулай булмыйча, авылдагы төп табыш чыганагы шул сөт ләбасә. «Башка авыллардан да җыймыйсызмы соң? Сөтен урнаштыра алмагач, халык сыерын бетерә бит», – дип тәкъдим итә Кайбыч районының ул чактагы җитәкчесе Җәүдәт Гаффаров. Булган акчаларны җыештырып, тагын бер УАЗ алырга туры килә. Башта – биш, аннары унсигез авылдан сөт җыялар. Үз абзарлары тулы да мал-туар: савым сыерлары гына да алты була ул чакта. «Гаилә фермалары ачучыларга дәүләт грант бирә икән дип ишеттем дә, безнең болай да ферма бит инде, дип, әлеге программа белән танышырга булдым», – дип искә ала Рәмилә ханым. 2012 елны крестьян-фермер хуҗалыгы булып теркәлеп, 2013 елдан җиң сызганып эшкә дә керешәләр. Дәүләттән бирелгән 1 миллион 250 сумлык грант акчасы гына ферма кадәр ферма ачу өчен җитми, билгеле. «Беренче елны симертергә дип 26 баш үгез алдык. Берсен суеп тапшырабыз да, савым сыеры алабыз, тагын берсен урнаштырып, тагын сыер эзләп чыгып китәбез… Шулай итеп, сыерларның баш санын ул вакытта 25 иттек».

25 сыер дип әйтүе генә җиңел лә! Ул бит әле Рәмилә ханымның үзенең дә «Кубня» агрофирмасында кадрлар бүлеге мөдире булып эшләгән чагы. Көн дә 15 чакрым барып, 15 чакрым кайтасы бар… «Иртәнге дүрттә торып, фермага йөгерәм. 25 сыерны берүзем савып, кабат өйгә чабам. Анда – карт кайната. Эшкә киткәнче ашарга әзерләп, суын китереп калдырырга кирәк. Үзем керә барам, өстемдәге бер киемемне салып, икенчесен кия барам… Берсендә туганым Рәфикъ карап тора икән. Кулыма чиләк тотып кереп киткәнмен дә шундук башка киемнән килеп тә чыкканмын. Мине танымый калган. «Берәрсе кайттымы әллә? Әле генә чиләк күтәреп кереп киткән кеше кем иде ул?» – ди. Кем булсын, мин инде. Су китердем дә, эшкә барырга чыктым, дим. «Син солдатлардан да уздырасың икән», – дип баш чайкый. Шунсыз булмый, безне эшкә йөртүче машина китеп бара бит. Тиз киенүе кыен түгел, кеше янында үзеңнән ферма исе килсә кыен. Чәчемә ис сеңмәсен өчен башта башлык киям, аннары яулык, аннары калын шәл ябам – иртән беренче булып директор янына керәсе бар бит…» – Рәмилә ханым ул чакларны искә алып,

«Нинди генә идеям булса да, ирем, юк, ди икән, аның белән ризалашам. **Ул фатиха бирмәсә, уңышлы чыкмый».**

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

«Бизнес – тауга менү кебек. Менә бу үрне генә менәм дисең дә, аның артында тагын үр булуы ачыклана».

әле көлемсери, әле көрсенеп ала. «Кайчак үзебезне ачуланып та куям. Башта ферма ачыйк, дидек. Шуның белән канәгать бул гына бит инде. Юк! Балтачтан авыр йөк токымлы 5 ат алып кайттык. Токымлы атлар үрчетәсебез килгән иде. Ләкин айгырын таба алмадык, атлар бик нык симерде, сатарга туры килде. Берсе-берсе 9 центнер иде».

Араннарны карап йөргәндә, тайлар рәтенә килеп чыктык. Барлыгы 38 баш. «Боларын иткә дип асрыйбыз, – дип аңлатып китә хуҗабикә. – Ат бик талымсыз хайван бит ул. Сыер-сарыктан калган бөтен азыкны ашап бетереп бара. Елкы итеннән ясалган казылыкларга да сорау зур. Әйдәгез әле, мин сезгә тагын бер нәрсә күрсәтәм, – дип, яңа гына төзелеп беткән тагын бер торакка әйди ул. – Казакъстаннан ук барып алып кайттык, – дип, көрдекле куйларга ишарәли. Арада Романов токымлы кара башлылары да чагылып ала. Сарык та асрый башлаганнарына әле ике генә ел. «Сарык – тере суыткыч бит ул. Ит кирәккән саен бер үгез ега алмыйсың. Корбан бәйрәменә дә сорыйлар, башка вакытта да алалар, сатылмый калганнары юк», – дип аңлата хуҗабикә.

Аранның аргы башыннан яшь бала тавышы белән кәҗә бәтие бәәлдәп куя. «Минем тавышны ишеттеләр. Монда яңарак кына менгездек, әлегә кадәр ихатада иделәр», – дип, бәләкәйләрнең башларыннан сөеп ала апалары. Аннары безнең сораулы карашларыбызны күреп, җавабын бирергә ашыга: «Оныклар өчен асрыйбыз. Кәҗә сөте файдалы. Берне генә алган идек, 18 баш булдылар әнә». Шулай итеп, сүз үзеннән-үзе гаиләгә, балаларга ялгана.

Ике кыз, бер ул үстергән алар. Гаиләдә бердәнбер булып үскән Рафаэль Минсәгыйрь улы зур гаилә, ишле бала-чага турында хыялланган. «Өч белән генә калдырдың, дип, кайчак үпкәләп тә куя», – дип көлемсери Рәмилә ханым. Кайнанасы белән – 21, кайната белән 31 ел гомер итә ул. «18 яшемдә – Канаш финанс техникумын тәмамлауга, килен булып килдем. Әни янында 15 яшемдә чыгып киткән кыз бит, кияүгә чыкканда бер эшне дә юньләп белми идем шул. Барысына да кайнанам өйрәтте. Кирәксә, сүгеп, кирәксә, сугып та алды. Берсенә дә үпкәләмәдем, аның каравы, хәзер авылда кирәкле бар эшне дә эшли беләм», – дип, кайнанасын хөрмәт белән искә ала ул. Үз әнисе Әлфия апаның исәнлегенә куана, килене белән киявен яратып телгә ала. Гадәти генә авыл йортында 12 кеше: улкызлары, килен-кияве, оныклары белән көн күрә Щукиннар гаиләсе. Дөрес, барысының да үз фатирлары бар шәһәрдә, тик аларның нәкъ менә монда яшиселәре, нәкъ менә үз хуҗалыкларында эшлиселәре килә. Балалары – әти белән әниләренең төп ярдәмчеләре, аларның эшен дәвам итүчеләр. Бөтен эш үзара бүленгән монда. Бухгалтерияне Рәмилә ханым үзе алып бара. Олы кызлары Гөлчәчәк белән кияүләре Рамил бал кортлары һәм сәүдә өчен җаваплы, уллары Риназ өстендә – терлекләр. Кече кыз Гөлназга завод эшчәнлеге йөкләнгән. Рафаэль Минсәгыйрь улының вазыйфасы тагын да җаваплырак, ул – председатель, 250 кешелек кооператив белән рәислек итә.

Авыл хуҗалыгы куллану кооперативлары төзү – Татарстанда авыл хуҗалыгын үстерү буенча өстенлекле юнәлешләрнең берсе. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматларына караганда, хәзер республикабызда 273 куллану кооперативы эшли, аларның 45 е быел оешкан.

Кайбыч районы Чүти авылындагы «Йолдыз» кооперативы исә 2018 елның октябрендә теркәлә. Беренче мәлдә аңа 3 крестьян-фермерлык хуҗалыгы (аның берсе Рәмилә ханымныкы) һәм 13 хосусый хуҗалык кергән булса, бер елдан кооператив – 5 фермер, 255 хосусый хуҗалыкны берләштерә.

«Элеккеге кебек, боты белән ит сатып алучылар сирәк хәзер. Халык беткәннән-беткәнгә яңа суйган ит сатып алуны кулай күрә. Әле сөтне сөт заводларына





тапшырып булса, итне урнаштыру кыенлаша, – ди Рәмилә ханым. – 2015 елны без сугым цехы булдырдык. Анда үз хуҗалыгыбызда үстерелгән терлекне генә түгел, тирә-як авылларның хуҗалыкларыннан китерелгән малларны да чалып, эшкәртеп бирәбез. Идел аръягында ачылган беренче сугым цехы – безнеке. Шундый шартларыбыз була торып, чи ит белән генә сату итәсебез килмәде, узган елның декабрь аенда эшен яңа башлаучы авыл хуҗалыгы куллану кооперативларының материаль-техник базасын ныгыту программасы нигезендә, 5 миллионлык грант алдык». Фермага якын гына салынган, тирә-ягы асфальт, әйләнәсе коймалы завод – әнә шул грантны кулланып булдырылган. Гомуми бәясе 9 миллион 600 мең булган әлеге модульле заводны быелның апрель аенда эшләтеп җибәргәннәр. Егәрлеге көненә 500 кг ит эшкәртергә җитәрлек. Әлегә монда алты кеше көн саен 200 килограмм иттән берничә төрле казылык, пилмән, ике төрле котлет, ике төрле тутырма, голубцы, ит чумарлары ясый, махсус мичтә каз-үрдәк, тавык ыслана. Ә иң әһәмиятлесе – барысы да «Хәләл» сертификаты нигезендә җитештерелә.

– Кайчак уйлап та куям: бөтен гомер эш белән үтте. Казанда фатирыбыз бар, олыгайган көнебездә ник шунда тыныч кына, рәхәт кенә яшәмәскә инде, дим. Шулай дип уйлыйм да, Гөбнә елгасы буйлары, каршыбызда гына шаулап үскән урман күз алдыма килә. Яз җитсә, 200 баш каз бәбкәсе алабыз һәм мин... «санаторий»га китәм, – дип көлә Рәмилә ханым. – Янәшәмдә – елга, каршымда – урман, баш очымда – тургайлар, янымда сары бәбкәләр – нәрсәсе белән санаторий түгел?

Аннары бераз уйланып тора да, болай дип өсти:

– Бөтен акчаны да эшләп бетерү мөмкин түгел, вакытында туктала да белергә кирәк. Нәфескә чикләр юк.

Щукиннарның киләчәккә тагын планнары бар әле – сөтне дә үзләре эшкәртеп сатарга ниятлиләр. Үз эшләренә керешкәнче, йөк машинасында ерак араларга йөргән Рафаэль әфәнде юл буенда тиз генә тамак ялгап ала торган кафе ачу турында да хыяллана.

Кем белә, бәлки... Ферма ачу турында да алар кайчандыр хыялланган гына булган бит әнә...







Ренат МАМАЕВ, «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы кооперациясен үстерү буенча компетенцияләр үзәге» директоры урынбасары

Кооперативларга берләшү идеясе яңа түгел. Революциягә кадәр үк Россиядә 46 меңнән артык кооператив берләшмәсе эшләгән. Бүген бу тәҗрибәне чит илләр дә киң куллана. Әйтик, Финляндиядә сөтнең 95 проценты авыл хуҗалыгы кооперативлары аша сатыла.

Бездә дә авыл хуҗалыгы эшмәкәрлеген үстерү өчен әлегә бу – бердәнбер юл. Әлбәттә, мондый эшне дәүләтнең булышлыгыннан тыш кына башкарып чыгып булмый. Ярдәм булмаса, бу процесс ким дигәндә 50 елгача сузылачак. 50 ел эчендә авылда яшәүчеләрнең уртача яше алтмышны узып китә. Шушы биш-алты ел эчендә авылда эшләүчеләргә табыш алу юлларын күрсәтә алмасак, киләчәктә җирләребезгә хуҗа табу өчен күбрәк көч түгәргә туры киләчәк. Үзебез хуҗа булмасак, җирләребезгә башкалар хуҗа була. Шуңа да кооперацияләр идеясе – стратегик идеяләрнең берсе.

Һәр кооператив үзенә күрә – уникаль. Ул авылда җитештерүченең ихтыяҗларына нигезләнеп төзелә. Әйтик, быел фермерлар бәрәңгеләрен сата алмый, аны сакларга урын кирәк. Бер генә хуҗалыкка яшелчә саклагыч төзү артык чыгымлы булыр иде. Аны берничә кешегә берләшеп салу отышлырак. Сөт сатучыларга да кооперативка берләшү кулайрак. Хуҗалыктан җыелган сөтнең литрына бүген 15 сум түлиләр. Ә суытылган һәм бер урында тоннадан артык тупланган сөтнең литрын 22 сумга сатарга була. Моның өчен суыткыч кирәк, ә ул арзан тормый.

Авыл хуҗалыгы кооперативларына берләшүнең өстенлеге бар, әлбәттә, ләкин ул һәр кешегә дә отышлы һәм табыш китерә дигән сүз түгел. Бу юл – алга таба да үз бизнесын үстереп, зуррак табышка омтылучылар өчен. Шул ук сөтне кооперативлар аша сатканда, бәясе кыйммәтрәк, чөнки кооперативларның җитештергән сөтне кибет киштәсенә кадәр китереп җиткерү мөмкинлеге бар. Ә кибеттә сөтнең бәясе җәй дә, кыш та бертөрле.

Кооперативларга һәм кооперативка берләшергә теләүчеләргә дәүләт ике яклап матди ярдәм күрсәтә. Беренчесе – республика бюджетыннан 5 миллионга кадәр бирелүче грант. Ул яңа оешучы яки теркәлүләренә 12 ай булып җитмәгән кооперативларга бирелә. 10–12 процент үз өлешеңне дә кертеп, бу грант акчасына транспорт, техника, эшкәртү җиһазлары алырга мөмкин.

Моннан тыш, федераль үзәктән дә ярдәм бар. Мәсәлән, кооператив әгъзаларыннан җыелган авыл хуҗалыгы продукциясе бәясенең 10–15 проценты субсидия буларак кире кайтарыла. Шулай ук кооператив әгъзаларына сатып алынган мал-туар бәясенең 50 процентын дәүләт түли. Техника, транспорт, эшкәртү җиһазлары алганда да ярдәм күрсәтелә.

ОБЪЕКТИВ АША... ЯКИ ФОТОГРАФНЫҢ КҮРГӘННӘРЕ



Фото: www.pixabay.com

Бәйрәмнәрдәге фотоларны барлап утырганда күңелгә гел бер уй килә: кешегә нигә соң бу кадәр фотосурәт? Туйдан, гадәттә, 500–600 фото сорап алалар, юбилейлардан 100–200 фотосурәт бирергә туры килә. Менә, сез, быел төшкән иң кадерле фотогызны хәтерлисезме? Аңа ничегрәк әзерләнгән идегез? Кайда сакларга телисез?

Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Бу тәҗрибә мине дөньяга объектив аша (ә ул дөньяны бөтенләй башкача күрсәтә!) карарга өйрәтте.

Элегрәк минем күзаллауда фотограф образы ул ир-ат иде. Бераз гына сакаллы, иңсәсенә төрле техника, фотоаппаратлар аскан, фәлсәфи карашлы… Замана тиз үзгәрә. Хатын-кызларның да күбесе фотога төшерү белән шөгыльләнә башлады. Фото – дөньяның бер кәсебенә әйләнде. Элек халык фотосалоннарга чират торса, хәзер фотографлар төрле мәҗлес-бәйрәмнәрнең алыштыргысыз бер кешесе бүген.

Инде берничә ел мин үзем дә фотога төшерү белән шөгыльләнәм. Бу һөнәрне декрет ялы чорында үзләштердем. Яшь әнинең төрле мәшәкатьләренә өстәп, кулга фотоаппарат тотып чыгып китүләр кирәк идеме, дип сорыйсызмы? Моңа чаклы һәр яңалыкны белеп торган, күп аралашкан, сөйләшкән әни кешегә менә шундый мохит, аралашу, яңа танышулар, вакыйгалар үзәгендә кайнау мөһим иде!

Балама яшь ярым булганда фотокурска язылдым. Ул вакытта әле без иремнең эше буенча ерак бер районда яши идек. Һәр якшәмбе гаилә белән төялеп Казанга киләбез. Пырдымсыз кызымны әтисе белән калдырып, дәресләргә кереп китәм. Өч сәгатьне ничек тә түзәләр! Атна буе фотоаппарат һәм нәни кызым белән мәш киләм. Композиция, экспозиция, яктылык темаларына өй эшләрен тапшырганда минем фотосурәтләрдә һаман бер герой – нәни кызым, бер үк төрле реквизитлар – бала киемнәре, уенчыклар чагыла иде. Күзләр очкынланып янганда, дөньяның бар матурлыгы объектив аша күренгәндә хатын-кызга берни дә комачаулый алмый икән ул! Йокысыз төннәр һәм бала мәшәкатьләре дә хәтта!

Ул көннәрдән бирле нинди бәйрәмнәрдә генә булмадым да, нинди хәлләр белән генә очрашмадым. Сезнең белән дә фотограф күзәтүләремне бүлешим әле!

«Сезне ир белән хатын дип игълан итәм!»

Фотокурсны узып, ярты ел тәҗрибә туплаганнан соң, туй төшерергә чакырдылар. Мин төшерәчәк беренче туй! Кышкы юлга челтәр боз каткан февраль ае иде ул. Яшь кенә бер пар өйләнешә. Ммм… килен буласы кеше көмәнле дә бугай әле. Кияү кеше гаилә корып яшәү өчен шактый «сыек» күренә. Апалары, бар көчләрен куеп, туй оештырган. «Сезне ир белән хатын дип игълан итәм!» ЗАГСта рәсми язылышу процессы бара. Әлбәттә, мин бөтен тырышлыгымны куеп, яшь гаиләнең мөһим мизгелләрен «тарихта калдырырга» тырышам. Уңгарак кара, бер адым алга, елмаябыз… Бер мәлдә минем бу командаларым көйсез кияү егетенең күңеленә шулкадәр тиде-е-е! Ул ЗАГС ишеген шап итеп ябып чыкты да китте! ЗАГС бүлмәсендәгеләрнең шок хәленә килүен, уңайсыз тынлыкны, аннары иптәш егетләренең кияү артыннан йөгереп, аны җайларга тырышулары, кыз ягының шау-шу куптаруы… юк, юк, берсе дә онытылмаган әле. Соңрак, бар да җайланып, бу туйның фотолары өчен күп рәхмәтләр ишетсәм дә, минем өчен ачы тәҗрибә булды ул.

Гомумән, кем әйтә әле туйда фотографка җиңел дип? Хисләр тулышкан мизгелдә кабынып киткән капризларны хәл итеп куярга да, туйдагы психологик киртәләрне җиңәргә дә, кәләшнең киңәшчесенә әйләнергә дә, туй күлмәгенең җебен бәйләү җаен белергә дә, оештыру эшләрендә катнашырга да туры килә кайчак фотографка. Иң авыры – төшерәсе кешеләр белән арадагы барьерны җиңү. Әлбәттә, башта бәйрәмне оештыручы хуҗабикә белән уртак тел табарга тырышасың. Һәрвакыттагыча, барысы да хатын-кыздан тора бит! Тагын бер сер бар: туй төшерергә килдеңме, иң усал кешенең күңелен яуларга кирәк. Аның күңеленә хуш килсәң – эшең дә уңа, чәйсез дә калмыйсың. Сыналган алым!

Чынлыкта, туйларның төрлесе була: бик яратышып кавышучылар, яшь җиткәнгә гаилә коручылар, берәве – яратып, икенчесе бу адымга ник барганын аңламаучылар, кирәк булганга өйләнешүчеләр… Тагын бер хәл искә төшә: билгеләнгән туй көне килеп җитәргә күп калмаган иде, егет белән кыз шактый каты ачуланыша. Туйны өзәр дәрәҗәгә җитә болар… Аларны җайлап, дуслаштырып ничә кич узды икән! Туй булды, Аллага шөкер!

…Ә бервакыт туй буласы көнне иртән көчле яңгыр явып узды. Шулай да, әйләнгечтән озакка китә дип, егет кызны алырга барганда туй машиналарын кыр юлыннан гына алып китте. Кәләш яши торган авылга бер-ике чакрым кала, беренче барган машина төпкә утырды. Кияүнең дуслары җан фәрманга этеп, тартып карасалар да, авыл бизнесменыннан алып торган ак джипны баткаклыктан чыгара алмадылар. Башкача чара калмады инде, кәләшнең тракторчы әтисенә шалтыратып, ярдәм сорарга туры килде. XXI гасыр фотографлары да шундый хәлләр белән очраша!

Һәм!.. (бу урында дәһшәтле барабан тавышы булырга тиештер!) Һәр фотографның «янган» фотозаказы була. Безнең дә булды ул… Салкын гыйнвар ахыры иде. Бу никахны төшерергә тормыш иптәшем белән бергә барырга булдык. (Фотога төшерү – күптән уртак проектыбызга әйләнде!) Ныклап әзерләндек, реквизитлар алып килеп, бакчада фотофон оештырдык. Фотосессия ясаганда борыннар кызарды, кул чуклары өзелеп төшәрдәй булып туңды. Ул көнне без шактый соң кайттык. Икенче көнне иртән торып,

Банкет залы буйлап җилфердәп узып барганда кадр ауларга чыккан фотографны таптап китмәвегез сорала!

төшергән материалны компьютерга күчерик дисәк... фотоаппаратның «хәтер картасы» бернәрсә дә күрсәтми! Ниләр генә эшләп карамадык та, кемгә генә күрсәтмәдек без аны. Нәтиҗәсез. Ахыр чиктә яшьләрдән гафу үтенеп, күңелсез яңалык әйтергә туры килде. Шул чактагы уңайсызланулар...

Туй төшерү аерым көч сорый шул. Андый вакытта фотографның көне иртәнге алтыда башланып, төнге уникеләрдә тәмамлану – гадәти хәл. Кулдан-кулга күчереп караган матур фотоларга фотографның күпме җан җылысы күчкәнен бик азлар гына аңлыйдыр.

Йоласыз бәйрәмнәр

Фотоаппарат күтәреп йөрү – керәшен халкына мәхәббәтемне уятты. Аларның бәйрәмнәрендә, туйларында еш булырга туры килде миңа. Бөтен авыл белән җыелышып бәйрәм итүләрендә үтә гадилек, үзенә бер ихласлык бар аларда. Менә 82 яшьлек Лиза апаның алтынчы оныгы өйләнә. Килен бирнәсендәге һәрнәрсә кулдан чигелгән! Олы апалар туйга вак тәңкәләр тезелгән күкрәкчәләр киеп килгән, мәҗлескә бөтен ыру чакырылган. Һәр кунак үз җырын әзерләп килә монда. Олысы-кечесенең күмәкләп биюләрен, рәхәтләнеп күңел ачуларын күрсәгез икән! Банкет өлеше авыл уртасындагы әллә ни зур булмаган таш бинада – элеккеге колхоз ашханәсендә узды. Беренче карашка, ашханә, күп дигәндә, 40 кеше сыярлык кебек иде. Ә кунаклар – йөздән дә ким булмагандыр! Юк, юк, гаеп итеш бөтенләй дә юк монда. Килгән кеше ашый-эчә бара, яңадан килгән кунакка урын биреп, биергә китә тора. Эскәмияләр шомара, кашыклар ялтырый, халык көлешә-җырлаша – барысы да шундый бәхетле! Затлы ресторан-нарда да күп төшердек, әмма бу авыл ашханәсендәге туй кебек күңеллесе булдымы икән?! Заллар кыйбатрак булган саен, мәҗлесләр корырак уза бугай ул...

Килен төшерү, кыз елату, акча чыңлату кебек элеккедән килгән йолаларның күбесе сакланган керәшеннәрдә. Йолалар дигәннән... татар халкында да туй йолалары бик күп булган бит ул. Онытыла гына баралар. Килен төшергәндә ишек төбендә бал-май каптыру, урамда аркылы җеп белән туй машиналарының юлын «бүлү», бала-чагага конфет, вак акча сибеп калдыру... Күпчелек очракта менә шулардан ары узмый. Беләсезме, йолаларның онытылу сәбәбен нидә күрәм?! Без бөтен бәйрәмнәрне дә тамадалар кулына тапшырып бетердек. Һәркем алар оештырган бәйрәмгә риза булып, тамадалар куйган тамашаны карап утырырга ияләште. Ә тамадаларның сценарийлары бертөсле, кунакларның исемнәре генә үзгәрә. Алып баручы авызына карап, бергәләп өстәл артында «Күбәләгем»не җырларга да җае чыкмый кала. Ә бит гомергомергә һәр нәселнең үз җырчысы, гармунчысы, оста итеп сүз сөйләүчесе булган. Менә шул кешеләр югалып кала. Кешедән ким булмаска дигән фикер кешегә яшәргә комачаулый. Хәтта бәйрәмнәр уздырганда да!

Яшь парларның үз гаме – фотолар социаль челтәрләргә куярлык булсын, башкаларныкыннан ким чыкмасын! Ерак араларны якын итеп кайткан туган-тумача, кечкенәдән карап үстергән әбибабайлар, бәйрәмнәрдә генә җыела торган кардәш-ыру белән фотога төшәргә кыстап йөри башлагач, кайчак миңа сәерсенеп карыйлар. Ә бит туй фотолары – яшь гаиләнең фотоархивына нигез салу булырга тиеш.

Йөрәк белән сизсәң генә...

Белсәгез икән объектив аша... дөньяның бөтенләй башка яктан ачылганын! Гаилә мөнәсәбәтләре дә, туганнар дуслыгы да, гаиләнең җәмгыятьтә тоткан дәрәҗәсе дә күренә анда. Минем фотоаппаратның тагын бер сәер ягы бар: кешеләрне битлекләрсез генә төшерергә ярата ул. Менә юбилейда тәнәфес вакытында бер пар килеп фотога төшерүне сорый. Күзләр, иңсә торышы, куллар... Вуаля! Бәхетле пар! Икенче берәүләрне бер-берсенә һич якын китереп булмый, югыйсә 30 ел бергә яшәгәннәр бит инде! Менә гаилә фотосы. Ир кеше, бөкрәеп, артка елышкан, уртада – ут чәчеп торган хатын һәм кимсенгән кыяфәтле балалар... Зәһәрлеге йөзенә чыккан апа, усал дип йөртсәләр дә, күз карашына мәгънәле тормыш кырыслыгы сеңгән юбиляр, мут күзле ир... Югыйсә бәйрәмдә бөтен кеше дә матур һәм шат күренә! Кайчак фотоаппаратта «бәхетле йөзләр» төймәсе булдырасы килә килүен.

Ә бәйрәмнәр бертуктаусыз дәвам итә! Иң шәп кадрны бозып, көтмәгәндә конфетти кәгазьләре оча, күккә салютлар сузыла, дискотека утлары йөзләргә төшә...

P. S. ...Йорт кырыендагы рәшәткәгә сөялгән дә эти кеше олы юлга төбәлгән. Баласын читләргә биреп җибәрү әчесеннән мөлдерәп чыккан күз яшьләре аша юлда тузан купканны, төсле итеп бизәлгән машиналар өере килгәнне көтә ул...

...Туй ыгы-зыгысы башланырга шактый иртә әле. Аулак бүлмәдә, ап-ак туй күлмәге кигән кәләш, аның белән бу шатлыгын бүлешә алмаган, дөньядан бик иртә киткән әнисенең фотосын күкрәгенә кочып, иңрәп елый...

...Артык юаш улы өчен борчылган әнинең кулыннан эше төшкән. Өстәл әзерләргә дип йөгереп йөргән туганнарының сорауларына да төгәл җавап бирә алмыйча гаҗиз булып йөри...

...Бәйрәмгә җыенган һәр өйдә менә шундый нәни тарих, нечкә бер мизгелләр була. Аларга инде объектив аша карап булмый, йөрәгең белән сизсәң генә...

ФОТОПРОЕКТ: «ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Ситора ЗАХАРОВА кызы Сафия белән. Фото: Лилия ГАЛИЕВА. Казан.

Бер мизгел.
Фоторәсемгә әйләнгән бер мизгел.
Ана белән Баланы кабат-кабат үткәнгә: шушы көнне, шушы сәгатьтә кичергән Бәхеткә, ул чактагы хис-тойгыларга алып кайтачак әле ул. Әни – җир йөзендәге иң кадерле кеше дип искәртеп торачак. Шатлыкларыңа аның кебек сөенүче башка берәү дә булмаячак, борчу-хәсрәтеңне ул гына үзенекеннән зуррак итеп кабул итәчәк. Аңлаячак, кичерәчәк, канат куячак... Яратачак! Бернигә карамый! Гомер буе...
«Объективта – әни» конкурсы тәмамланды, әмма проектыбыз дәвам итә.
Фотосурәтләрегезне көтәбез: гомер альбомындагы ул мизгелне безнең белән дә бүлешегез!
Иң уңышлы эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк.

БЕРДӘНБЕР

Яшьлектә ике арада кабынган якты хисләрне – мәхәббәтне гомер буена саклап калган парлар күп түгел. Әмма очрыйлар! Күз карашларыннан таныйсың аларны. Ул карашларның җылылыгыннан. Бер-берсенә караганда күзләрдә балкып алган яктылыктан, нурдан...
Азнакайда гомер итүче Юлира һәм Рафаил САДРИЕВлар – шундый сирәк парларның берсе. Бу язмада аларның гаилә бәхете серләрен ачабыз.


Фото: Анна Арахамия

– Мин бик кызу кеше... Сөт кайнаганын янында басып көтеп торырга да түземлегем җитми. Ул арада әллә никадәр эш эшләргә була бит. Йөгереп йөрсәң нигә булмасын?! Нидер эшләп, кире әйләнеп килгәнче, сөтемнең кайнап ташыган чаклары да бихисап инде анысы...

«Рафаил белән танышканчы, берәү белән дә очрашканым булмады. Тирә-юнемдә бер егет тә юк иде. Бәлки, мин аларны кызулап узып киткәнмендер», – ди ул уенынчынын кушып.

Алар Урыссу мәктәбендә укыганда танышалар. Чаңгы ярышына катнашырга баргач, Рафаилнең күзе күрше сыйныфта укучы Юлирага төшә. Әмма ул чактагы танышлык ике-өч сүз алышудан узмый. Егет тәвәккәлләгәнче яз килеп җитә, чыгарылыш имтиханнары башлана. Аннан инде юллар икесен ике якка алып китә...

Ә бер көнне Юлирага хат килеп төшә. Солдат хаты. Рафаилдән! Баксаң, һаман да күңелендә йөрткән икән... Җаен тапкан: сеңлесе Римма аша кызның адресын эзләтеп алган. Аралар шулай ялгана. 1971 елның мае була бу. Калганын инде вакыт хәл итә... Юлира ханымның, үзе әйтмешли, «инструкция буенча яши башлавына» быел җәй инде менә кырык биш ел тулган. Нигә инструкция буенчамы? Ирең озак еллар «куркынычсызлык кагыйдәләрен саклау» бүлеге начальнигы булып эшләгәч соң! Ул кагыйдәләр күптән инде эш урыныннан көндәлек тормышка да күчкән. Газ сүндерелгәнме-юкмы икәнен тикшермичә беркайчан өйдән чыкмыйлар, куркынычсызлык каешын эләктермичә машиналары кузгалмый. Башкалар бакчадагы чүпне яндыра – алар юк. Чөнки куркынычсызлык кагыйдәсе буенча ярамый! Тиеш түгел! (Юлира ханымның: «Менә шундый кысаларда яшәп ятам!» – дип «зарлануы» яратудан гына ла. Югыйсә шуның артыннан ук: «Дөньяда ике намуслы кеше булса, аның берсе – минем Рафаил!» – дип өстәп куяр идеме?!)

Башкортстанның Октябрьск шәһәрендә нефть институтын тәмамлаган Рафаилне «Актүбәнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә



Гаиләдә берәр борчуыбыз булса: «Бу безне берәр олы борчудан коткаргандыр», – дип уйлыйбыз. Авыррагыннан...

юллама белән эшкә җибәрәләр. Килеп төшүгә гаилә башлыгына бер бүлмәле фатир ачкычы тоттыралар. Инде биш ел буе кеше почмакларында торып шактый интеккән Юлира белән Рафаилгә бәхетнең үзе булып тоела ул. Энә кайда – җеп шунда. Башта Мәскәү технология институтында белем алган, аннан Октябрьск нефть техникумы дипломына ия булган Юлираның да хезмәт юлы нефть тармагына бәйләнә.

– «Актүбәнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә эшкә 1979 елның 1 ноябрендә килдем. Айның беренче числосы план бүлеге өчен аеруча мөһим бер көн ул. Бу көнне үткән айны ябалар: мең төрле урынга мең дә бер төрле отчет бирелә. Һәм ул ай саен кабатлана... Килеп кердем бүлеккә. Күреп торам – эшләре шулкадәр тыгыз. Уңайсызланып та калдым. Әмма бүлекнең ул чактагы начальнигы Рөстәм Разих улы Хәйруллин вакыт табып, мине кул астындагы хезмәткәрләренә тәкъдим итте. Ул чакта «статотчет»ны кулдан язып, билгеле бер сәгатьләрдә Әлмәткә «Татнефть»кә, Казанга җибәрә идек. Миңа да шул отчетны күчерергә бирделәр. Күчереп бетергәч, бүлектә аны берсе кычкырып укый, калганнар һәр цифрны тикшереп бара. Җаваплылык бик зур – бер хата да китәргә тиеш түгел...

Бөтен нәрсәдә дә тизлек яраткан Юлира ханымның хезмәт юлы башыннан ахырына кадәр ашыгу-кабалануны һич тә өнәмәгән саннар, цифрлар арасында узуын күз алдына китерү кыенрак, билгеле... Әмма чынлыкта – бу шулай. Бүлек ишеген кыюсыз гына ачып кергән яшь ханым тора-бара аның әйдәп баручы белгеченә әйләнә.

– Әкрен эшләү әйбәтме икән, әллә тиз эшләүме, дип гел уйлый идем. Берсендә кулыма шушы хакта язылган язма эләкте. «Тизрәк эшләсәң, ялгыш киткән очракта аны төзәтергә вакытың булачак», – дигәннәр. Минем хакта дип укыдым моны...

Яшь гаилә Азнакайда ныклап төпләнергә өлгерми, нефть һәм газ чыгару идарәсе аппараты Актүбәгә күчә. Идарәгә ияреп, Садриевлар да күчәнә. Мәшәкатьле, әмма күңелле еллар була ул: бер-бер артлы туган ике бала үсә, мәктәпкә керәләр; йорт төзиләр («Актүбәнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе ул чакта теләгән бөтен кешегә дә монолит йорт һәм аны төзеп бетерү өчен ссуда бирә. Хезмәт хакы исәбеннән төзелеш кирәк-яраклары алырга мөмкинлек тә тудыра. Һәр гаилә өчен зур ярдәм була бу! Туксанынчы еллар башында, кибет киштәләре бушап калган вакытта да, идарәнең кайгыртуын һәрдаим тоеп яши нефтьчеләр: айлар буе хезмәт хакы түләнмәсә дә, алар өстәленнән ит, сөт-май өзелми.)

Ә аннан 1996 елда ике идарә кабат бергә кушыла: Рафаил белән Юлира да тагын Азнакайга әйләнеп кайталар. Бу юлы инде – бөтенләйгә.

– Бер дә авырсынып күченмәдек, эшебезгә якын булсын дидек. Икебез дә эшебезне яратып эшләдек. Шул очракта гына алган хезмәт хакыңның да куанычын күрәсең. Иртән эшкә сөенеп бару, кичен канәгатьлек белән өйгә кайту ярты бәхет бит ул...

Әйе, идарәләр кушылды, без «дело»ларыбызны күтәреп Азнакайга кайтып төштек. Борчылабыз. «Ничек каршы алырлар?» – дибез. Гел онытмыйм, Вәсилә безне каршыларга дип беренче катка ук төшкән иде... Бүлектәге кызларның иң күркәм сыйфаты – кешелеклелек булды. Без бик тату эшләдек! План-икътисад бүлегенең бер үзенчәлеге бар: безнең эш икегә – «ашыгыч»ка һәм «хәзер үк кирәк»кә бүленә. Син күмелеп нindидер отчет эшләп утырганда, шалтыраталар, бөтенләй башка цифрлар сорыйлар, «Тиз кирәк!» – диләр. Шундый вакытларда, башлаган эшемне бүлектәге кызларның теләсә кайсына биреп, «хәзер үк кирәк» дигән эшкә тотына идем. Лаеклы ялга чыккач кына уйладым, берсе дә: «Юлира Әмирҗановна, сезнең бит разрядыгыз зуррак, бәлки үзегез генә эшләрсез», – димәгән. Эшне синеке, минекенә бүлмәгән. Мин аларга хәзергәчә рәхмәтле. Венерага, Рәмзиягә, Резедага... Идарәнең бар цифрлары бергә тупланган бүлек иде бит. Һәм ул цифрларның теләсә кайсы җитәкчегә һәр минутта кирәк булуы мөмкин. Һәр эшнең үз нечкәлекләре... План бүлегендә норматив, положение дигән төшенчәләр бар. Ай азагы җитсә: «Нинди факт көтелә?» – дип сорый башлыйлар. Планлаштырылган чыгымнар билгеле, ә чынлыкта күпме булачак ул? Моңа амортизация дә керә, хезмәт хакы да, капиталь ремонт та. План белән факт аерылырга, факттагы чыгымнар планлаштырылганнан артырга тиеш түгел. Һәр ай ахырында: «Шул кысалардан чыкмасам ярар иде», – дип борчыласың. Әгәр нормадан чыгасың икән, «Азнакайнефть»кә премия түләнми. Унөченче хезмәт хакы да шуңа бәйләнгән. Зур җаваплылык! Ялгышудан курку бар иде инде. Алай-болай ялгыш цифр китсә, артыннан йөгереп барырдай буласың. Шөкер, тирә-юнемдә гел хәлгә керә белә торган кешеләр эшләде.

Саннарны, цифрларны бик яраттым. Һәрберсе нәрсәдер өчен җавап бирә, һәркайсы артында кемдер бар сыман... Тере кебекләр! Төшләремдә әле дә отчет тапшырам...

«Эш урыным һаман да икенче туган йорт, ә элеккеге хезмәттәшләрем туганнарым кебек», – ди ул. «Азнакайнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе исә аларны очраштыру, күрештерү өчен сәбәп чыгарып кына тора: йә нефтьчеләр көнен бергә бәйрәм итәргә чакыра, йә ветераннарын җыеп, автобуска утыртып Казанга, Болгарга, Зөя утравына ял итәргә җибәрә, йә алар өчен Ижевск каласына сәфәр оештыра.

– Гаиләңдә тынычлык булса гына эшеңдә онытылып, бирелеп эшләп була...

Әңгәмәбез кабат гаиләгә килеп тоташа.

Рафаил – минем иң беренче егетем, иң беренче ир-атым булды. Мин дә аның өчен бердәнбер дип уйлыйм.

«Кырык биш ел узганын сизмәдек! Әле яшәмәдек тә кебек...» – ирле-хатынлы икесе дә беравыздан шулай диләр. Тыңлавы рәхәт аларны!

– Тату гаиләнең сере? Мәхәббәттер... Ансыз алтыннарга күмелсәң дә, тормыш тормыш булмыйдыр.

– Йортта кем хуҗа? Ул да, мин дә... Бездә андый бүленеш юк. Мин аның инструкцияләрен тыңлыйм, ул да мине тыңлый...

– Акча уртак безнең... Бер-береңә ышанырга кирәк!

– 45 яшьләр тирәсендә берара дөньяны туктасы килде минем. Шул бәхетле хәлендә генә саклыйсы: гаиләм бөтен, балаларым үсә, эшем бар... Әмма аннары да тормышта бик кызык мизгелләр булды. Балалар үсеп җиткәч, белем алгач, башлыкүзле булгач... Мин әле килмәгән киленемне, кияүне яраттым. Көтеп алдым! Минем балаларымны да алар сайлаган ярларның әниләре шулай көтеп алсын дип уйладым. Кеше балаларын хурлаганны яратмыйм. Нишләп синеке генә әйбәт булсын да, аларныкы начар ди? Гаиләдә тавыш чыга икән, ике як та гаепле...

– Балалар, шөкер, ипле. Айдарның хатынына «килен» дигәнем юк. Минем үземә дә «кызым» дип кенә дәштеләр. Әти белән әни дә иремә бер тапкыр да «кияү» димәде. Әтиләр ул сүзне белмәгән дип уйлый идем... Кемдер: «Улым» дип тешне кысып әйткәнче, кияү диярргә генә кирәк», – ди. Ә мин рәхәтләнеп авыз тутырып «улым» дип әйтәм. Кызым Айгөлнең ире Маратны бик яратам!

– Рафаил абыеңның кәефе юклыгын кайдан беләмме? Сөйләшми ул. Болай да аз сүзле кешенең сөйләшмәвен күз алдыңа китер инде... Барыбыз да күп белә, үз сүзебезне бирәсебез килми бит – әйткәләшәбез кайчак. Аннары икебез ике якка китә. Ике-өч сәгать йөрибез шулай. Шуннан артык тора алмыйбыз. Мин – бигрәк тә. Киләм дә кочаклап алам. Аның күңеле шундук эреп төшә...

– Гаиләне саклау өчен бер-береңне хөрмәт итү кирәк. Гел яратышып кына торып булмый... Әгәр ул һәрвакыт сүзеңә колак сала икән, нигә син дә аны тыңламаска тиеш? Мин аның бер яхшылыгына икеләтә яхшылык белән җавап кайтарам.

– «Син иртәрәк кайттың, нигә ашың өлгермәгән?», «Нигә аны түгел, моны пешердең?», «Нигә шулпаң тозлы (тозсыз) булган?», «Тәмле булмаган!»... Кырык биш ел эчендә Рафаилдән мондый сүзләрне бер тапкыр да ишетмәдем! Ялгыш та! Ул кайтып кергәндә аш пешеп чыкмаган чаклар булды югыйсә. «Әйдә, ипи белән чәй эчә торабыз», – дия иде... Кыздырган бәрәңге ярата ул! Аны көн саен ашарга да риза. Һәр бәрәңге телеме аерым кызарга, изелмәскә, бер-берсенә ябышмаса тиеш. Кайчак бәрәңге әрчеп куям да, аны үзе кыздыра. Үзе генә белгән серләре бар. Үсемлек мае, сыер мае, тагын берәр май куша. Лавр яфрагы, кара борыч... Тәмле була! Пешеп чыкканчы, яртысын үзе ашап та бетерә...

– Кайнанам бик иртә вафат булды. Рафаилнең сеңелләре гомер буе: «Син безнең әни урынына калган кеше», – дип йөрделәр...

– Оксананың безгә килен генә булып төшкән вакытлары. Берсендә миңа әйтә: «Әти белән сезнең мөнәсәбәтләргә караган саен сөенәм, Айдар да шундый булыр инде», – ди...

– Балалар безгә гаиләләрендәге проблемаларын сиздермиләр. Кызым 17 ел эчендә бер тапкыр да ире турында начар сүз әйткәне юк. Киңәш бирәсе килгән чаклар бик була. Яңа өйләнешкән вакытларында бер әйтеп карадым. «Әни, без үзебез уйларбыз, хәл итәрбез», – диделәр. Шуннан бирле үземне кысаларда тотам. Дәшми калам да, соңыннан гел сөенәм: «Әле дә әйтмәдем!» – дим. Бу – аларның тормышлары, нигә кысылырга?

– Яшьләрнең гаиләсе ничек булуы әти-әнидән дә күп тора. Без башта ук кода-кодагыйлар белән: «Балалар үзара килешсә, без ничек тә уртак тел табарбыз», – дидек. Азнакайдагы кодаларыбыз – Розалия һәм Фоат Галиевләр белән күптән туганнарга әйләндек инде...

– Балаларымны үз алдымда мактауларын яратам. Үзем исә аларны: «Бәхет-тәүфыйгыгыз артсын», – дип, йоклаганда гына сөя идем. Хәзер бу сүзләрне оныкларга әйтәм. Бишәү алар безнең: Тәлгат, Тимур, Кәрим, Булат, Карина.

Менә шулай. Һәрберсен кагыйдә итеп алып, үз гаиләңә күчерерлек.

Башкалар сокланырлык итеп яши алар. Кыш җитсә, парлап тау чаңгысында шуарга чыгып китәләр. («Таудан чаңгы белән шуып төшкәндә уйлар каядыр тарала – баш ял итә. Рәхәт! Кышны яратабыз, көтеп алабыз!») Яннарында гына парк – җәяү йөриләр. Юлира ханым инде биш-алты ел йога белән шөгыльләнә. Парашюттан да сикергән. Бассейнда йөзә – чордашлары арасында призлы урыннар яулый. Сәяхәтләргә баралар – үзләре өчен яңа дөньялар ачалар. Инде ун еллар элек лаеклы ялга чыккан Рафаил абый, ниһаять, эштән туктаган. Икесе дә өйдә хәзер, үзләре әйтмешли: «Тормыш яңа башлана гына!»

– Рафаилнең күңеле бик нечкә, яз җитсә: «Сыерчыклар килгән, әйдә, карыйсыңмы?» – дип керә бакчадан. «Күрдеңме, бөреләр ничек тулышкан? Тиздән яфрак ярачаклар», – ди. Аңа ияреп, шуларны карарга урамга чыгып китәм. Күңеле була инде...

«Мин бик кызу кеше. Туктап тору минем өчен бик авыр», – дигән Юлира ханым әйтә моны. Матур гаиләнең тагын бер сере, димәк, шушы – вакытында, кирәк урында туктый да белергә кирәк!

Ә күңел үзенеке дә бик нечкә. Рафаиленең солдаттан язган хатларын һаман да саклый әнә. Яшьлек хатирәсе, оныкларга ядкарь инде алар. Барысы да шул хатлардан башланган бит...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



МИЛЛӘТЕБЕЗ ЙОЛДЫЗЫ

Тарихта якты эз калдырган күренекле мәгърифәтче, татар хатын-кызлары өчен тәүге уку йортларының берсе – Бубый кызлар мәдрәсәсенә нигез салган педагог, Россия ислам дөньясында беренче казый Мөхлисә Бубыйның тууына быел 150 ел тулды. Истәлекле вакыйга уңаеннан октябрь башында аның туып-үскән ягы – Әгерҗе районындагы Иж-Бубый авылында «Мөхлисә Бубый – милләтебезнең якты йолдызы» дип исемләнгән төбәкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Дин әһелләре, галимнәр, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре катнашында узган абруйлы җыенны Татарстан мөфтияте, Әгерҗе мөхтәсибәте һәм Бөтендөнья татар конгрессы оештырган иде.

Җыенга килгән кунаклар иң әүвәл бертуган Нигъмәтуллиннарның аналары Бәдрелбәнат абыстай, улы Габдулла Бубый, меценат-сәүдәгәр Мөхәммәтҗан хаҗи Әхмәтҗанов җирләнгән Иж-Бубый авылы зиратында каберләрен зиярәт кылып, әрвахлар рухына багышлап дога укыдылар. Аннан мәгариф учагына әверелгән авылдагы тарихи биналарны карап-күреп, музей экспонатлары белән таныштылар. Фәнни-гамәли конференциядә чыгыш ясаучы галимнәр, әдипләр хатын-кызларыбызның җәмгыятьтә тоткан роле турында, мондагы тарихи биналарны файдаланып, халкыбызның милли-мәдәни йолаларын саклап, Иж-Бубый авылын киләчәктә зур бер үзәк итү кирәклеге хакында сүз алып бардылар. Әлбәттә, тарихи мирасны саклау, аларны киләчәк буыннарга җиткерү – исәннәрнең олы бурычы. Иж-Бубый авылының статусын билгеләү һәм аны туристлык маршрутына кертү зарурлыгы хакында кызыклы фикерләр яңгырады. Мөхлисә Бубый феномены турында халкыбыз, яшь буын күбрәк белсен, уйлансын, данлы исемнәр онытылмасын иде.

Татар дөньясын каплап алган калын караңгылык эчендә беренче шәмне күтәреп чыккан Бубыйлар – Гобәйдулла, Мөхлисә, Габдулла Нигъмәтуллиннар тырышлыгы белән элекке Вятка губернасы Сарапул өязендәге Бубый мәдрәсәсе Россия мөселманнарының гыйлем мәркәзенә әверелә. Мөхлисә Габделгалләм кызы җитәкләгән хатын-кызлар мәктәбенең (женское мусульманское училище) шөһрәте илгә-көнгә тарала. Татарлар яшәгән ерак төбәкләрдән – Төркестан, Сембер, Оренбург киңлекләреннән, Ташкент, Сәмәрканд, Әстерхан, Казан, Уфа калаларыннан яшь кызлар, баласын, асрауларын иярткән ханымнар килә. Укып, укытучы таныклыгы алып чыга алар. Укытучы-мөгаллимәләргә Бубый мәктәбе биргән таныклык Россиянең мәгариф органнары таный торган документ була. Төпле белем, гыйлем-мәгълүмат алган мөгаллимәләр милләт аналары булырлык аң-белемле зыялы затлар тәрбияләүне максат итә, шуның өчен күп көч куя.

Мөхлисә ханымны хөрмәтләп, шул чакта ук аны мулла-абыстай дип йөртәләр. Әмма 1911 елда патша хөкүмәте татар халкына белем бирә торган уку йортын тар-мар итеп, туздырып ташлый. Җитәкчеләрне, укытучыларны кулга алып, Сарапул төрмәсенә ябалар. Олау-олау китапларны, Бубыйлар язган дәреслекләрне урамда өч көн буе өеп яндыралар. Кызлар мәктәбен дә ябу, мөгаллимәләрне кулга алу белән янийлар. «Яман исем белән мәктәп ябудан, яхшы исем белән төрмәгә ябылу артыграк», дип каршы торырга тырышсалар да, 1912 ел башында бу мәгърифәт учагы да сүнә. Фаҗигале хәлләрдән соң, Мөхлисә ханым кызы Мөнҗия белән Троицк шәһәренә китә, тәрбиягә алып үстергән Наҗиясен кияүгә биреп өлгерә. Яушевлар варисы Габдрахман Әхмәров ачкан кызлар урта мәктәбе мөдире һәм мөгаллимә булып эшли, төрле фәннәрдән дәресләр бирә.

1917 ел 47 яшьлек Мөхлисә ханым тормышында кискен борылыш елы була. Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае уза. Шөһрәте илгә-көнгә танылган галимә-мөгаллимәне, съездда катнашмаса да, Үзәк Диния нәзарәтенә казый итеп сайлыйлар. Аны яклап, 307 делегат тавыш бирә. Ягъкуб Хәлили «Сөембикә» журналында: «Мондый хәлнең ислам дөньясында булганы юк иде әле. Ислам дәүләте исәпләнгән Төркиядә дә хатын-кыз казый күренгәне юк. Бу хатын-кызның изелүенә нокта куелуга, ирләр белән тигезлегенә дәлил», дип яза. Гаиләнең әһәмиятен күтәрү, ике, өч хатынлыкка каршы көрәш, халыкка гыйлем, тәрбия бирү... Диния нәзарәтендә егерме ел дәвамында ул башкарган хезмәтләрне санап чыгу мөмкин түгел. Изелгән, авыр хәлдә калган мескен хатын-кызлар яклау табуга өметләнеп, җәяүләп, йөзләрчә чакрым юл үтеп, Уфага – аңа килә. Кешелекле, абруй казанган казый, үзенең акыллы киңәше белән дә, кануннарга таянып та, һәркайсына ярдәм итәргә тырыша. Әмма... Авыр көрәш юллары үткән, баш-аягы белән игелекле эшләргә чумган фидакарь йөрәк – Мөхлисәне дә афәтле еллар аямый. 1937 елның 19 ноябрендә аны Диния нәзарәтеннән, секретарь булып эшләгән җиреннән алып китәләр. Башкортстан НКВДсы Өчлеге 1937 елның 30 ноябрендә Мөхлисә Бобинскаяны «атарга, шәхси милкен конфисковать итәргә», дип хөкем карары чыгара. Каргышлы еллар корбаны, хаксызга җәберләнгән шәхес культы корбаны буларак, аның исеме 1960 елның 23 маенда гына аклана.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

PRESSA

Һәр фоторәсемдә – бер язмыш

Әни... Һәркемнең Ватаны йөрәгендә булган шушы иң кадерле кешедән – Әнидән башланадыр. Газизләрдән-газиз заттан!.. «Сөембикә» журналында да әниләрнең урыны – аерым.

Бер ел элек, журналның редколлегия утырышы вакытында, Казан фоторәссамы Әлфия Бикмөхәммәтованың «Рәссам сәхифәсе»ндә дөнья күргән эшләре турында сүз чыкты. Туган ягының матурлыгын сурәтләгән фотолар арасында өлкәннәргә – ак яулыклы Әниләргә багышланган сериясе аерым урын алып тора иде. «Ә бит бөтен Әниләр дә шушылай итеп зурлауга лаек», – дип уйладык без. «Объективта – әни» проекты шулай туды.

Журнал укучыларыбыз бу тәкъдимне хуплап каршы алды. Иң гаҗәбе – һәр фоторәсем белән редакциягә яңа бер язмыш килеп керде. Бәйгедә катнашучы авторлар белән якыннан аралашкан саен, ул язмышларга яңа юллар өстәлде.

«...Сез бәйге игълан иткәнче күпкә алданрак төшергән фото бу. Туган нигез. Җәй. Әни ишегалдында мунча себеркесе бәйли... Шундый кадерле истәлек ул миңа. Яшәү мәгънәсе Әни белән булганлыгын аны югалткач кына аңлыйсың икән шул...»

«Сездә ничектер, ә безнең авылда әле мич бар! Әни бар! Җылы бар! Әниемнең кочагында оныгы – кызым бар. Нәсел дәвам итә! Бәхет шушы түгелме?!»

«Кәләш күлмәге кигән кече кызының әтисе белән вальс әйләнүен карап утырган Әниемнең күзләрендәге моңга, сагышка гаҗәпләнмәгез. Әти яңа гына авыр операция кичергән көннәр бу. Без инде аның диагнозын беләбез... Тагын бер ай узуга, инде аны югалтачакбыз. Өчәү бергә төшкән соңгы фотосурәт...»

«Әнигә: «Мин кияүгә чыгам!» – дип кайтып әйткән көн бу... Куаныч һәм сагыш кушылган көн. Әни елады да елады. «Нигә күз яшьләреңне түгәсең?» – дигәч, «Бәхеттән...» – дип җавап бирде...»

«Фотода мин өч балам белән бергә. Кулыма күтәргән кечкенәсен «Ходай бүләге» дип йөртәм. Мине ул җәйне елан чакты. «Тагын биш минутка соңарсагыз, коткарып булмый иде», – диде табиблар... Бу хәлләрдән соң аз гына вакыт үтүгә балага узганымны белдем. Бернинди «ярамый»ларга карамыйча Ул туды! Могҗиза белән бер иде бу! Әйе, Ходай бүләге!»

Ана бәхете турында иде бу фотоконкурс. Ана шатлыгы, ана сөенечләре турында. Аның безгә биргән Җылысы турында... Ярату хакында! «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы белән бергә оештырган бәйгебезнең иң матур ноктасы «Манеж» күргәзмәләр залында булды: конкурска килгән иң-иң уңышлы эшләрдән анда күргәзмә ачылды. Әниләр бәйрәме көне алды иде. Күңелләр болай да нечкәргән, аларга әйтәсе, ишеттерәсе килгән сүзләрдән тулышкан чак иде...

Күргәзмә ачылышында Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты Ольга Павлова, Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды җитәкчесе Нурия Һашимова, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева, күргәзмәнең спонсоры, Inwells компаниясе җитәкчесе Радик Даешев һәм башкалар катнашты. Җиңүчеләр аталды, аларга бүләкләр тапшырылды. 1 нче урынны алган Лилия Кашаповага (Алабуга) бүләкне – ноутбукка сертификатны «Казан Кремле» музей тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева тапшырды. 2 нче урын алган Рамилә Нотфуллина (Казан) бүләк планшетны «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Лариса Маликова кулыннан алды. Өченче бүләк – смартфон Үзбәкстанда, Ташкент шәһәрендә яшәүче Сәрвиназ Кәримовага китәчәк. (Бу урын сайтта барган тавыш бирүләр нәтиҗәсен исәпкә алып бирелде.)

...Фоторәсемнәрдәге Әниләр төрле. Кемдер әле яңа гына Әни булган – тәүге сабыен кулга алган, икенче Әниләр янәшәсендә буй җиткән ул-кызлары басып тора, өченче фотода – балаларын таратып бетереп, төп нигездә ялгыз калган Ана сурәтләнгән. Көләч, бәхетле, уйчан, моңсу, сагышлы, гамьле... Алар бар да Күкләр биргән иң зур вазыйфаны үтәгән – бала тудырган затлар. XX гасырның олы галиме Ризаэтдин Фәхретдиннең сүзләре хак: «Ана булу – бөек бер нигъмәтмуллык вә тиңдәше булмаган бер хөрмәттер».

Фото: Анна Арахамия
















Canon










КРЕМЛЬ... БОРЫНГЫ, БАЛКЫШЛЫ, БЕЗНЕКЕ!..



Эльмира ЗАКИРОВА

Зилә Рәхимҗан кызы ВӘЛИЕВА «Казан Кремле» музей-тыюлыгына директор итеп 2012 елда билгеләнде. Һәм бу эшкә ул яңа сулыш өргән кебек булды. Үзендәге әйбәт энергетика көчте. Һәрчак яңалыкка омтылучы җитәкче республикада бик билгеле шәхес! Исемле журналист, депутат, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, матбугат һәм мәгълүмат министры, мәдәният министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы рәисе... Зилә Рәхимҗановна һәркайсына нииндидер яңалык, иҗадилык, заманчалык алып килде, җылылык өстәде, камиллеккә иреште. Биредә дә шушы эш стиле сизелә. Алдан күрә белүе, зирәклеге, тәвәккәллеге, зәвыгы, затлылыгы, хатын-кыз дипломатиясе... Аннары электән үзе белән аралашкан зур шәхесләр, сәясәтчеләр белән дуслыкны эш өчен файдалана алу сәләте дә... «Кремльдә һәрвакыт кызыклы булырга тиеш. Без эшебезне шулай оештырырга тырышабыз», – ди ул.

Казан Кремленнән түбәнгә, офыкларга кадәр сузылган шәһәребезгә карап сокланганыгыз, Колшәриф мәчете яныннан азан тавышларын тыңлап узганыгыз, Сөембикә манарасы янында ханбикә турындагы риваятьләрне искә төшереп, уйланып басып торганыгыз, ерактан ялтырап күренгән Иделне, Казансуны, Болакны колачлаганыгыз, Ослан таулары артына тәгәрәп төшеп баручы кояшны, аның соңгы нурларының нәкъ менә Кремль диварларында уйнавын күзәткәнегез бармы сезнең? Спас капкалары янында даң-доң килеп Кремль курантлары суга, атларның ток-ток тояк тавышлары ишетелә, аңа Казан урамнарыннан төрле авазлар килеп кушыла, туристларның төрле телләрдә сөйләшеп узулары колакка кереп кала, гидның салмак хикәясе ерак гасырларга алып китә... Анда тавышлар күп. Аннары шунысы – һәр архитектура шедевры аерым тавышка ия. Ниндидер илаһилык, серлелек бар шуларда. Кремль – шәһәребезнең йөрәге. Казанның йөзек кашы диләр аны! Баскычларын саный-саный кабат шунда күтәреләсе, шул дөньяны кайта-кайта ачасы, беренче тапкыр күргәндәгедәй рәхәт хисләр кичерәсе килә! Казан Кремле теләсә кемне магниттай үзенә тарта.
Казан Кремле үл үзе бер шәһәр, үзе бер дәүләт кебек! Ерак тарихны искә төшерсәк, чынлыкта да шулай булган бит! Хан пулатлары, биек таш мәчетләр, берсеннән-берсе затлы матур биналар, сәүдә рәтләре калын диварлар белән уратып алынган булган. Биек калкулыкта Казан ханлыгы дигән дәүләтнең баш каласы урнашкан... 1994 елның 22 гыйнварында Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев «Казан Кремле» Дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей тыюлыгын оештыру турында» Указга кул куйды... һәм Казан Кремле безгә тагын да якынайды. 2000 елда Казан Кремленең ЮНЕСКО Бөтендөнья мәдәни мирасы исемлегенә кертелүе исә аның кыйммәтен, дәрәҗәсен бермә-бер күтәрде. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы оешуга быел – 25 ел. Гасырлар тирәнлегеннән караганда, меңьеллык тарихта бу чирек гасыр бик аз, бик кыска тоелыр, бәлки. Ләкин бирeдә бер-бер артлы ачылган музейлар, реставрацияләнгән биналар, мегакүргәзмәләр, халыкара фестивальләр Кремль тарихында яңа бер дәвер булып языла.




Фото: Анна Арахамия

Мин Кремльдә үткән колачлы бәйрәмнәрне искә төшерәм.

«Казан фанфаралары» халыкара фестиваленә хәрби тынлы оркестрлар чыгышын карарга туристлар махсус килә икән хәтта! Россиянең Оборона, Эчке эшләр министрлыклары оркестрлары, Милли гвардия оркестры... Арада Мәскәүнең Кызыл мәйданында хәрби парадта катнашкан оркестрлар да бар.

Балаларны халыкара яклау көнендә «Без Кремльне яратабыз!» дигән чарага җыелган халыкны күрсәгез иде! Ул балалар, ул әти-әниләр!.. 18 меңләп бала Казанның иң матур җирендә көне буе күңел ачсын әле! БМО тарафыннан бу көн әти-әниләр көне дә дип игълан ителде бит. Шуңа күрә Кремльдә аны зурлап гаилә бәйрәме итеп оештырганнар. 1 июньдә туган балаларны Кремльгә чакыру матур традициягә әйләнгән! Сабыйның беренче туган көнен шулай билгеләп үтү гомергә истә кала торган вакыйга бит. «Беренче елны 11 балага курчаклар бүләк итсәк, узган ел аларның саны 50 гә җитте. ЗАГСлар да бу зур чараны оештыруда катнаша. «Алдагы елларда бүләк курчакларны машинага төяп алып килергә туры килер, мөгаен, – дип елмая Зилә ханым. – Балалар – Кремльнең булачак дуслары», – ди ул. Бу сүзләргә тирән мәгънә салынган. Алар өчен ниләр генә оештырылмый! Квестлар, интерактив программалар, фәнни шоулар...

Алтын Урда чорының сәяси һәм мәдәни глобализациясен күрсәтүче «Алтын Урда һәм Кара диңгез буе. Чыңгызыйлар империясе сабаклары» күргәзмәсе, «Борынгы, соклангыч, синеке!», «Коръән – камиллеккә тартылу», «Матисс, Пикассо, Шагал...» күргәзмәләре... Һәркайсы турында аерым сөйләрлек.

...Зилә Рәхимҗановна Санкт-Петербургта узган мәдәни форумнан кайтып кына төшкән иде. «Союзмультфильм» киностудиясе, «Петергоф» музей-тыюлыгы, «Б. Н. Ельцин исемендәге Президент китапханәсе» белән үзара хезмәттәшлек килешүе, Финляндиядән килгән коллегасы белән уртак проектлар турында сөйләшүләр, Кытай музее җитәкчесенең чыгышлары... Яңа идеяләр, яңа планнар белән рухланып кайткан ул. Кремль, туристлар, күргәзмәләр турында сөйләшәбез. «Казан Кремле» музей-тыюлыгында директор булып җиде ел эшләү дәверендә Зилә Рәхимҗановнаның истә калырлык вакыйгалары да, матур мизгелләре дә, онытылмас очра-

Казан Кремле – чын-чынлап музейлар шәһәрчеге! Күпме тарихи байлык, серләр саклана анда...

шулары да күп, бик күп. Әйдәгез, шул мизгелләрне күз алдыннан үткәрик.

Казан Кремле – ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән һәрвакыт ачык һәйкәл. Чит илләрдә дә, бүтән җирләрдә дә күргәнем бар: капкалар кичтән ябыла. Ә безнең Кремльдә җәйләрен төнге 2 дә дә, иртәнге 4 тә дә туристларны очратып була. Алар чит илдән бер-ике көнгә генә килүчеләр булып чыга. Хәтта таң атканда Кремльнең матурлыгын күрер өчен махсус та киләләр.

Кеше үзенә хак мәгълүмат алырга тели икән, музейга барсын ул. Чын документның төп нөсхәсен карап, экспонатның үзен күреп кенә дөрес фикер тудырып була. Юкса бүгенге заманда, булмаган нәрсәләрне уйлап чыгарып, фейк-яңалыклар белән кешенең башын әйләндерәләр. Мәгълүмат чаралары да бихисап, алар шундый төрле... Һәркайсы үз редакциясе политикасыннан чыгып оештыра материалны. Хәтта «безнең формат», «безнең формат түгел» дигән фикерләр дә чыга башлады. Ә менә музей форматының үзенең көчле яклары бар. Ул барыбер чын тарих, чын экспонат, исбат ителә торган кыйммәтләр. Документмы, кәгазьме ул, Тукай кульязмасы белән сакланган битме, безгә ничәмә-ничә гасырлардан калган чех монетасымы – алар барысы да чын.

Төнге 12 дә дә, 2 дә дә кунаклар кабул иткән бар. Кайчак ул иртәнге сәгатьләр дә була. Туристлар шәһәр белән таныша башлаганчы ук иң элек Кремльне барып күрергә тырыша. Берчак шулай Татарстанны өйрәнергә килгән кешенең самолеты соң төшә. Һәм ул иртән иртүк Президент белән очрашачак та, шуннан соң очып та китәчәк икән. «Аңарга үзебезнең кыйммәтләрне күрсәтәсе иде», – дип шалтыраталар. Татарстанга килгән делегацияләр, рәсми кунаклар өчен дә ул, һичшиксез, күреп китәргә тиешле истәлекле урын. Кремльдә зур кунаклар кабул итү – җаваплы, мәшәкатьле, дулкынландыргыч эш, әлбәттә. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы иртән сәгать 10 да ачыла, кичке 6 да бикләнергә тиеш. Алай да җомга көнне кичке 8 гә кадәр эшлибез – эш кешесенә музейга килергә җай чыгарабыз. Җәй көне Колшәриф мәчете, Благовещение соборы алданрак ачыла. Иртәрәк килгән группалар күрми китмәсен дип, махсус шулай эшлибез.

Әүвәлдән безгә килеп җиткән тарихи байлыкны бүген дә яшәтеп, зыян тидермичә киләчәк буыннарга шул килеш калдыру – төп бурычыбыз. Бу юнәлештә күп эшләр башкарыла, һәм алар елдан-ел дәвам итә. Менә хәзер Спас капкасыннан уң якта Благовещение соборына чаклы реставрация бара. Әле күптән түгел төрле оешмалар карамагында булган бина Президент карары белән музейга бирелде. Тарихи яктан да әһәмиятле бина ул. Анда нинди генә хәлләр булмаган, нинди генә кешеләр эшләмәгән... Император Павел I килгәч, шушы бинаның бер залында Казан губернасының иң затлы кешеләрен чакырып, мәҗлес оештырганнар. Татар зыялылары да хатыннары, кызлары белән килгән. Бөтен губерна җитәкчелеге, суд, салым хезмәте, финанска караган тармак конторалары шушында утырган. Тарихи яктан караганда да андый типик биналар илдә күп калмаган инде. «Присутственные места» дип атала ул бина, тарихи исеме шундый.

Музей тирәсендә заманча инфраструктура, үзенчәлекле атмосфера булырга тиеш. Хәзер музейга бер сәгатьтә йөгереп чыгарга дип кенә килмиләр, гаиләләре белән көне буена дип киләләр. Танышып, өйрәнеп китү урыны гына булмасын ул, анда ял итәргә дә, капкалап чыгарга да мөмкинлек тудырырга кирәк. Ә музей кафелары гадәти кафе гына түгел, үзгә алар. Хәтта анда да музей атмосферасы! Чынлап та шулай бит. Ул интерьердан гына да тормый. Мәскәүдә әнә баскыч астына тартмалар гына куеп, төзелеш башланган кебек кенә эшләсәләр дә, шушы музей атмосферасы саклана анда: алган тәэсирләре белән уртаклашып, сөйләшеп утыралар. Үзенә бер музей халәте! Менә без дә Колшәриф мәчете каршында җыйнак кына «Wi-Fi» кафесы ачтык. Яшьләр, студентлар яратып йөри анда. Еракта җәйрәп яткан Иделгә карап, Кремльдә алган тәэсирләрдән тагын да җанланып, ничәмә-ничә гасырлар ядкарен күңелдә кабат тергезгән хәлдә бүгенгә кучә-кучә, тәрәзә төбендә сөйләшеп утыралар, шунда ук чәкчәк, өчпочмаклардан авыз итә-итә чәй эчәләр. Казан Кремле сурәте төшерелгән кечкенә сувенир-шоколад исә биредә алган тәэсирләргә яңа бер бизәк сыман!

Музейның асылын да югалтасы килми, заманга да яраклашырга кирәк. Санкт-Петербургтагы форумда, түгәрәк өстәл янында махсус сөйләшү булды. Профессионаллар, музейдан сату үзәге ясамасыннар иде, дип чыктылар; икенче яктагылар, музейны үзгәртмичә дә булмый дип, бәхәсләшеп тә алдылар. Музейлар тарихында реформалар табигый күренештер инде ул. Кешегә керү өчен уңайлы булсын дип, Луврда Пирамида төзеп куйдылар инде. Ләкин андагы картиналар шул ук бит! Узган гасырда да, бүген дә Джокондага сокланырга дип киләләр. Һәр буын Джоконданы күрергә бара. Хәзер менә экспонатсыз музейлар да барлыкка килә. Гомумән, шундый мода күзәтелә: кафе ачалар да «Чәкчәк музее» дип исем бирәләр. Музей дигән исемнең кеше күңеленә бик туры килә торган җисеме бар. Шуңа күрә «музей» сүзен бик актив кулланалар, хәтта коммерция максатларында музей булмаган җирне дә музей дип атыйлар.

Кытайдан килгән коллеганың чыгышы уйландырды. Ул бернинди «коммерция», «интеграция»ләрсез генә сөйләп китте: «Кем без? Кайдан чыкканбыз? Кемнәр алар кытайлар?» дигән сорауларга җавап бирергә тиешбез иң элек. Безгә килгән һәр яшь кеше – ул кем, кайсы илнеке, нинди халыкның дәвамы?» Әнә шуларга гади генә итеп җавап та бирде. Дөньяның астын өскә әйләндереп түгел, киресенчә, аякта ныграк басып торып, без шушы җирдә яшибез, без менә шушындый



дип аңлатырга тиешбез. Менә шуларны әйтергә теләде ул. Дөнья һәркем өчен ачык хәзер: төрле илләргә барабыз, үзебезгә киләләр. Һәркайсы белмәгәнен, үзендә булмаганын күрергә, ачыкларга тырыша. Шуның өчен без дә үзебез турында иң-иң асылларын җыеп сөйләргә тиешбез. Менә без шундый җир, монда инде мең еллар элек тә төрле илләрдән килгәннәр, безнең белән сәүдә иткәннәр, без ничәмә гасырлар буе яши торган борынгы халык, дип, башкаларга шушы мәгълүматны бирергә тиешбез.

Казан Кремле территориясендә уткәрелгән археологик тикшеренүләр һәрвакыт яңа ачышларга юл сала. Борынгы диварлар астында табылган байлыклар арасында хатын-кыз бизәнү әйберләреннән бакыр асма бизәк, гарәп язуы орнаменты төшерелгән көмеш беләзекләр, ат дирбиясе каешында бронзага алтын йөгертеп эшләнгән аксессуарлар, ат сурәтле керамик уенчыклар, иран савытлары фрагментлары, көмеш гарәп дирһәме ватыклары, сенсациягә тиң табылдык – чех монетасы... 1996 елда казу эшләре алып барганда Благовещение соборы белән Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты бинасы арасындагы скверда XV–XVI гасырларга, Казан ханлыгы чорына караган рус көмеш монеталары хәзинәсенә юлыктылар. Зур таш бинаның төньяк-көнчыгыш почмагында, 600 квадрат метр мәйданда җир өслегеннән 160 см тирәнлектә – күн капчыкта табылды ул монеталар. Алар рус патшалары идарә иткән чорларга карый. Казан археологик экспедициясе вакытында табылган хәзинә гомумрус акча системасының барлыкка килү чорын бик ачык сурәтли. XV гасыр ахырында, Мәскәүнең йогынтысы көчәйгән бер мәлдә, акча суга торган үзәкләрнең саны кими, ә XVI йөзнең беренче чирегендә Дәүләт монета дворларында гына акча сугу рөхсәт ителә. Ул монеталарның ниндиләре генә юк! Ә бер монетада «Ибан/Иван» исеме гарәп хәрефләре белән язылган! Ул акча 1470–1480 елларда кулланылышта булган. «Ак патша» Иван III суверенитетын тануны белдергән. Тарихи фактлар яңадан-яңа яклары белән ачыла әнә шулай.

Күпләр монгол хатын-кызларының баш киеме боккуны күреп гаҗәпләнде. Моннан әллә ничә йөз еллар элек яшәгән затлы бер ханымның киеп йөргән баш киеме безнең көннәргәчә саклансын әле... Алтын Урдага багышлап ачылган мегакүргәзмәдә булды бу. Күргәзмәнең эчтәлеге шулкадәр тирән, шулкадәр актуаль иде. Бу эштә никадәр кеше катнашты! Сөйләшүләр алып барудан башлап, экспозицияне әзерләү, экспонатларны саклауга кадәрге этапларны искә төшерсәң... Петербург Эрмитажыннан, Беларусь, Кырымның Ялта, Феодосия, Таврида, Бакчасарай, Әстерхан, Воронеж музейларыннан 600 ләп экспонат куелды анда. Борынгы халатлар, баш киемнәре, бизәнү әйберләре, кабер ташлары, монеталар, савыт-саба... Кремльгә керү юлындагы баннерга да бокку кигән ханым портретын куйдык, афишаларга да аны чыгардык. Чакыру билетлары, открыткаларда да шул хатын-кыз сурәте... Гомере буе Петербург Эрмитажының Шәрык бүлегендә куратор булып эшләгән Марк Крамаровский безгә әлеге күргәзмәгә килде, фәнни конференциядә катнашты. «Ничәмә-ничә еллар Алтын Урданы өйрәнеп, Эрмитажда күпме күргәзмәләр оештырып, Алтын Урда хатын-кызы образын беренче тапкыр Казанда күрәм!» – дип сокланды ул. Башка вакытта күбрәк җайдаклар, кораллар, кылычлар белән җәлеп иткән шул ул күргәзмә. «Алтын Урдада хатын-кызның дәрәҗәсе зур булган, аның роленә игътибар күрсәтеп ялгышмагансыз», – диде Крамаровский.

Кремльдә «Эрмитаж-Казан» үзәген ачканда мин Татарстан Республикасының вице-премьеры идем. Тантанага Петербург Дәүләт Эрмитажының генераль директоры Михаил Пиотровский килде. Бу эшнең башында, әлбәттә, Минтимер Шәрипович Шәймиев торды. Яңа музейлар турында сүз дә юк чакта – 1994 елда – музей-тыюлык оештыру үзе үк шаккаттыргыч адым иде! Перспективага эшли торган җаваплы адым! Беренче музейларны ачу, шул ук Колшәриф мәчетен төзү... хәтта манараларының төсләрен сайлауга кадәр үк үтә бер җаваплылык белән карады. «Безнең эштә вак-төяк була алмый. Барысы да мөһим!» – дип әйтә килде һәрвакыт. Әле дә хәтеремдә: Минтимер Шәрипович эшләрнең барышы белән танышырга килә, манара төсләренең төрле вариантларын җентекләп карый, уйланып тора, фирүзә төснең әле бер төсмеренә, әле икенчесенә туктала, һәркайсын күзаллап карый. Юк, бу дөрес төс түгел әле, туры килеп бетмәгән әле, дип, буяуның тонына кадәр үзе сайлый. Чак кына бүтән төсмергә тайпылса да, Колшәриф мәчете андый затлы, күркәм булмас иде. Мәрмәргә шулкадәр туры килеп тора бу төс! Әллә кайдан балкып күренә, хәзер ул дөньяның иң яхшы ун мәчете исемлегенә кергән!

Кемнәр генә килмәде Кремльгә! Мөселман киносы фестиваленә килгәч, француз актрисасы Катрин Денёв та Казан Кремлен карап йөрде. Татар читекләре бүләк иткән идем, аһ итте инде, аэропортка кадәр кочаклап барды шуларны! Элеккеге җитәкчеләрнең дә килгәне бар. Борис Ельцин һәм хатыны Наина Иосифовна, Михаил Горбачёв... Күпләр... Горбачёв анда Дмитрий Хворостовский белән очрашты хәтта! Аларның күрешкәннәре булмаган моңарчы... Михаил Сергеевич: «Хворостовский белән танышыр өчен миңа Казан Кремленә килү кирәк булган», – диган иде.

Безнең бәхетебездер инде: көн саен күрәбез Кремльне! Ә кайбер кеше гомерендә бер генә килеп күрә. Менә шул бер очрашуны да мәңгелек итеп истә калдырыр өчен, Кремльнең дә, анда эшләгән кешеләрнең дә әзерлеге югары дәрәҗәдә булырга тиеш. Әнә шундый таләпләрдән чыгып эшләргә тырышабыз. Белгечме ул, музей хезмәткәреме, кунакны каршылаучымы, билетлар сатучы кассирмы, Кремльне бизи торган чәчкәләрне үстерүчеме, җыештыручымы – һәркайсына таләпләр бик югары. Алар бит көн саен, сәгать саен кунаклар каршылый. Шуңа күрә планеркаларда гел әйтәм: «Бәлки, ул үз гомерендә бер килгәндер, шул бер килүдә дә иң асылын, иң матурын, иң истә калырлыгын күрергә тиеш!»

PRESSA



ЧИБӘРЛЕК – КЕШЕНЕҢ СЫҢАР КАНАТЫ

Шунда ук «икенче сыңары ни?» дигән сорау туа. Матур кешенең ике канатыннан берсе чибәрлеге булса, икенчесе – аның сәләте. Ярый, чибәр дә, сәләтле дә булсын, ди. Матурлыкка шулар гына җитәме соң? Чибәрлекне дә, сәләтне дә, матурлыкны да бизмәнгә салып яисә озынлык үлчәве белән үлчәп булмый. Ул сыйфатларны үлчәгечләр һәркемнең үзендә, үзенчә. Әгәр кем дә булса берәү икенче берәүне матур кеше дип таный икән, шунда ук «матурлык үзе нәрсәнең бер элементы?» дигән сорау туа. Ә җавабы соравыннан ерак түгел: матурлык – бәхетнең сыңар канаты ул. Ә икенче сыңары – мәхәббәт. Мәхәббәтсез бәхет булмый, матурлыксыз мәхәббәт булмый!

Ике күзе дә тумыштан сукыр Наил исемле яшьтәшем бар иде минем. Үзе шикелле үк тома сукыр кызга өйләнеп, өч бала үстерделәр. Очрашкан чакларда: «Яратышуыгызның сәбәбе нидә?» – дип сорый идем. Икесенең дә җавабы бер иде: «мәхәббәт»тә!

– Димәк, матурлыксыз да мәхәббәт була? Күрмичә дә?

– Матурлык – күзгә генә түгел, күңелгә, җанга күренә, сизелә торган сыйфат ул.

Язмамның башында ук шундый фикергә килүемнең сәбәбе – үзен дә матурлык алиһәсе дип атарлык чибәр Фирдәвес Хәйруллинаның халык артисткасы Галимә Ибраһимовага багышлаган мәкаләсен «Матурлык алиһәсе» дип атавында. Матурлык үрнәге булырлык бу артисткаларның икесе дә күптән мәрхүм булсалар да, рухлары яши, сокландыра, сагындыра.

Фирдәвеснең Галимә апа турындагы ихлас мәкаләсендәге кайбер фикерләр белән килешмәүдән түгел, ә кайбер өстәмәләр кирәклектән, мин кулыма каләм алырга җөрьәт иттем. Икесеннән дә гафу үтенеп, беренче өстәмәне язам.

Фирдәвес Галимә апаны пьедесталга бастырып, матурлык идеалына гына хас сыйфатлар белән тасвирлый. Кеше турында объектив фикер йөртү өчен, аны, пьедесталдан вакытлыча төшереп, җиргә бастырырга, кешеләр белән, гаиләсе белән, хезмәттәшләре яки иҗатташлары белән мөгамәләсенә игътибар юнәлтергә кирәктер.

Галимә апа ишле гаиләдә, җиде баланың берсе буларак авылда үсә. Вафа хәзрәтнең биш кызының һәркайсы чибәр һәм дин гыйлеме алган булсалар да, авылда калмыйча, заманча шәһәр белеме алырга омтылалар. Олы апалары янына шәһәргә килгән Галимәне мәшһүр артист Зәйни Солтанов очраткач, апасына: «Мәрьям, синең бу сеңлең сәхнә өчен туган, ул артистка булырга тиеш», – ди. Коръән сүрәләрен яттан белгән мулла кызы әдип, режиссер һәм талантлы артист сүзләрен үзен сәхнәгә чакырган фатиха буларак кабул итә: театр техникумына укырга керә. Аны тәмамлагач, Мәскәү эшче театрына җибәрәләр, бер ел анда эшләгәч, яшь артисткага Мәскәү театр техникумына керергә тәкъдим итәләр. Шулай итеп, Галимә Ибраһимова татар артисткаларыннан беренчеләрдән булып югары белем алып, Казанга кайта, академия театрында иҗат итә башлый. Аның башкаруында татар тамашачысы Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт»ендә – Луизаны, Островскийның «Төшемле урын»ында – Полинаны, Шекспирның «Отелло»сында – Дездемонаны, «Король Лир»да Корделияне күрә.

(Декадага «Король Лир» спектаклен алып килү – без, студентларга да Галимә Ибраһимова башкаруында Корделияне, «Хуҗа Насретдин»да Сәлвине күрү бәхетенә ирештерде.)

Укып бетереп, театрда эшли башлагач, миңа Галимә апа Ибраһимова белән Мостай Кәримнең

Аларның яшәүләре генә түгел, үлемнәре дә кеше ышанмас фаҗигале була.

«Кыз урлау»ында, Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә, Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ендә, «Хиҗрәт»ендә бергә уйнарга туры килде. Иң күп уйналган һәм иң отышлы дип табылган Ана роле Галимә апаның соңгы роле булды.

Зәйни Солтановның «Сеңлеңне сәнгатькә бүләк ит!» дигән канатлы сүзләре фатиха кебек яңгырап, актриса үзенең сәхнәгә бүләк булуын театрда раслаган икән, Галимә Ибраһимова үзе нинди бүләкләргә лаек булды соң? Уйнаган рольләреме?

Татар театрында Галимә Ибраһимованы «Матурлык алиһәсе» дип соклансалар, безнең дәвердә рус театрында Элина Быстрицкаяга табындылар. «Дөнья чибәре», «Матурлык символы» диделәр. Күптән түгел генә күрсәтелгән телевизион тапшыруда Быстрицкаяның бәхетсез язмышы, ялгызлыкта үлеме турында белдек. Кызгандык, гаҗәпләндек. Ә татар матурлык алиһәсенең сәхнәдән тыш тормышы ничек булганын беләбезме соң? Әллә аны белүнең кирәге юкмы? Узган эшкә салаватмы?

Мәрхүмнәрнең гел яхшы якларын гына хәтерләргә кирәк, диләр. Әгәр ул яхшы якларда кайбер начарлыклар да яшеренгән булса?

Әйтергә ярамаса да, хакыйкать өчен дөреслек кирәклектән, Галимә апаның бердәнбер баласы Флүрәнең гарип булып тууын әйтеп узу гаептән саналмастыр. Галимә апа 12 мәртәбә авырлы булып, 12 тапкыр баласын тудырмаска мәҗбүр була. Сәхнә өчен! Матурлыгын саклар өчен! Луиза, Дездемоналар гүзәл булып күренсен өчен. 13 нче тапкыр көмәнле булгач, аңа «бу балаңны табарга тиешсең» дигәнгә юрарлык төш керә. Галимә апа төшләргә, догаларга һәм төрле гореф-гадәтләргә ышана торган кеше буларак, 13 нче баласын табарга ниятли. Ләкин аны ничегрәк сиздерми, сәхнәдән китми табарга? Галимә апа корсагын кеше сизмәслек, сәхнәдән беленмәслек итеп буып йөри башлый. Баланың туар вакыты җитәрәк кенә поездга билет алып, юлга чыгарга җөрьәт итә. Үзенчә, баланы вакытлыча гына бала тудыру йортында калдырып тора да, шау-шу басылгач, аны барып ала.

...Үлем көтмәгәндә килгән кебек, туасы җанның да төгәл вакыты һәм кайда, ничек туачагы билгеле булмый. Галимә апа утырган поездның 13 нче вагонында кинәт тулгагы тота башлый, һәм 13 нче вагонда аның, төшендә күргәнгә ышанып, туарга калдырылган баласы дөньяга аваз сала: аяк-куллары гарип кыз бала була ул. Ягъни сәхнәгә үзен бүләк иткән матурлык алиһәсенә – гарип бүләк.

...Бүләк күп булмый. Гарип кыз бала туганнан соң, күпме генә көтсәләр дә, Галимә апа бүтән балага узмый. 13 нче бала ата белән ананың бердәнбере булып үсә. Гарип булса да, югары белем ала, 13 мәртәбә операция ясатып, үз йомышларына йөрерлек хәлгә килә. Медицина институтыннан «врач-фониатр белгечлегенә ия» дигән диплом алып чыккач, колоратур сопрано тавышлы опера җырчысы һөнәрен камил үзләштереп, сөйләү-җырлау тавышы чыгару әгъзалары авыру артистларны үзенең оригиналь методы белән дәвалап, сафка бастыруга ирешә ул. Аның исеме республикада гына түгел, союз күләмендә яңгырап танылa. Мәскәү профессоры Михаил Яковлевич Полунов күзәтчелегендә кандидатлык диссертациясен яклагач, докторлык дәрәҗәсен якларга материаллар туплый. Материаллар китапханәләрдә түгел, ә врач-фониатрның пациентларында табыла. Шул пациентларның берсе – «рак надгортанника» авыруына дучар булган җырчы Фердинанд Сәлахов сөйләгәннәрдән: «Флүрә Гаевна мине дәвалады гына түгел – үлемнән алып калды. Казанда операция ясау мөмкинлеге чикле булганлыктан, ул мине Мәскәүгә үзе озата барды. Миңа операция ясап, терелгәнче янымда булды. Тәмам савыгып, кабат җырлый башлагач кына, ул мине үз карамагыннан «ычкындырып», башка авыруларны дәвалауга күчте. Терелгәннәр һәрчак аның күзәтүе астында булып, сәхнә эшчәнлекләрен дәвам иттеләр. Үзе дәвалап терелткән җырчылар аңа балаларыдай якын булуының бер шаһиты буларак, мин шуны раслыйм: аның өчен һәр терелгән пациент олы бүләккә тиң дәрәҗә иде».

...Шундый киң күңелле, мәрхәмәтле, юмарт кешенең үз ата-анасына мөнәсәбәттә үтә дә кырыслыгы аны якыннан белгәннәрне гаҗәпләндерә дә, уйланырга да мәҗбүр итә.

Шәригать кануннары бер-береңне гафу итәргә, кичерергә өнди. Ата-аналар – балаларын, балалар ата-аналарын, гөнаһлары нинди булса да кичерергә, гафу итәргә тиешлекне яклый. Ә менә Галимә апа Ибраһимова гаиләсе, бер-берләрен гафу итмичә, һәрчак үзара киеренкелектә яшәде. Әтисе Гай Хадҗиевич Таһировның – үз дөньясы, Галимә апа Ибраһимованың – үз кыйбласы, ә кызлары Флүрә Гаевнаның дөньясы да, кыйбласы да ата-анасыннан читтә. Иң гаҗәпләндергәне шул – Галимә апаның кызы өчен борчылган, аның уңышлары турында ишетеп шатланган чакларын күрүче, ишетүче, белүчеләр юк, чөнки аның шатлыклары бары тик сәхнәгә бәйле, театр эчендә генә. Гай Хадҗиевичның да (чын исеме Гайнулла Хаҗимөхәммәт улы) бөтен тырышлыгы, татар милли бию сәнгатен нигезләүче һәм милли традицияләрне саклаучы буларак, күргәнбелгәннәрен шәкертләренә җиткезү юнәлешендәге хезмәтләре бердәнбер баласына игътибарга урын калдырмый. Озак еллар опера һәм балет театрының баш балетмейстеры, җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры, «Шүрәле» балетын беренче буларак

«Син чибәр, син матур» сүзләре эш белән генә аклана.



Ш. Хәсәенов «Әни килде». Галимә Ибраһимова, Әхтәм Зарипов һәм Габдулла Шәмуков. 1969 ел.

сәхнәгә чыгаручы балетмейстерлардан берсе, озак еллар Мәдәният институтында бию серләрен студентларга юмарт өләшүченең гарип туган кызына игътибары булмауны аңлап булса да, яклап булмый. Кемдер Гай Хаджиевичны яклап, аның опера һәм балет театры сәхнәсенә куйган 35 оригиналь биюен, Камал театры сәхнәсендәге – 37, җыр һәм бию ансамбленә куйган 60 оригиналь биюен, болардан тыш, чуаш, азәрбайҗан, Моисеев ансамбльләренә, республиканың академия театрыннан тыш театрларда куйган 30 га якын биюен санап күрсәтер. Ул саннарның берсе дә газиз балага тиешле мәхәббәтне алыштыра алмый.

Әмма ләкин хакыйкать шул: гаиләдә үзара мәхәббәт тә, хөрмәт тә юк. Һәркайсының үз дөньясы, үз зәвыклары. Безнең карашка, мондый аерымлыкны, гайре табигый автономияне булдырмауда Галимә апа Ибраһимова җигелеп эшләргә тиеш иде. Ләкин матурлык алиһәсе үз ирке белән моннан баш тарта.

Ниндидер бер йомыш белән Галимә апага баргач, ул, булки турап, мине чәй эчәргә утыртты. Чәй янына куярга башка бернәрсә дә юклык гаҗәпләндергәч, «коймак-фәлән булса да пешермисеңмени?» – дип сорарга мәҗбүр булдым.

– Коймак түгел, күкәй пешерергә дә кулым бармый. Гай абыең язуыннан аерыла алмый, миңа камыр ашлары ашау ярамый... Симерүдән куркам.

– Ә кызыгыз Флүрә Гаевна... ничек?

– Ул минем кайда яшәгәнлекне дә белмидер, белсә дә оныткандыр.

– Галимә апа, эчең пошканда кем белән сөйләшәсең соң син?

– Минем эчем пошмый. Әнә – этем бар. Аның белән аралашып юанам. Кай чакларда Мәрзиягә шалтыратам, Галия апага. Уйнаган рольләремне искә төшереп кабатлыйм. Яшьлегемне сагынам.

– Галимә апа, бу бит ашаган күкәй кабыгын җыеп, йомырка ясарга тырышкан кебек. Әллә кайчан уйналган Дездемонаны хәтерләү кемгә кирәк? Нигә кирәк?

– Шул чакларны сагынгач, нишлим соң?

– Яраткан шагыйрьләреңнең шигырьләрен ятлап сәхнәгә чык, сольный концертлар куй. Сәхнәгә бүләк булуыңны акла һәм якла. Узган, уйнаган рольләреңнең сүзләрен кабатлап вакыт әрәм иткәнче, шул рольләр белән автор ни әйтергә теләгәнне һәм үзең шуңа ни өстәгәнеңне хәтерләп, бүген шул фикерләрне ничек тамашачыга җиткезү проблемасын хәл итү белән шөгыльләнсәң, сәхнә өчен син һаман кирәкле артистка булып яшәячәксең.

– Кирәкле булсам чакырырлар иде. Чакырмыйлар бит.

– Артистка үзе чакырырга тиешлекне онытма. Гафу ит, Галимә апа, син һаман шул Зәйни Солтановлар чоры оеткысы белән яшисең. Замана икенче, тамашачылар башка. Матурлык башка. Хәзерге кеше тамашага килә икән, ул анда чибәрне генә түгел, ә булдыклыны, дөрес яшәү өчен көрәшүчене, үзенең идеалларын яклый алган шәхесне күрәсе килеп килә.

– Сәхнәдә бармы соң тамашачы күрергә теләгән шундый типлар, холыклар-рольләр?

– Ниһаять, эзгә төштең. Шулар булсын өчен театрларыбызга ни җитми – шулар турында уйлап, үз фикерләреңне уздыр.

– Мин – актриса. Ни бирсәләр шуны башкарырга тиешлекне генә беләм.

– Актриса иҗади шәхес булырга тиеш. Роль уйнауга имитация ясаучы гына түгел.

Безнең бу сөйләшү Шәриф Хәсәеновның «Әни килде» спектаклен 200 нче тапкыр уйнау алдыннан булган иде шикелле. Нинди каты сүз әйткәнемне хәтерләмим, әмма әңгәмәбез Галимә апаның елавы, минем гафу үтенүем белән тәмамланды. (Ул спектакльдә мин Әлмөхәммәт ролен башкаручы артист кына түгел – Марсель Сәлимҗановның ассистенты да идем.) Әңгәмәбез, бәлки, дәвам да иткән булыр иде – хөрмәтле Гай Таһиров кайтып керде. Гомер иткән ире, кызының әтисе буларак, эштән кайткан кешегә ашарга әзерләү бик табигый булса да, Галимә апа анысын кирәк тапмады. Ә Гай ага өчен бу көтелмәгән хәл түгел икән, ул аны Галимә ападан ниндидер калфак соравында күрсәтте.

– Миңа калфаклар буенча язмам өчен күргәзмә буларак кирәк иде ул, кая яшердең? – диде ул.

– Теге алып киткәндер, – диде Галимә апа.

– Кем ул «теге?» Флүрә монда килми.

– Ул килмәсә, сеңлең Сания килә. Шул алып киткәндер. Ни югалса – шуны миннән таптырасың, – диде Галимә апа.

Гай Хаджиевич бүлмәсендә озак кына казынгач, кабат кухняга чыгып:



– Нәрсәне дә булса тапканың бармы соң синең? – дигәч, мин үземнең артыклыгымны аңлап, саубуллашырга ашыктым. Шушы кыска гына сүз алышуда бу гаиләдә дуслык түгел, татулык та дефицит икәне чагылды.

Күренекле әдибебез Әмирхан Еникиның «Матурлык» дигән хикәясе бар. Анда мәдрәсәдә укучы шәкертнең ике иптәше белән авылына кайтып, аларны гаиләсе белән таныштыруы сурәтләнә. Тома сукыр бабасы, дөнья мәшәкатьләре баскан атасы һәм Анасы...

...Ананы автор менә ничек сурәли: «Аңа күтәрелеп карагач та минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора иде кебек. Әйтерсең, бу һич йомылмас яшьле-моңсу күз аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә, күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдертдин бу бәхетсез әнисен безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән? Без бит, гадәттә, кешене куркытырлык ямьсез һәм гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз!»

Бәдертдин әнкәсен күрсәтеп кенә калмый, аның белән горурлана, үзе ясаган скрипкасында анасына багышлаган көйләр уйный. Бу гаиләдәге татулык, бер-берләренә хөрмәт фәкыйрьлек баскан дөньяны да, гарипләрне дә матур итеп күрсәтә. Автор матурлыкка шулай мәдхия җырлый. Беркемне дә алиһәгә тиңләмичә, ул укучыны тасвирлаган персонажларына гашыйк итә, ярattыра.

Ә без югарыда телгә алып узган Галимә апа да, Гай Хаджиевич та кызлары Флүрә белән горурланасы урында аннан читләшеп, үзләреннән биздерергә, күрмәскә-белмәскә тырышалар. Кеше ышанмас хәлләр!

Республикабызда гына түгел, ил күләмендә танылган хөрмәтле шәхесләр, алар гаиләсендәге кабул итеп булмас хәлләр турында язган өчен, ихтимал, кемнәрдер мине гаепләп, «мондый хакыйкатьнең кемгә кирәге бар?» – дияр... Кирәк!

...Үрнәк булмаса гыйбрәт буларак кирәк. «Эш», «сәнгать» дигән булып, еш кына без кешелегебезне онытабыз, дан өчен, исем өчен, сәнгать өчен кешелек инстинктларыбызны корбан итүгә барабыз. «Сәнгать корбаннар сорый» дигән лозунгның бик күп язмышларны харап итүен күрмәскә, белмәскә омтылабыз.

...Ипотека да, «ана капиталы» да булмаган заманда уникешәр бала табып үстергәннәр. Галимә апа Ибраһимова да ишле гаиләнең бер сөеклесе булып үскән, Гай Хаджиевич та гаиләдә бердәнбер бала түгел. Ә үзләре, бер баланы үстерүдән куркып, кеше ышанмас кешелексезлек гамәлләре кылалар...

...Галимә апа, эте үлгән хәсрәттән йөрәгенә көч килгәч, ваннасында юынмакчы булганда суга капланып җан тәслим кыла. Күпмедер вакыт узгач кына, кызы Флүрә Гаевна үтенече буенча хәл белергә килгән Фердинанд Сәлахов барып табып, аны кадерләп җирләүне оештыра.

Флүрә Гаевна үзе дә салкын душ астында коенып, үпкәсенә салкын тиюдән кинәт кенә авырып үлеп китә. Үлгән чагында, телендә булып, «табутка матур итеп киендереп, башыма әбиләремнән калган бәрхет калфакны кидереп» җирләүне әйтергә өлгерә. Әнисе кызыннан алданрак үлгәнлектән, аның васыятен үтәү Фердинандка кала. Мәрхүмәне үзе теләгәнчә киендереп табутка салгач, аны соңгы юлына озатырга әтисе Гай Хаджиевич килеп керә дә, кызының башындагы калфакка ташлана, аны салдырып үз кесәсенә салгач: «Менә кайда булган икән миңа кирәкле калфак», – дигән «хушлашу нотыгы» яңгырый...

...Атаклы балетмейстерның үз үлеме дә үкенечле. Ул, йөрәген тотып, кемнедер чакырырга дип ишеге янына килгәч, ялгызлыкта җан биреп, күпмедер вакыт ишеге төбендә (аны ватып ачканчы) ятуга дучар була.

Өч гомер, өч язмыш, өч үлем... Бүген аларны сагынып искә алучылар бармы икән? Дога кылучылары бармы? Бардыр.

Флүрә Гаевнаның дәвалавыннан терелгән җырчылар, Гай Хаджиевич китапларында язып, аңлатып калдырган бию үрнәкләреннән файдаланучылар. Ә Галимә апаны белүчеләр, сәхнәдә күрүчеләр инде сирәгәеп барганлыктан, аның иҗаты турында язылган истәлекләрне укып кына артистканың нинди булуын күз алдына китерәбез. Өлешчә. Истәлекләрдә һаман шул бер сүз: «Чибәр иде». Без исә Галимә апаның «сәнгать өчен» дигән булып нинди корбаннар бирүенә игътибарыбызны юнәлттек. Корбан сораган сәнгатьнең сәнгать түгеллеген сиздерергә тырыштык. Минем бу язмам Фирдәвес Хәйруллинаның Галимә апага багышланган «Матурлык алиһәсе» дигән мәкаләсе белән бәхәс кебегрәк язылды.

Кабатлап әйтәм: Фирдәвескә дә, Галимә апага да каршы түгел мин. Сәнгатькә хезмәтне ялгыш аңлап, урынлы-урынсыз корбаннар бирүнең нәтиҗәләре аянычлы булуны әйтергә теләвем иде.

Язганнарым мәрхүмнәргә дога буларак кабул ителсә, «чибәр» дигән тылсымлы сүзгә алданып, язмышларын корбан итүчеләр кимесә, балаларын корсакта чакта ук бууучылар бетсә, мин өлешчә булса да теләгемә ирешкән булачакмын.

Әхтәм ЗАРИПОВ

Фото: Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музее фондыннан һәм автор архивыннан алынды.

PRESSA

Рүзәл Мөхәмммәтшин... «Каралама», «Бүре мин» шигырь китапларының, «Ак бүре» либреттосының авторы. Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты. Үзен прозаик, драматург, публицист, тәрҗемәче итеп танытты. Ә шулай да укучылары аны шагыйрь Рүзәл Мөхәмммәтшин буларак кабул итте. («Әгәр халык күпсенмәсә, шагыйрь дияр идем», – дигән иде ул берчак...)
Ул яңалыгы белән шаккаттыра! Бунтарьлыгы, фәлсәфәсе, нечкә зәвыгы, лирикасы – барысы да үзенчә: Рүзәл халәте, Рүзәлне уйландырган, сыкраткан әйберләр! Менә тагын язмыйча кала алмаган: хисләрен йөрәгеннән алган да кәгазьгә салган! Каурый каләм беләндер, мөгаен. Ә илһамны, бәлки, төнлә алгандыр... (Шагыйрь шулай иҗат итүен сиздергән иде берчак...)
Рүзәлнең күңел халәте сезгә дә күчсен әле...



Рүзәл МӨХӘММӘТШИН

ҮЗЕМНЕ ЭЗЛӘДЕМ, Ә ТАПТЫМ СИНЕ...

* * *

Җыенуым.
Әтәй машинаны
Кабыза да, озак-озаклап
Тынын карый, тәрәзәсен сөртә.
Капка ача.
Шулай озата.

Сыегайган зәңгәр күзләрендә
Ничәнче кат бер үк сүз күрәм:
«Исән йөре!»
Үзе, әллә ничек,
Җибәрәсе килми төслерәк.

Көмеш чыкны ал нур үпкән чакта,
Ни сәбәпле шулай икән, чү,
Миндә дә моң...
Ашыгырга кирәк:
Таң ялкыны куып җиткәнче.

Әтәй кала.
Хатирәдәй ап-ак.
Эчтән генә авыр көрсенеп.
Ул һич мөмкин түгел аңламаска:
Китәр кешең булу – бәхет ләса! –
Димәк, кайтыр кешең бар синең...

* * *

Озатырга чыкма арттан, әнкәй,
Күз яшьләрең авыр җаныма...
Тәрәзәдән генә яулык болгап,
Карап кал, тик озак багып торма –
Син һәрвакыт минем янымда!
Мин озакка китмим, әнкәй, – ышан!
Сагынсаң да, авыр сагынма...
Өстәл артларында йомшак көлеп,
Яннарымда басып торган кебек, –
Син һәрвакыт минем җанымда!..

* * *

Күп ертылды йөрәк –
Саклап кына
Туздырырга юкса теләдем.
Җөе ничә купкан яраларны
Энә күзләп кабат тегәмен.

Чукыныплар китсен шәхес, иҗат,
Уймак чокырына сыйган дан! –
Мондый чакта куеныңа сеңеп
Җуеласы килә дөньядан.

Һәр яңа көн – яңа сугыш кыры,
Яңа көрәш.
Азмы көрәштем?!
Хәзер аңлыйм: гомер буе булган
Тик җил тегермәне –
Көндәшем.

Үз галәмен корып,
Нигездән үк
Ялгышуын күргәч соң гына,
Гаҗәпмени – үгез егар егет
Кузый кадәр кызга сыгына.

Мондый чакта кәеф – челпәрәмә,
Күңел – китек, хәлләр – чамалы.
Кул тидерсәң, авыртуым кимер,
Тының өрсәң, җаным ямалыр.

Кашларымны сыйпа,
Үп чигәмнән.
Язылмаган күпме җыр тулы
Йөрәгемдә – ертык...
Әмма беләм:
Тибәр чакта әле ертылыр!

Без батырып тегәрмен яңадан,
Җәрәхәте ятсын кырык буй, –
Мине берни куркытмый...
Син барда
Икеләтә берни куркытмый!

* * *

Гомер буе эзлим, эзлим Аны.
Иманыма терәү терәтәм...
Һәм, ниһаять, табам.
Көтмәгәнчә.

Ул бик якын икән –
Йөрәктә.



Дөнья мәшәкате күмеп китсә,
Калеб җылым белән беррәттән
Мин Аны да җуям.
(Мескен халәт!)

Ул бик ерак хәзер –
Йөрәктә.
Гомер буе эзлим,
Табам,
Җуям.
Бер тукталып шушы куласа,
Мин, һичшиксез, дәһриләнер идем…
Әгәр Аллаһ чынлап булмаса.

* * *

Авырый балам.
Коелып
төшәр икән шулчаклы:
һаман төренебрәк ята,
уенчыгын кочаклый.

Ут чәчәр күзләре моңсу,
мөлдерәмә үзләре…
тутырып бер карасамы –
үзәгеңне өзәрлек!

Аңа әле салкын караш
ташланмаган,
салкын сүз
әйтелмәгән
һәм ул белми –
күпме кеше
ялкынсыз
йөрәкле килеш җан асрый…
Аларга өмет әрәм:
кояшым, дип сыенасың –
зәмһәрир салкын бәрә.

Авырый балам.
Юрганга
төренә…
Ни хәл итим?
Үзе кызу, кайнар!
Әмма –
үзенә җылы җитми…

Кочагыма алам.
Эри…
Мин, кирәксә әгәр дә,
җанымны әзер,
биләүдәй,
юешенә җәяргә,

гомеремне әзер аңа
сукмак итеп салырга, –
сөрлекмичә, абынмыйча,
киләчәккә бар гына!

Савыгыр ул,
һич шигем юк,
савыгыр бу юлы да…
Әмма әйт, дөнья, сабыем
туенырмы җылыңа?

Шомлы җилләрең, шым гына,
күңел төбенә кереп,
туңдырмасмы –
карт әтисен
язда туң орган кебек?

Бәхетлерәк булсын алмаш!
Һәм җылырак булсын, рас –
көннәре дә,
кояшы да,
заманасы да бераз…

* * *

Мин хәзрәткә «әйе» дигән чакта
Ихлас идем…
Ни дим тагы ла?
Нәрсә вәгъдә итим?
Кесәмдә – җил…
Шул җил, шомландырып, өстәвенә,
Бәгырь кылларыңа кагыла.

Кабат көең киткән:
– Кайда йөрдең? –
Бәйдәге эт түгел соң ла мин!
Сабыйныкы төсле күз яшьләрең…
Елап җибәр, юкса…
Сокланыйм.

Әмма сөю үлчәвеннән хисне
Нәфрәт үлчәвенә күчермә!
Кичер мине, рәнҗеткәнем булса,
Кичер… рәнҗетәсем өчен дә…

Мин яңадан салмыш!
Күкрәк төеп,
Әрлә!
Котыр!
Соңрак коч кына…
Ә мин башым салындырган килеш
Шуып төшим аяк очыңа…

– Болай барса, озак сузмассың ич! –
Җанга төшә авыр күләгәң…
Ни афәте аның – рәхәтләнеп
Итәгеңә ятып үлгәндә?..

Ә илаһка әйтермен дөресен:
«Тәүбә кылыйм, дидем… соңардым».
…Һәм үтенеп, хәрәм гомерем белән
Шул гомеремдә бердәнбер хәләлем –
Син ярымны кире сорармын!

* * *

Офыкка күмелде язларым,
көзләрем,
Артымнан ишекне
көн япты сөенеп! –
Мин дөнья бетереп үземне эзләдем,
Ә таптым – сине…

Көфер шигырь

Нәүбәттәге «даһи» уйларымны
Бәян кылгач, җәйге ак таңда,
Куырылып бактың күзләремә:
«Син имансызмыни,
Хактан да?»

Кискенлегем бәгыреңә үтә,
Капыл әйткән сүзем ошамый:
Яратуга нигезләнми икән,
Бернәрсәгә дә мин ышанмыйм!

Мин ышанам яратуга гына –
Анда гамем, хыял-касдларым[1]…
Син, очравың белән,
Җир йөзендә
Моңа хакым барын расладың.

Тары ярмасыдай гади юкса,
Ни әйтәсең, нәрсә уйлыйсың:
Син – иманым минем,
Күрәсеңме,
Мин ничек имансыз булыйм соң?

Елмайдың да… үтте.
Биттән үптең.
Кичерешләр давын бөяләп,
Сулык-сулык килеп кочакладың:
«Андый көфер сүзләр сөйләмә…»

Сине миңа багышлавы белән
Шикләремне күкләр таратты:
Ярату ул – илаһият үзе,
Илаһият үзе – ярату!

Мин һичкайчан
мөртәтлеккә бармам,
Шөкер кылып армам, онытмам:
Шул хис Җирдә яшәвемне аклый,
Шул хис… иманымны ныгыта.

---

[1] Касд – теләк.





Ихласлык, яктылык, романтика, җылылык, җиңелчә юмор... Раилә Сабирова язмаларын шулар аша танып буладыр. Аннары – геройларын ярату, аларга ышану, бәхет юрау хас аңарга. Укучыларын сөендерәсе килеп, үзе дә шулар дөньясында кайнап яза ул. Елмаеп укыйсың. Бүген исә Раиләдән сюрприз: Яңа ел хикәясе! Бәхетле билет, бәхетле язмыш, әкияткә охшаган чынбарлык!

Раилә САБИРОВА

ТЕАТРГА БИЛЕТ

(тормыштан алынды)

– Идеал мөнәсәбәтләрне ничек күз алдына китерәсең?

– Уңга бер адым, сулга бер адым – «расстрел»! – диде дә артист егет, күзләреннән нур чәчеп рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

«Чая артист дигән аты булса да, ихлас һәм артык сөйкемле үзе», – дигән уй йөгереп узды Мөнирә күңеленнән. Шәхси мөнәсәбәт, мәхәббәт темасына ачылырга җыенмый бу сәхнә йолдызы... Тә-әк... тагын бер сорау гына биреп карыйм да...

– Үзеңә тиң ярны ничек күзаллыйсың?

– Ачык йөзле, көләч, саф күңелле... Сиңа охшаган кебек!

«Башланды-ы-ы...» – дип борынын җыерды Мөнирәнең хатын-кыз халәте. Шушы театр артисты, җырчы халкы янына якын килсәң, ниндидер мәгънәсез шаярулар башлана. Сине, сиңа, синдәй... Уф! Яратмый андый сөйләшүләрне Мөнирә. Шуңа күрә барган җирендә эш өчен кирәкле мәгълүматны җыя, героеннан интервью ала да тизрәк китү ягын карый. Бу юлы да Марат күз кысып шаярта башлагач:

– Интервьюгыз өчен рәхмәт, тапшыру пәнҗешәмбе чыга, 19.20 дә, җаегыз булса карарсыз, – диде дә, операторга «бетте», дип ым кагып, микрофон чыбыгын җыярга керешге.

– Әйдәгез, театр буфетында бер чынаяк чәй эчәбез! – диде Марат. – Үзем сыйлыйм! Һәм Мөнирәнең җавабын да көтеп тормыйча буфетка таба китте.

– Әкълимә апау-у! Ике чынаяк чәй...

– Юк-юк, рәхмәт! Тизрәк редакциягә китәргә кирәк, болай да соңга калдык... – дип, Мөнирә театрның чыгу юлына ашыкты. Чыннан да көтәләр, тизрәк кайтып монтажга утырасы, кичке хәбәрләргә репортаж ясыйсы бар әле. Аллага шөкер, әллә ни уңайсыз хәлләргә калырга туры килмәде, алайса бу артист халкы... Театрдан чыгып барганда Мөнирәнең эчке тәнкыйтьчесе уянып, дилбегәне үз кулына алган иде инде...

Җомга көнне төшке аш вакыты җиткәнче үк Марат шалтыратты.

– Тапшыруны карадым. Үземә дә, әнигә дә бик ошады. Шул форсаттан бер чынаяк чәй күтәреп куярга үзе-гезне затлы кафега чакырам. Әллә кофе яратасызмы?



Рәсем: Наталья Васильева

– Рәхмәт! Кичен кофе эчмиләр инде.

– О-о-о, сез бит илаһи иҗат кешесе! – дип ягымлы шаярды Марат. «Үзең бик ерак киткән инде», – дип эчтән генә елмайды Мөнирә. Зур муенлы җылы свитерына качып, артист егетне тыңлау ошый иде аңа. Шаярса да, тавышы ихлас шундый.

– Яхшы! Алтыда көтәм алайса! Бер чынаяк чәй! – диде дә Марат, сүзне ничек башлаган булса, шулай шаяра-шаяра, саубуллашып та куйды. Нинди алты, кая очрашабыз, кем ризалык бирде, дип «ламбада биеде» хатын-кыз мин-минлеге. Ә күңелгә шундый рәхәт иде, урамда ноябрьнең соңгы көннәре димәссең дә...

Тәки алтыда кайтырга чыкты Мөнирә. Ә бит Марат аны кайда көтәсен дә әйтмәгән иде. «Бәлки әле көтмидер дә, шаяргандыр. Ышан артист халкына!..» – дип уйларга да өлгермәде, каршысына кояштай елмаеп Марат килеп басты. Шул көннән башлап Мөнирәнең тормышы – комедиягә охшаш романтик мелодрама рәвешен алды...

Рәхәт иде аларга! Җай чыгуга, икәүләп театрга йөгерәләр. Марат Мөнирәгә сәхнә арты тормышын сөйләде, күп кенә шәхесләрнең күңел пәрдәсен ачты. Еларлык та, көлерлек тә хәлләр күп иде монда! Нишләтәсең, театр шундый дөнья! Икәүләп машинада төнге Казан урамнарын урау, шәһәр серләрен ачу, туйганчы (юк туймыйлар иде!) сөйләшүләр, Маратның бертуктаусыз кызык ясаулары! Җаен туры китереп, егет үзенең апасы гаиләсенә кунакка да алып барды. Мөнирәне инде театрда да таныйлар, җитәкчелек белән дә таныштырды аны Марат. Бу сезонда Марат уйнаган барлык спектакльләрне карап барды ул. Артистлар йөри торган ишектән үз кеше булып кына кереп китә дә Мөнирә, буш калган урынга барып утыра. Спектакль тәмамлануга башка тамашачылар агымына кушылып, урамга чыга. Ә анда инде битендәге гримын сөртә-сөртә Марат көтеп тора:

– 2 нче рәт, 17 нче урын!

Ул һәрвакыт шулай Мөнирә утырып спектакль караган урынны төгәл әйтә. Аһ, дип, күңеле булып елмая кыз андый чакта, күргән! Аннан алар икәү җитәкләшеп Казан урамына чумалар, бүгенге спектакль турында сөйләшәләр, кыз шаярып артист егетнең кимчелекләрен тезә-тезә дә чыркылдап көлә. Маратның шаянлыгы аңа да күчеп бара бугай!

...Бугай шул менә, бугай! Шундый күңелле очрашулардан кайткач, Мөнирә еш кына йомшак юрганына төренеп, иркен тәрәзә төбенә менеп утыра. «Артист бит! Нинди генә әйбәт булса да, артист ул!» – дигән уй күңелен яндырып уза. Артист белән язмышын бәйләгән күпме бәхетсез хатын-кыз, күңелсез гаилә



тарихларын үз күзләре белән күрде! Андыйлар турында тапшырулар эшләп йөрде, сәхнә кешесе янына мәңге якын килмим, дип, мең кат үз-үзенә сүз бирде! Ә хәзер... Спектакльләрне караганда да башта мавыгып әсәргә кереп китә, Маратның осталыгына соклана... Ә аннары... аны үзенең янәшәсендәге ир-ат дип күз алдына китерә башлагач, сәхнәдә ут уйнаткан егет аңа шамакай булып күренә башлый. Оялу хисе уратып ала, шул халәтне үзеннән җибәрергә тырышып урындыгына чума. Сәхнәдәге егетнең бары тик бер тамашачыга гына төбәлгән күз карашын сизеп, күзләрен идәнгә төби... Үзенә ничек әйтергә соң? Син артист, мин синнән оялам, дияргәме? Әниемнең, «артист халкы белән бәйләнмә инде син, аларга ышаныч юк», дигән сүзе бар дияргәме?! Ә үзең соң, үзең, дип баш күтәрә гаеп хисе. Күрә торып, белә торып якынайдың! Җандашына, сердәшенә әйләндең! Ник баштан ук, «син – артист, мин синнән куркам», димәдең?! Качмады-ы-ың?!!

Аралар торган саен якыная. Сизә инде Мөнирә, Марат аңа магнитка тартылган кебек тартыла әнә. Көндез вакыты булса да Мөнирә янына сугылып чыгарга тырыша. Әниләр белән таныштыру турында сүз башлады кичә... Мөнирәгә дә барысы да ошый, әмма «ул артист» дигән зәһәр уй гына күңелне кимерә, нидәндер өшетеп куркыта. Икеле-микеле уйлар белән вакытны сузу – зур гаделсезлек, батырлыкны җыеп, барысын да Маратның үзенә әйтергә кирәк иде. Беркөнне кафеда чәй эчеп утырганда шул турыда сүз башлады Мөнирә.

– Куркасыңмы? – дип сорады егет кырысланып.

– Әйе... – дип баш какты кыз.

Марат башка дәшмәде. Җитдиләнеп, кафе тәрәзәсенә карап утырды да, яңадан үз халәтенә кайтып, шаяртырга керешә.

Күңелне күпме генә тырнап торса да, бу темага алар башка сөйләшмәделәр. Җае туры килгәндә Маратның, артист хатынына рәхәт түгел инде ул, дип шаяртып кына алганы булды, ары китмәде. Очрашулар дәвам итсә дә, Мөнирә күңелен билгесезлек, курку хисе биләп алды. Ул күбрәк шулар турында уйларга гадәтләнде.

Ә бер көнне Марат ун көнгә авылга, җизнәсенә төзелеш эшләрендә булышырга кайтып китте. Артистларның җәйге ял вакыты иде ул. Китте дә югалды менә! Ике-өч көнгә бер шалтыратып исәнлеген генә белгертеп ала да, вәссәлам! Башта Мөнирәгә шәһәрдә берүзенә генә калу бик күңелсез иде. Сагына ич ул! Театрны, озаклап сөйләшүләрне, Марат елмаюына төренгән Казан урамнарын, бергәләп кул чылаткан фонтаннарны сагына! Ә Марат юк, ул авылга китте... Бигрәк сәер китте. Ә бәлки, ул аның шулай йолдызлануыдыр, үзенең мөһимлеген аңлатырга тырышуыдыр, ә бәлки, ул Мөнирә турында бөтенләй уйламыйдыр, артист ич – ничек тә уйный ала?! Уф! Арылды... Марат авылдан килгәнче төпле фикергә килергә кирәк иде. Һәм килде ул фикер. Әнә шул киң тәрәзә төбендә, төнлә... Иртән әнисенә шалтыратып барысын да сөйләде кыз, күңелендәгесен аңлатырга тырышты. «Узар, шулай дөрестер», – дип хуплады аны әнисе.

Ике-өч көннән Марат кайтты. Шундый шат, шундый бәхетле иде ул! Сагынуы тавышына чыккан хәтта. Театрга гына кереп чыгам да, синең яныңа киләм, дип шалтыраткач, Мөнирәнең күңелен ялкын биләп алды. Теге төндә, тәрәз төбендә Маратка дип атап язган шигырен сумкасыннан бер алды, бер куйды. Уйланды, янды, инде көлгә әйләндем дигәндә генә, Мараттан «килеп җиттем» дигән хәбәр килде. Очрашу бик күңелле узды. Марат авылдагы мәзәк хәлләрне сөйләп көлдерде, сагынуы турында сөйләде. Рәхәт тә, эчтән нидер көйдерә дә иде Мөнирәне. Марат озата кайткач, саубуллашканда шигырен егеткә сузды кыз. Һәм йөгереп фатирына кереп китте. Шигырь рәвешенә салынган саубуллашу сүзләре иде ул...

Марат шуннан соң башка килмәде. Шалтыратып саубуллашты да тынычлыкта калдырды Мөнирәне. Шулай итеп берәр еллап вакыт узды.

Беркөнне Мөнирә эштән кайтырга шактый соңга калды. Шәһәр транспорты йөри торган вакыт узган. Андый вакытта такси чакыра ул. Бу юлы да шулай итте, чыгып утыруга, сумкасыннан әйберләрен барлый-барлый, таксистка адресын атады. Ә руль артында Марат иде... Башта сүзләр бер-берсенә ялганмаса да, соңрак сөйләшеп киттеләр.

– Таксист мин хәзер. Инде бер еллап башка эш таба алмыйм.

– Ничек таксист, ә театр?

– Беләсеңме, теге юлы авылда озак уйландым мин. Чыннан да, гомер буе сәхнәдә шамакайланып йөреп булмастыр дидем, безнең хезмәт хакы да бит... Шул, авылдан кайтып, сиңа килер алдыннан театрдан китү турында гариза калдырып чыктым... Ә аннары үзең беләсең...

– Марат!..

– Юк, горурлык рөхсәт итмәде. Сиңа әллә кемлегемне күрсәтермен кебек булган идем, менә һаман эшкә урнаша алмый йөрим...

Озак сөйләштеләр ул кичне. Бүгенге хезмәт хакымны сиңа багышлыйм, дип, егет Мөнирәгә бер кочак чәчәк бүләк итте.

...Баганага ябыштырылган афишаларны җил йолкый. Метрога төшкәч тә гел театр афишаларына юлыгасың соңгы араларда. Тормыш ул – театр, дигән бер акыллысы. Театр шул, дип фәлсәфәгә бирелеп алды Мөнирәнең хатын-кыз халәте, бер артистланып та алмагач аны, дип чытлыкланды үзе һәм янында барган ир-атка елыша төште. Ефәк күлмәк итәкләре кышкы җилдә җилферди, ә затлы хушбуй исе Маратның борынын кытыклый иде. Теге көнне саубуллашыр алдыннан, театрга ике билет алган иде алар. Менә бүген шунда барышлары. Казан үзе дә бик матур иде бу кичтә. Кая карама, төсле утлар яна, Яңа

ел бәйрәме белән котлап язылган элмә такталар, бизәлгән чыршылар... Талгын гына яуган җепшек карны ерып узган тролллейбус, автобусларга, зур калын шарф эченә борыннарын яшереп, кар шыгырдаткан җәяүлеләргә карап тору гына да үзе бер романтика иде. Ә алар ашыгалар. Театрда бүген премьера – тамашачы, төрле кунаклар бик күп була торган дулкынландыргыч көн! Өлгерергә кирәк!

Урыннары сәхнәдән әллә ни ерак түгел иде. Артистларның һәр мимикасы ачык күренә, тоемлана. Яшь артистларның оста итеп уйнавына бертуктаусыз кул чабасы, алкышлыйсы килә. Театр ишегеннән тыйнак кына узып, тыныч кына тамашачы урынына кереп утырган Маратны бөтенләй танырлык түгел иде бу мизгелдә. Ул һәр артистның ролен күңеленнән кичерә, йөзе үзгәрә, вакыты-вакыты белән ым кагып куя, уйчанлана, елмая, борчыла, күзләре яна... Мөнирә янында гади генә тамашачы утырмый иде... Күңеле белән инде күптән сәхнәгә йөгереп менгән, тамашачы каршына чыккан һәр актерның ролен йөрәгә аша уздырган, күбрәкне аңлаган, һәр кылны тоемлаган элеккеге артист... җаны сызып спектакль карый иде.

Маратның ни дәрәҗәдә сәхнә кешесе икәнлеген аңлый барган саен, Мөнирәнең гәүдәсе кечерәеп, театр урындыгына сеңә барды. Үзен бик гаепле хис итә иде ул. Га-еп-ле... Имәнне туфрагыннан йолкып алган, балыкны – сусыз, кошны канатсыз калдырган кеше итеп... Үз юлын тапмаган, гомер буе сукмаклар сайлаган кешеләр бит болай да меңләгән. Ә ул һәр сулышы белән сәхнәгә талпынган, һәр күзәнәге театр һавасы белән тукланган кешегә юлыннан язарга юл куйган! Уйларына бирелеп, спектакльнең ахыры ни белән тәмамланганны аңлап җиткерә алмады Мөнирә. Торып басып артистларны алкышлаучы тамашачылар агымына гына кушылды.

Театр фойесында рәхәт. Чәчәк, хушбуй һәм Яңа ел исләре. Өлгер тамашачылар кием элгеченә ашыга. «Киемнәрне соңрак алырбыз, – диде Мөнирә, Маратны җитәкләп. – Әйдә, фотолар карый торабыз». Шулчак:

– Марат, Марат кайткан! Бүләк алып кайткан! – дигән шаян җыр ишетелде. Театрның баш режиссеры икән, журналистларга интервью биргән дә, Маратларны күреп, алар каршысына килә иде. Җылы итеп хәл-әхвәл сораштырганнан соң:

– Марат, синең урын буш бит әле, яңадан уйлап карамыйсыңмы? – дип сорап куйды.

Бу көтелмәгән тәкъдимнән Марат бераз аптырап калса да, күзләре ялкынланып, нурланып китте. Шулай да, сагаеп, Мөнирәгә күз ташлады. Ә Мөнирәнең йөзе хуплау һәм шатлык хисе белән тулган иде...

Ә бу вакытта Галәмдә Яңа ел теләкләрен кабул итеп, чынга ашыру чоры башланганны белгертеп, фәрештәләр кар коя иде...

2019: СОКЛАНДЫРДЫЛАР!


Австриянең Вена шәһәрендә татар кызы җырлый. Үзебезнеке! Тамашачы аягүрә басып алкышлаган бу кыз – Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаган яшь җырчы, Альбина Шаһиморатова шәкерте, Михаил Глинка исемендәге Халыкара вокал конкурсы лауреаты Эльза Заяри.

Ноябрь аенда Казанның филармония залында Эльза Заяри һәм Артур Исламовларның концерты булды. Бары бер генә көн. Ә тәэсире атналарга сузылды. «Афәрин! Булдырдыгыз!» Ярты сәгать алкышлар тынмаган залдан тамашачы аларны әнә шулай хуплады.

Эльза Заяри исеме быел Татарстанда гына түгел, илебезнең иң күренекле сәхнәләреннән яңгырады, чит ил тамашачысы аның сопраносына сокланды. Аңа – татар кызына! Җәй көне Кытайда узган концертта Татарстан дәүләт симфоник оркестрына кушылып, ул Артур Исламов белән «Сөембикә» операсыннан «Сөембикә һәм Кошчак» дуэтын башкарды, Европа сәхнәләрендә «Кармен» операсыннан «Микаэлла» ролендә чыгышлар ясады, Татарстан тамашачысына өр-яңа камералы опера – композитор Ильяс Камалның Рүзәл Мөхәммәтшин либреттосына иҗат иткән «Минем Такташ» операсын тәкъдим итте. Эльзаның затлы тавышы Санкт-Петербургның Мария театры сәхнәсеннән яңгырады...

– Быел минем юбилей елым һәм вакыйгаларга иң бай елым да булды, – ди Эльза Заяри, 2019 елга йомгак ясап. – Михаил Глинка исемендәге XXVI Халыкара конкурста икенче дәрәҗәдәге лауреат исемен алуым, яшь опера җырчыларының Елена Образцова исемендәге XII Халыкара конкурс дипломанты булуым иҗатымны яңа баскычка күтәрде. Катлаулы конкурс иде ул. Аның финалына сирәкләр генә чыга.

26 ноябрьдә Австриянең Вена шәһәрендә зур концерт булып узды. Россиядән бары дүрт тавыш – бас, тенор, сопрано, меццо-сопрано катнашты анда. Сопрано итеп Россия Мәдәният министрлыгы һәм Елена Образцова исемендәге фонд минем тавышымны сайлап алган иде. Әлеге концерт белән «Чайковский. Путешествие во времени» халыкара музыкаль проекты башланып китте. Бөек композиторга үзе исән чагында иң зур хыялын тормышка ашырырга – Вена сәхнәсендә чыгыш ясарга насыйп булмаган. Һәм менә 126 елдан соң Венада аның музыкасы яңгырый. Үземнең шундый зур проектта катнашуым аша Татарстанымны да таныта алуым белән ничек горурланганымны белсәгез!











ВАТЫК ПЫЯЛА ӨСТЕННӘН...

Шигырендәге бу юллар аның тормышына карый, аның язмышына кагыла. Әйе, церебраль параличлы кешегә бирәүдән дә ким булмавыңны раслап яшәү җиңел түгел.







«Җил-яңгырда чыныккан канатыңны киереп бер очасы иде. Өстән сынап күзәткән зәңгәр күккә күтәрелеп, кайнап торган тормышка бер күз төшереп аласы иде. Мин дә сезнең шикелле, дип, бар дөньясына аваз саласы иде».

Аңлыйм мин аны, ни әйтәсе килгәнен күңелем белән сизәм. Аның шигъри җаны инде күптән әле ап-ак болытлар кочагында, әле кошлар очып җитә алмас биек тау башында, әле ярларына бәрелә-бәрелә сулкылдаган диңгез хозурында.

– Айгөл, Айгөл, дим...

Ул уянып киткәндәй була. Һәм... янә чынбарлыкка кайта. Күктә түгел, җирдә ул хәзер. Тәпи киткәннән бирле бетмәс-төкәнмәс борчуларга салган чынбарлык аны «бүген һәм шушы мәлдә» яшәргә өйрәткән. Ул, үзе әйтмешли, «аңгыра» язмышына өндәү ташлаган церебраль параличлы 36 яшьлек Айгөл Исмәгыйлева, үзен белгән һәм белмәгәннәргә, туганнарына, дус-ишләренә алар шикелле, ә бәлкем, алардан да өстен булуын исбатлый-исбатлый арыган инде. ДЦПның хөкем карары түгеллеген, дүрт стена арасына кереп бикләнер өчен сәбәп булмавын яшәеше белән күптән раслаган.

Айгөл компьютерны кабызып җибәрә. Экраннан таныш та, таныш та булмаган бер кыз елмая. Ул дөньяның үзе кебек төрле. Кайларда гына булмаган ул?! Әнә ул Кара диңгез буенда, Ялтада, Севастопольдә, Судакта... Әнә – Төркиядә, Аланья җирләрендә, Дубайда, Кытайда.

«Бик күп илләр күрдем...»

Аның Мароккодан кайтып кына кергән чагына туры килдем. Хәзер тәэсирләрен минем белән уртаклашып утыра. Сүзен җанын тетрәткән мизгелләрдән башлый:

– Марокко – ул бөтенләй башка дәүләт. Анда инвалид та, физик мөмкинлекләре чикле дигән төшенчә дә юк.

Инстаграмында болай дип яза: #superpulchak «Без гарәп илләрендә сәяхәттә. Кешеләренең ачык һәм позитив булуына сөенеп бетә алмыйбыз. Гарәпләр мине йә Польшадан, йә Германиядәндер дип уйлаган икән. Россиядән икәнемне белгәч, йөзләре тагын да яктырып китә: «Россия – әйбәт ил, кешеләре әйбәт», – дип безне мактый башлый. Алар безне ярата. Чөнки безнең илдә милләтләргә аерып карау дигән нәрсә юк. Гарәпләр физик мөмкинлеге чикле кешеләрне батыр йөрәклеләр дип атый. Булдыра алганча ярдәм итәргә тырышалар. Ислам шуңа өйрәтә. Кылган игелегең икеләтә кайтачагына ышана. Алар гади, шул ук вакытта үзләрен хөрмәтле дә белә. Безгә аларны аңлавы читен. Әйтик, кроссовкадагы шнурың чишелгәнен күрә икән, килеп шуны бәйләп куюны ул бернигә санамый. Кызганыч, бездә шуны сорасаң да эшләмиләр. Кая ул елмаю, күргүгә йөзләре үзгәреп китә, тизрәк яныңнан китеп барырга гына торалар. Дөрес, бездә дә инвалидлар өчен бик күп эшләнә хәзер. Тик гарәпләргә җитәргә ерак әле. Моның өчен халыкның аңы үзгәрергә тиеш».

«Син фәрештәм минем...» («Әнигә» шигыреннән)

Әңгәмәгә кушылмыйча, читтән генә безне күзәтеп утырган әнисе Әкълимә ханым башыннан үткәннәрне:

Ул үзе кебекләрне «...өметсез-сәламәт авырулар» дип атый.

«Күз яшьләрем елга булды, агып кына китмәдем», – дип искә ала. «Җанымны да бирергә әзер», – дип торган әни кеше куркыныч төш сыман еракта калган ул көннәрне хәтерендә яңарта башлауга ук зур итеп ачылган зәңгәр күзләреннән шыбырдап яшь ага. Ничек сызланмасын инде ана йөрәге?!

Бала сәламәт туган. Табиблар, шәфкать туташлары нәни кызчыкның матурлыгына сокланып туя алмаган. Нинди матур да, нинди матур... Тик менә сабыйдагы сәер билгеләрне генә күрми калган алар. Соңыннан, баланың чирле икәне беленгәч кенә, табиб: «Ничек күрми калдым?» – дип инәлгән. Чир үзен тиз сиздергән. Дүрт айда утырган бала тугыз айда янтая башлаган. Шуннан башланган да инде күрәсе михнәтләр.

– Ай саен невропатологка барабыз. Ә аның исе дә китми: «Утыра бит әнә», – ди дә кайтарып җибәрә.

Һәр көне бер гомергә торырлык ул чакларны исенә ала башласа, ананың йөрәге сулкылдый. «Бала йә хастаханәдә, йә санаторийда. Елына өчәр-дүртәр тапкыр бара идек, – ди Әкълимә ханым сүзен дәвам итеп. – Терелер, аягына басар, дидем». Ул хезмәттәшләренә бик рәхмәтле. «Хәлемә керделәр, сорасаң, эштән гел җибәрәләр иде», – ди ул. Баланы санаторийда дәвалар өчен, ике көн – үз эшендә, ике көн санаторийда кухняда да эшли әле ул.

– Бервакыт дүрт айга Евпаториядә, санаторийда калдырдык, – ди Әкълимә ханым. – Без киткәндә: «Мине алырга килерсезме соң?» – дип елый гына бит бала. Хат яза иде ул безгә. Ә кәгазь битендә – аның күз яшьләре.

«Минем монда үз дөньям» («12 көн» шигыреннән)

Айгөлдән балачагы, мәктәп еллары турында сораштыра башлыйм да, шундук уйлап куям: «...яшәү рәвеше төрмәне хәтерләткән» мәктәптә укыган, гомеренең яртысын хастаханәләрдә, санаторийларда уздырган баланың балачагы нинди булсын инде? Айгөл – Казан кызы. Айгөл шикелле авыру балалар өчен шәһәр җирендә дәваланыр өчен шартлар күпкә яхшырак. Дәвалау дип әйтү бигүк дөрес тә булмас. Андыйларның хәлен җиңеләйтергә генә була. Кыз үзен сагалап йөргән бу чирдән дә котыла алмаячагын аңлаган. Шуңа да ул максатының чынга ашардаен сайлаган: мохиткә яраклашу, җайлашу...

Үсә төшеп, мәктәп яшенә җиткәч, аны үзе шикелле инвалид балалар өчен булган 4 нче интернат-мәктәпкә укырга бирәләр. Айгөл ул елларны: «Колпак астында яшәгән шикелле», – дип, тетрәнеп искә ала.

Кыз мәктәптә укыганда ук шигырьләр яза. Баштарак аның бу шөгыленә: «Язсын, әйдә, туйгач, туктар», дип көлеп кенә карыйлар. Сәләтенә беркем дә ышанмый. «Кайсы китаптан чәлдердең бу шигырьне?» – дип мыскыллаучылар да табыла. Тик Айгөл бернигә карамый, үзенчә әйтсәк, «ватык пыяла өстеннән...» атлавын дәвам итә. «Кычкырырга азапланам. Йөрәк дәшми. Җитте...

Фото: гаилә архивыннан

Ул әле Сергей Есенин исемендәге әдәби премия номинанты да.

Арыдым», дип, ул вулкан булып атылырга торган хисләрен янәшәдәгеләргә ишеттермәкче, үпкә-рәнҗешләрен белдермәкче. Ярый әле янында күзенә генә карап торган, абыйсы Айрат әйтмешли, ул дигәндә, стена булып баскан әнисе бар!

«Син безгә юл күрсәтүче» («КГУга ода» шигыреннән)

Мәктәптән соң Айгөл Зөфәр кызы Исмәгыйлева Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. Кыз инде күптән кем буласын хәл итеп куйган. Ул җаваплы көннәрдә әтисе янында була. Ректор янына керә, сөйләшә. Инвалид балалар өчен бирелә торган бер урын, шулай итеп, Айгөлгә эләгә. «Университетка киткәндә сәламәт балалар арасында ничекләр укыр?» – дип елап кала идек. Әйбәт укыды. Имтиханнарны яхшы билгеләренә генә биреп барды, – дип горурлана әнисе.

Укыганда ел ярым «Сәламәтлек паркы» дип аталган газетада да эшләп ала әле ул. Үзе кебекләр турында мәкаләләр яза. Университетны тәмамлагач, проблеманың тагын да саллырагы килеп туа – эшкә кайда урнашырга? Янә әтисе ярдәмгә килә. Кызын Медицина университеты китапханәсенә эшкә урнаштыра. Айгөл бүген дә шунда эшли. Ул хәзер бүлек җитәкчесе. Аның һәр минуты кадерле. Һич тик тора белми. Айгөлнең бүгенге көндә «Лунный цветок», «Незабываемые», «Ода моему вдохновению» дип аталган өч шигырь җыентыгы дөнья күргән. 2017 елдан инклюзив яшьләр театры студиясенә йөри. Спектакльләрдә катнаша, курчак театры студиясендә образлар тудыра. Шигырьләренә композиторлар җырлар иҗат итә. «Татарстан энҗесе» республика бәйгесендә ул язган сүзләргә гимн яңгыраган. Ул гимнны без дә тыңладык. «Кем шулай матур җырлый?» – дип кызыксынам. Айгөл моңлы тавышы белән йөрәкләрне айкаган кызның фотосын күрсәтә. Компьютер экраныннан безгә бер кыз елмая. Аяк-кулы булмаган бу чибәр кыз рәссам да икән әле. «Китабымны аның рәсемнәре бизәде», – дип куя Айгөл. Күптән түгел «Компьютер дизайны» курсларын тәмамлаган. Теләк кенә булсын, таулар җимерердәй көче әллә каян табыла.

Айгөл хәзер тырышып гарәп теле өйрәнә. Гарәп илләрендә булып кайту шуңа этәргәнме, нәсел җепләре сиздерәме (аның әбисе абыстай булган бит), ул инде Коръән укырлык дәрәҗәгә күтәрелеп бара. Инде әнә намазга да баскан. «Бервакыт миннән тәсбих тартырга дисбе сорады, – дип елмая Әкълимә ханым. – Дисбе дә алып бирдем, кайнанам бүләк иткән озын күлмәкне дә... Кияүгә дә дисбе бүләк иттем әле». Сүз шунда гына Айгөлнең тормыш иптәше Иван Смольниковка барып тоташа.

«Бәхет бар ул бу дөньяда...» («Бәхет бар» шигыреннән)

– Аңа дисбе нәрсәгә? – дим, гаҗәпләнә калып.

– Иван ислам динен кабул итте, – ди әни кеше. – Унтугыз ел бергә алар. Кызым аны гел үзе белән йөртә. Биюгә дә, театр студиясенә дә... гел бергә. Хатыны әйдәгәч, теләмәсә дә бара. Әле бер көн: «Йокламыйсыңмы? Сиңа кайтабыз», – дип, төн уртасында шалтыратып яталар. Мин бит хәзер ялгыз яшим. Ирем чыгып китте. Килеп тә керделәр: «Әни, менә нинди бию өйрәндек», – дип, биергә дә керештеләр. Ә миңа аларга карап торуы үзе бер рәхәт. Шулкадәр пар килгәннәр инде. Мәктәптән үк бергә. Янында үзе шикелле мең михнәтләр кичергән ышанычлы кешесе бар. Бер-берсенә охшаганнар: икесе дә эшчән, күңел төшенкелегенә бирелми торган. Үз тормышларын үзләре алып барганга бик куанам мин.

Аларның – үз фатирлары. «Ипотекага алган идем, алты елда түләп бетердек», – ди Айгөл. – Ирем дә югары белемле. «Тасма» берләшмәсендә система администраторы. Икебез дә сәяхәт итәргә яратабыз». Ел саен Кырымда булалар. Анда иренең йорты бар икән. #superpulchak. «Без – Судакта. Таулар, таулар, таулар... Бире дә ял арзангарак төшә. Диңгезе җылы, һавасы шундый «тәмле», файдалы». «Гоголь: «Кырымда булдым. Минераль пычракта пычрандым», дип язган. Мин дә пычранып алдым. Ялтада Ботаника бакчасында булдык. Ялта – матур шәһәр». «Дубай, 2018 ел. Урамда шахмат уйнаучыларны күрдек. Без дә уйнап карадык. Шулай итеп, 2019 елгы дөнья уеннарында катнашучы булып куйдык». Инстаграмда әнә шундый истәлекләр.

«...Рухыңны төшермәскә» (Табибә Равия Мухинага багышланган шигыреннән)

Әңгәмәдәшемнән: «Иң авыр вакытларың?» – дип сорарга тел әйләнми. Ник дисәң, аның һәр көне, тормышының һәр мизгеле зур көрәш бит. Җиңел чагы юктыр да. Шулай да бу хакта сүзне үзе башлый.

2009 нчы еллар. Айгөл кинәт урын өстенә ава. Аяклары шешә, температурасы 40 ка күтәрелә. Ярдәм сорап, ВТЭК табибларына бармый инде ул хәзер. Чөнки алар гел: «Анализларың яхшы», – дип кире борып җибәрә. Ярдәмгә 7 нче республика клиник хастаханәсенең ревматология бүлеге җитәкчесе Равия Мухина килә. Бу юлы ВТЭКка юлламаны ул бирә. ДЦП чиренә ревматоидлы артрит килеп кушыла. Хастаханәгә салалар. Янында ак халатлы өмете-ышанычы була. Аның ярдәме белән Айгөл аякка баса. Сәламәтлек саклау министрлыгына шикаять язганнан соң гына аңа икенче группа билгелиләр.

– Терелә алмаслык чир белән авыруыңны белеп тору бик авыр, – ди Айгөл. – Аяклар шешә, бөтен тән сызлый, гормональ препаратларда гына утырасың... Әмма шундук: «Мне хочется летать, / Расправив гордо крылья. / Я не хочу воспринимать / Судьбу во мраке изобилия», – дип, күңелендәге шомлы уйларын читкә җибәрә.

– Мин үземне сирәк мактыйм, – ди ул, «Җыр, гитара һәм мин» республика бәйгесендә җиңүче булуын искә алып. – Көтмәгәндә килеп чыкты. МиЗаМИ фондына рәхмәтлемен. Шулай да... мин молодец!

Бу сүзләргә без дә кушылабыз, Айгөл. Әйе, син молодец!

Мәдинә АВЗАЛОВА

Менә хәзерге акылым, инде тормыш тәҗрибәм белән уйлыйм: куллары җир эшеннән аерылмаса да, күңеле белән иҗат кешесе булган ла минем дәү әни! Яшәргә яраткан!

БАКЫРЧЫ ДӘҮ ӘНИ

Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Әнием белән уҗымлы кыр юлы буйлап тәпилибез. Кечкенә әле мин, мәктәпкә дә кермәгән чагым. Һәр атна шулай: җиде чакрым юлны кичеп, әниемнең туган авылы Олы Бакырчыга барабыз. Яз көне кырда җиргә-күккә атылып сайраган тургайларны тыңлыйбыз, яңгырда күрше авылдагы берәр йортның капка астына басып ышыкланып торабыз, җәй көне бик арыганда чишмә янына тукталып су эчәбез. Кайчан килеп керсәк тә, чәчәкле алъяпкычын япкан, ак яулыгын чөеп бәйләгән Бакырчы дәү әни безне мич каршысына баскан килеш каршы ала. Чыжлап пешкән бәрәңге пәрәмәче, бавырсак, күпереп пешкән юка... ә чолан шкафының аулак почмагында чикләвекле ширбәт. Аһ, шул ширбәтне дәү әни күрмәгәндә генә кабып карыйм дип алганда, ничә тапкыр тотылдым мин! Дәү әнинең кычкырып әрләгәнен хәтерләмим, күз карашы җитә иде бугай...

Апас районы Олы Бакырчы авылында туып-үскән Әхмәтгәрәй кызы Сатирә Сәмигуллина – уңган-булган нәсел кызы. Әхмәтгәрәй бабабыз агач кисмәкләр ясаган, агач эшенә бик оста булган. Дәү әнием өлешенә тегү, чигү, бәйләү, сату эшләре тигән. Үзләренең хәләл кул көчләре белән яшәргә тырышкан алар.

Сатирә билдән түбән толымнарын ике якка үреп салып йөри торган иң чибәр кызы булган авылның, ә дәү әти матур җырчы булган минем. Өйләнешкәч, Пермь якларына шахта эшенә, Кизел шәһәренә чыгып киткәннәр. Икесе дә тырыш, җир кешеләре бит: анда баргач та яшәргә, мал арттырырга тырышканнардыр. Беренче хезмәт хакларына дәү әтигә – гармун, дәү әнигә тегү машинасы алганнар. Бу шатлыкларын уртаклашып, авылга хат язып җибәргәннәр. «Машинагыз – ызба, гармуныгыз морҗа булсын», дигән җавап алганнар. Көтелмәгән кызык әйбер сатып алынса, әле дә шулай дип шаяру гадәте бар хәзер бездә.

Биш бала үстергән дәү әнинең тегү, чигү, бәйләү эшенә һәвәслеге, өлгерлек серләре турында утырып бер сөйләшәсе иде! Аның каравы, ул теккән күлмәкләр, итәкләр саклана миндә. Әниемнәрне һәрчак үзе тегеп киендергән бит ул. Үзенекеләргә генә түгел, авылдашларына да гомер буе бала итәкле күлмәкләр, костюмнар тегә...

Бакырчы дәү әниләргә менгәч, тәмле итеп чәйләп алгач, аларның ямь-яшел келәмнәрендә тәгәрәп уйнарга ярата идем. Яшел келәмгә тәгәрәп китәсең дә, тирәюньне күзәтә башлыйсың. Анда-а-а... Стеналарда якты төсле чигешләр, дәү әнинең күз нурлары кучкән кашагалар, чигешле пәрдә, чаршаулар, тәрәзәләрдә дәү әни үргән челтәрләр, макрамеда үрмәле гөлләр һәм шау чәчәккә күмелгән яраннар.



Алар ел әйләнәсе чәчәктә! Һәр бизәк минем өчен әкияти дөнья, аларның ничек чигелгәнен, гади җепләрдән ничек шундый матурлык барлыкка килгәнен беләсе килеп, шкаф башына үрмәлим, мич башын үз итәм. Аннан дәү әнием иплəп кенә төшерә дә, күршедәге Хәтимә аптый, Мәликә аптый, Хәнифә аптыйларга сәдака бирергә, яңа пешкән юкасын авыз иттерергә алып кереп китә. Пәнҗешәмбе олыларның хәлен белү, хәер бирү саваплы дигән гадәт минә шуннан килгән ул безгә. Кичләрен дәү әнигә еш кына күрше апалар керә. Серләшеп, сөйләшеп утыралар. Кемдер иреннән зарлана, кемнедер кайнанасы кимсеткән... Эчләрен бушаткач, дәү әни аларга шимбә-ял көннәрендә телевизордан караган спектакльләрен сөйли. Көлешеп тә алалар шунда!

Колхоз эше, олы улы Равил белән лапаста кирпеч сугып, алты тиеннән чуашларга сатып җибәрүләре, йомырка сатарга Казанга йөрүләре, әллә ничә чакрым ара узып колмак җыеп сыра ясаулары... Балалар башкалар бакчасына кереп урлашып йөрмәсеннәр, кызыгып үсмәсеннәр дип, җиләк-җимеш үстерүләр, аш-су пешерү, кызларына бирнәгә дип махсус станокта палас сугулар...

...Без әнкәйнең биш шатлыгы идек,
Биш кайгысы идек кайчакта...

Бу җырны әнием үз туенда әнисенә багышлап җырлаган. Әниемнең тагын бер сүзен бик еш ишетәм мин: «Бишебезне бергә кушсак та, бер әнигә тормыйбыз без!» Әниләргә кемнәр җитсен соң, әнием!

...Келтер-келтер-келтер... Хәзер безнең өйдә дә еш кына каеш баулы аяк машинасы тавышы ишетелә. Дәү әниемә тормыш итәргә булышкан тегү машинасы минем өемдә яши, кызларымны тәрбияләргә булыша... Чүлпылары саклана.

Күкләрдән безне күзәтәсеңме, Бакырчы дәү әнием?! Күлмәк итәгендәге җөебез, юлыбыз дөресме?!









МИЛЛИОНЕРЛАР ЯНӘШӘСЕНДӘ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

Канатлары суга тиям дигәндә генә очкычыбыз җиргә төшеп утырды. Бер чите диңгезгә тоташкан аэропортлар тагын бардыр ул, әмма... бигрәк якын бит! Йөрәк кысылып куя... Истанбулның яңа һава аланыннан соң мондагысы бөтенләй кечкенә тоела. Хәер... Соңрак диңгез буенда ятканда бер көнне махсус санадык: Ницца шәһәре аэропортына биш (!) минут саен бер самолет очып килә: Мәскәү, Рим, Париж, Бухарест, Нью-Йорк, Лиссабон, Бәйрут, Тель-Авив... Шәхси очкычларның гына кайдан килгәнен белеп булмый – алар да байтак. Ниццаның күңеле киң: үзенең 350 мең халкы янына ул миллионлаган туристны да бик теләп сыйдыра. Һәм кемдер уйлаганча, зәңгәр диңгез ярында миллионерлар гына ял итми...

Гоголь, Тютчев, Шаляпин, Толстой, Куприн, Чехов... Кемдер Ниццаның искиткеч һавасыннан дәва эзләп килгән, кемдер иҗат итәргә.

Ницца

– Монысы – тышкы ишекнең ачкычы, болары – кухня балконыныкы... Чәй, каһвә, шикәр – һәммәсен куллана аласыз. Май, соус, тәмләткечләр... Нәрсә кирәк, тотыгыз. Юк, тәрәзәләрне япмасагыз да була, тыныч... Ачкычны бер танышым кереп алыр, мин бүген улым янына Грециягә китәм. Матур яллар сезгә!

Сабрина ашыгып-ашыгып саубуллаша. Аның ике катлы бу өенә тугыз көн буе без хуҗа. Тәрәз төбендәге, урамдагы гөлләренә дә. Кайсы чүпне атнаның нинди көнендә чыгарырга икәнен генә бутамасак... Ике генә йорттан торган тар тыкрык. Буш урам. Тыныч, рәхәт... (Үзебез өйдә чакта ишекне япкан да булмады – гел ачык торды.) AirPlay аша улым телефоныннан телевизорга җыр куеп җибәрде: «Мин сине шундый сагындым...» Үткән гасырның алтмышынчы елларында салынган бу француз йортының татар көен тыңлаганы булмагандыр әле... Юлдан аз гына хәл алгач, инде барысын тәртипләп сөйләсәм дә була.

...Ниццага Казаннан туры рейс юк. Без Истанбул аша килдек. Үз җае белән килгән туристны аэропортта туроператор вәкиле каршыламый: транспорт ягын үзең кайгыртасың. Ниццада моның бер авырлыгы юк: автобус тукталышы аэропорт янәшәсендә генә. Автобуска чират белән алдагы ишектән керәсең һәм йөртүчедән билет аласың. Әмма салонга узгач, билетны тиштермәсәң, барыбер «куян» булып саналасың. Билет евро ярым тора, әмма берьюлы ун тапкыр утыруга алсаң, бәясе бер еврога гына төшә: мондый билет трамвай тукталышындагы автоматларда сатыла. (Ниццадагы трамвайларның чисталыгын күрсәгез!)

Әмма турист күбрәк җәяү йөри инде ул: дөньяның матурлыгын автобус, трамвай тәрәзәсеннән күреп буламыни?! Франциянең икенче башкаласы саналган Ницца белән танышуны күпләр кебек Променадтан – яр буеннан башладык. Биш чакрымга сузылган диңгез яр буен бу шәһәрнең йөрәге диләр. Тормыш шушында кайный! Киң юлның бер чите спортчылар өчен. Ә монда бар да спортчы бугай! Карты да, яше дә. Берәүләр йөгерә, икенчеләр велосипедта, өченчеләр роликта, скейтта... Ашыкмыйча әкрен генә атлап баручы туристларның исә исәбе-саны юк. Утырып торучылар да байтак. Буш урын тапсаң, диңгезгә каратып урнаштырылган урындыкларда көне буе утырып торып буладыр, мөгаен. Онытылып, бер уй уйламыйча... Дулкыннар шавын гына тыңлап. Офыкка тоташкан диңгез белән хозурланып... Диңгез... Фирүзә кебек зәңгәр диңгез! Матурлыгын аңлатырга сүзләр табалмыйм... Аңа күз салуга «Лазурный берег» дип, нигә бар дөньяның һушы китүен шунда ук аңлыйсың. (Урындык дигәннән. Зәңгәр бу урындыклар – Ниццаның символы. Яр буенда аңа хәтта һәйкәл дә куелган! Кайчандыр бу урындыкларга акча түләп кенә утырып булган. Урлауларыннан арып, берара шәһәр җитәкчеләре аларны яр буеннан алып та торган, әмма халык соравы буенча кире кайтарган. Урындыклар хәзер унарлап-унарлап бер-берсенә беркетелеп куелган. Әмма Ниццадан зәңгәр урындыксыз киткән кеше барыбер юктыр. Без дә алып кайттык: бу сәфәрдән суыткычка магнит урындык алып кайтып ябыштырдык.)

Инде бу матурлыкка өстән күз салырга телисезме? Димәк, Променадны йөреп чыгабыз да, Шаро калкулыгына менәбез. 330 баскыч! Юк, юк, кире уйлый күрмәгез, күзәтү мәйданчыкларында туктап ял итә-итә күтәрелгәч, аның биеклеге сизелми дә калачак. Иң беренче тукталыш – Белланда башнясының түбәсе (ул түгәрәк, зур булып ерактан күренә). 92 метр өстә! Шушы манарага урнашкан кунакханәдә кайчандыр композитор Гектор Берлиоз туктала. Кәләшенең хыянәте турында ишетеп: «Мин аны җирдә барыбер яшәтмим!» – дип, Парижга барышы була аның. Менә шушы биек манарадан ул диңгез өстенә күз сала, балыкчы көймәләрен күзәтә һәм тынычлана, ә аннан... «Король Лир»га увертюра язарга утыра.

Матурлыктан тын кысылган тагын бер күзәтү мәйданы – югарырак, Шаро паркында урнашкан. Син өстә, таш кыяда басып торасың, ә аста порт (Монако шәһәренә баручы 100 нче автобус та шуннан китә!), Ницца шәһәренең икенче ягы. Чирәп түбәле йортлар, диңгез буе, маяк...

Кая аяк бассаң – Ниццаның шул урынына гашыйк буласың! Әйтик, иске шәһәргә. Кояш төшми диярлек – урамнар тар, йортлар биек. Әллә нинди хикмәте бар бу урынның: дөньяның бар телендә дә сөйләшүче туристлар агымына ияреп йөрисең-йөрисең дә, көтмәгәндә буп-буш урамга барып чыгасың... Аннан алдагы чатта борыласың да, кабат кафе-кибетле урамга тап буласың. Ничек кенә йөрсәң дә, Кур Салея мәйданын урап узып булмый. (Әйтәм бит, монда урамнар сиздермичә сине үзе җитәкләп алып бара!) Кызык мәйдан ул: иртәнге якта барсаң – анда базар гөрли, төштән соң ул тоташ кафе-ресторанга әйләнә. Танымыйча, үз күзеңә ышанмыйча торасың. (Нәрсә икәнен белер өчен булса да, милли ризыклары соккадан (socca) авыз итмичә китмәгез: безнең юкага охшаган, әмма шактый тозлы.) Иске шәһәрдән буш кул белән чыгып булмый: күчтәнәчкә дигән лаванда сабыны, лаванда ботагы, ала миләүшә исе килеп торган саше, магнит, открыткалар... Шәрык базары түгел бу – сатулашу юк.

Арыдыгызмы? Туктап ял итәргә, кафеларның берәрсендә туңдырма ашап алырга теләмисезме? Туңдырма башкаласына килеп, туңдырмадан авыз итмәсәң гөнаһ булыр! Нинди генә тәмдәгеләре юк монда?! Сыра, пицца, лаванда, роза... Бер түгәрәге 2-4 евро тора. «Моны ашап буламы?!» – дип, төкереп китүдән

Автор фотолары

Фестиваль сарае каршында иркенләп фотосессия ясарга мөмкинлек юк: келәм алдында гел чират!

курыкмасаң – аласың. (Супермаркетларда туңдырманы 2-2,6 еврога тартмасы белән саталар: 5-6 данәлесе бар, 10 лысы. Искиткеч тәмлеләр!)

Ашау-эчүгә күчкәч әйтим инде. Бәяләрне арзан диеп булмый. Август аенда бәрәңгенең килограммы 2 евро иде, помидор – 3-4 евро. Тавыкның түшкәсе – 5 евро. Ипи – 1,5-2 евро. Без күбрәк үзебезнең урамдагы Casino супермаркетына йөрдек. Әмма Lidl кибетләрендә бәяләр арзанрак. Безнең кебек туристларга иң җайлысы: әзер салатлар (тунец балыгы яки ит, йомырка, кукуруз, макарон, яшел салат кушып, аларны өйдә дә еш ясыйбыз хәзер).

Канн

– Кызыл келәм буенча уздыгызмы соң?

Каннда да булуыбызны белгәч, бу сорауны бирмичә калган кеше юк бугай. Иң беренче кинофестиваль Каннда 1939 елда ук үткәрелергә тиеш була, тик сугыш комачаулый. 1946 елдан башлап ул хәзер ел саен уздырыла. (Иң беренче кинофестивальдә иң беренче итеп «Берлин» дигән совет документаль фильмын (режиссер Юлий Райзман) күрсәтәләр.) Кино йолдызларын күрергә теләсәң, бирегә май аенда килергә кирәк. Әмма Фестиваль сарае (янына килеп баскач, аның гадилеген күреп бер мәлгә аптырап та каласың) алдына җәелгән кызыл келәм – ел әйләнәсе туристлар хозурында. Шушында басып фотога төшү өчен махсус күлмәк тектереп киләләр!



■ Минем өчен Канн шәһәре иң беренче чиратта Әлфия исеме белән бәйле хәзер. (Хатынының татарча сөйләшкәнен Жан Люкның моңарчы ишеткәне булмаган икән. Һәм ул үзе өчен Әлфиясен яңа яктан ачты бугай. Безнең белән туган телендә гәпләшкән хатынына карап, ул гел елмайды – бәхете йөзенә чыкты.)

Канн... Элеккеге балыкчылар авылы. Ә бүген... Бүген ул иң затлы халыкара курорт! Иң кыйммәтле отельләр, пляжлар шушында! Круазетт бульварының символы дип «Карлтон» отелен атыйлар. 1912 елда төзелгән бу отель Франциянең архитектура һәйкәле санала. Канн кинофестиваленең иң дәрәҗәле кунаклары шушында туктала. Пугачева, Михалковлар да «Карлтон»ны күбрәк үз итә икән. (Анысы – каннандыр. Кайчандыр бөек кнәзь Михаил Романов та шушында туктала торган булган. Кичке сәгать биштә чәй эчәргә яраткан ул. Яңа сауган сөт белән. Һәм моның өчен махсус хезмәтче тотканнар. Романовка ярарга тырышулары юкка түгел: отель төзелешенә шактый акча биргән ул.)

– Отельгә кереп чыгабызмы?

Янәшәмнән атлаган «гид»ым сүзен бүлеп сорау бирә. Әйе, әйе, татарча сорый! Канн урамын гөрләтеп туган телебездә сөйләшеп барабыз. Рәхәтләнеп! Шәһәрнең күркәм урыннары турындагы «экскурсияне» бүлеп, вакыт-вакыт аның тормышына да кучеп китәбез. Әлфия Халитова – Башкортстаннан, Мәләвез кызы. Скрипкачы. Ул үзе: «Элеккеге...» – дип өсти. Мин аның тәвәккәллегенә шаккатам: бөтен тормышыңны ташлап бер көнне Италиягә чыгып кит әле! Кулыңда турист визасы гына булган килеш торырга кал. Тел өйрән. Эшкә урнаш. «Закон бозмыйсың икән, сиңа бәйләнүче юк», – ди ул үзе. Римини, Сен-Тропе, Куршавель, Экс-ан-Прованс... Әлфия яшәгән һәм эшләгән Европа шәһәрләрен санап бетерә алмам. Әмма бирегә ул язмышын очратыр өчен килгән бугай. Кире Уфага кайтып китәм дип йөргәндә, дус кызы аны Жан Люк белән таныштыра. Сынаулар сындырып сынаса да (башта – гөрләп барган бизнесын югалта, аннан – хатыны ташлый), күңеле йомшак калган ир-егет белән. Жан Люк – Франциянең коньяк-көнчыгышында, Прованста туып-үскән. Әнисе балерина була, әмма балалары хакына сәхнәне ташлый. (Жан Люкның биюгә мәхәббәте, әлбәттә, мәрхүм әнисеннән күчкән. «Татарларның биюләре бик матур, – диде ул соңрак очрашкач. – Буш вакытымда интернеттан милли биюләр карарга яратам. Татар дәүләт бию ансамбле концертын Әлфия белән танышканчы ук караган идем инде». «Әлфия», – дип, чын татарча әйтүләре шул французның!..)

– Французлар сәламәтлеккә бик зур игътибар бирә, – дип сөйли Әлфия. – Минем кайнатама 94 яшь. Ул һәр көнне иртә белән бер сәгать йөгереп кайта, физик күнегүләр ясый. Күптән түгел тикшерелде: «Сезнең организм әле 45 яшьлек ир-егетнеке кебек», – дигәннәр... Ит ашамый диярлек, ә балыкны атнага ике тапкыр ашый. Якшәмбе тавык пешерәләр. Һәр кич саен итсез шулпада пешкән яшелчә ашы кирәк аңа. Һәм салат, салат, салат... «Бордо» шәрабы тотып куя. Су күп эчә. Иремне чәй эчәргә өйрәттем анысы. Тик ул барыбер күбрәк яшел чәй ярата. Татар аш-суларын пешереп карадым. Безнең ризык аларга аңлашылмый, ятрак шул... Аннан кухняда ике хуҗабикә дә булмый – кайнатам йортында күптән инде Алжир кызы хезмәтче булып эшли...


Сөйләшә-сөйләшә Круазетт бульварының икенче очына барып җиткәнбез.

– Менә бу диңгезгә терәлеп торган вилла – гарәпнеке. Берничә ел җәйләрен гаиләсе белән килеп торды, хәзер югалды. Йорт буш... Алар монда бик күп. Кичләрен хатыннарын, балаларын ияртеп йөрер-

гә чыгалар. Руслар да бу тирәне ярата төшә. Пляж Ниццадагыга караганда әйбәтрәк монда: комлы. Дөньяның төрле почмагыннан акчалы, бай өлкән кешеләр җәй буена яшәргә дип килә. Диңгезгә иртүк төшәләр, көндез, кояш кыздырганда парк эчендә утырып торалар, тамак ялгыйлар. Игътибар иткәнсездер, Ниццада да шулай – җыелмалы урындык гел үзләре белән аларның... Ә француз әби-бабайларына пенсия акчасына гына яшәү авыррак. Коммуналь түләүләр бик югары. Шуңа күрә фатирларына кеше кертеп, Таиландка китеп яшәүчеләр байтак. Ә яшьләр Монакога барып эшләп йөри – анда күбрәк түлиләр.

И-и, иң мөһимен әйтергә онытып торам. Ниццадан Каннга автобуста сәгать ярымлык юл. Поезд, әлбәттә, тизрәк бара. Әмма автобуска билет бәясе – 1,5 евро гына! Монакога да, һичшиксез, автобуста барырга кирәк. Беренчедән, шулай ук 1,5 евро гына түлисең, икенчедән, автобус Вильфранш, Болье-Сюр-Мер, Сен-Жан-Кап-Ферра кебек кечкенә шәһәрләр аша уза – аларны да күрәсең.

...Эсседән арып, азрак ял итеп утырырга, ишек төбендәге унбишәр миллионлык машиналарның хуҗалары кем икәнен күрергә яки, гафу, бәдрәф эзләп, «Карлтон» отеленә чыннан да керергә була. Матурлыгын күрергә, рухын тоярга! «Монда тукталмадыгыз», – дип берәү дә кире бормаячак. Менә әле генә син кергән ишектән кайчандыр Брижит Бардо, Софи Лорен, Элизабет Тейлор... атлап узган. Ул озын исемлекне күз алдына китерсәң дә тын кысыла!



La Reserve рестораны. Таш кыяга килеп бәрелгән дулкыннар шавы, портка керүче һәм чыгучы корабль, яхта һәм көймәләрне каршы алучы, озатып калучы маяк, баеп баручы кояшның диңгез өстендәге соңгы нурлары... Шушы гаҗәеп манзараны бер күрер өчен генә дә барырга була Ниццага...

Монако

– Бер, ике, өч... Унҗиде!

Инде җиде гасыр Гримальдилар нәселе яшәгән патша сарае урнашкан мәйдан алдында каравыл алышынганын көтәбез. (Сарай өстендә Монако әләме җилферди икән, димәк, патша галиҗәнаплары үзе монда дигән сүз.) Каравыл алышыну көн саен бер вакытта – көндезге уникe туларга биш минутта башлана. Әмма ярты сәгать алдан барып басмасаң, карарга җайлы урын эләкмәячәк. Кояш, кызу, әмма түзәбез! Әлегә сарай ишек төбендә басып торучы ике гвардиячетенең берсе безнең каршыда «аяк яздыра»: берничә адым атлап, мәйдан уртасына чыга, туктый, аннан 17 адым уңга таба атлап килә, туктый, аз гына басып тора һәм кире борылып, кабат 17 адым бара... Кат-кат! Ә без, тамашачылар, кычкырып саныйбыз: мин – татарча, янымдагы кыз – инглизчә, артымдагы олы абзый – мин белмәгән телдә...

Каравыл алышыну – туристлар өчен махсус уйлап табылган тамаша кебек. Тынлы оркестр уйный, ә гвардиячеләр үзләре генә аңлаган телдә кулларындагы мылтыклар белән ниндидер бию башкара бугай. Бар да озын буйлы, чибәр! Сөлек кебек егетләр! Аларны гвардиягә бик җентекләп сайлап алалар, диделәр.

Монако картада бер нокта гына, әмма ул – аерым дәүләт! Әнә шул кечкенәлеге белән үзенә җәлеп итә дә. Дөнья байлыгы шушында тупланган: әмма аның исәбен-санын берәү дә белми – Монако банклары серне яхшы саклый. Салымнар байлар мәнфәгатен кайгыртып салына. Халкының 80 проценты килеп-китеп йөрүче миллионерлар, миллиардерлардан торуы шуңа гаҗәп тә түгел. Алар өчен җирдәге җәннәт – шушында. (Хәтта казинода Монаконың үз кешеләренә уйнауны закон белән тыю да шул байларны кайгырту: уенга алданып, байлыкларын югалтып куя күрмәсеннәр!) Монакода бер генә нәрсә җитми. Җир! Иңгә-буйга түгел, өскә-аска таба гына үсә ала бу дәүләт. Хәер... җирне әнә диңгездән «урларга керешкәннәр» – бүлеп алалар да киптерәләр, йортлар салалар. Инде яңа район калкып килә.

Бер көн эчендә Монакода тагын ниләр карарга буламы? Монте-Карло казиносын, Милли музейны, япон бакчасын, океанография яки иске автомобильләр музеен, принцесса Грейс розариен, принцесса Антуанетта паркын... Уч төбенә сыярлык дәүләт димәссең! Ә бәлки, патша сарае урнашкан таудан төшкәндә тыныч бер урын сайлап, өстән генә бөтен Монакога карап утырыргадыр? Болыт итәкләре йортларга тиеп-тиеп үтә. Гаҗәеп күренеш! Аста – 700 (!) судно сыярлык Фонвьей порты. Берсеннән-берсе кыйммәтле яхталар тезелгән. Зурлар, кечерәкләр... Йә, «Минеке менә монысы булсын иде!» дигән уен уйныйбызмы? Әллә Ларвотто пляжына гына китеп барабызмы? Диңгез, ком һәм һава – барыбыз өчен уртак: миллионерларга да, безгә дә.



Тулысынча сайтыбызда:
www.syuyumbike.ru

«ХАТЫН-КЫЗ ГАИЛӘДӘ ӘНИСЕН КАБАТЛЫЙ»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

Инсаф АБДУЛЛА,
Татарстанның атказанган артисты, диктор, Казан театр училищесы укытучысы;
гаилә стажы – 30 ел;
балалары – Айрат һәм Асия.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Ир-атны башта аның тулаем тышкы кыяфәте җәлеп итәдер дип уйлыйм. Башын-чәчен җыя алмаган хатын-кыз – хатын-кызмыни ул дигән сүз бар: мин үзем чәчләргә бик игътибарлы. Без әби белән үстек, бу аңардан сеңгәндер. Чәчен җыя белмәгән хатын-кыз үзен дә, гаиләсен дә карый белми кебек тоела.

2 Нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Татар ирләре хатын-кызда бер генә нәрсәне гафу итми бугай – хыянәтне... Безнең холык та шундый, ирлегебезне күрсәтергә теләү дә бар. Кеше ялгышмый тормый, әлбәттә. Әмма хатын-кызның бу ялгышы, гадәттә, гаиләне фаҗигагә китерә. Ир-ат бу адымны аңлы рәвештә эшләмәскә дә мөмкин. Ә хатын-кыз моңа уйламыйча бармыйдыр кебек тоела миңа. Гаиләне тар-мар итүгә китерә торган ялгышларны гафу итү авыррак.

3 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Болай икегә бүлмәс идем. Өйнең матурлыгы, пөхтәлеге ирне нигә илһамландырмаска тиеш әле?! Син моны, тегене эшләргә тиеш, дип, адым саен искәртеп, төртеп күрсәтеп тору илһамландыру дип саналмый. Минем бер якын дус кешем бар. Аның хатыны бервакытта да иренә каршы сөйләми, «Юк», дип әйтми. «Ярар, ярар», – дип кенә тора. Ләкин ул гаиләдә бар да нәкъ ул ханым теләгән тәртиптә бара. «Иргә чүп чиләге тоттырырга ярамый», – ди ул. Савыт-саба юмыйсың, дип тә әйтми. Тормыш булгач, юарга туры килә, әлбәттә. Әмма: «Нигә юмадың?» – дигән сорау туарга тиеш түгел. Белеп эшли икән, рәхмәт, юк икән, аны мәҗбүр итәргә кирәкми. Өйдә, хатын-кыз җилкәсендә яткан ирләр турында сүз бармый.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә! Хәзер күбрәк «хатын-кыз иренә сөяркә булырга тиеш» диләр. Тик «сөяркә» сүзе үзе дә, аның мәгънәсе дә ямьсез. Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең ничек булырга тиешлеген кыз балага кечкенәдән аңлатып үстерергә кирәк. Гаиләдә һәркем үз урынында икән, алар дус булалар. Моның өчен, әлбәттә, дөньяга уртак караш, ниндидер ситуацияләргә карата фикердәш булу да кирәк. Татарда «үтә кызыл тиз уңа» дип әйтү бар. Мәхәббәт нәкъ менә шундый ул... Ул киткәч, ике арада тагын нәрсә кала? Әлбәттә, дуслык!

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Бауман урамында «Спартак» аяк киемнәре фабрикасының Горький клубы бар иде. Без Нурфия белән шунда, кайчандыр Сара Садыйкова оештырган хорда таныштык. Икебезнең дә хорга беренче тапкыр килгән көн иде. Башымны җуеп гашыйк булдым дия алмыйм. Миңа инде 24 яшь, армиядән кайткан, азмы-күпме акыл утырткан... Ничек тәкъдим ясаганымны бөтен нечкәлекләре белән хәтерләмим. «Сине сорарга килсәк, ни диярсең?» – дидем. Ул: «Ярар», – диде. Әни мәрхүмәм: «И-и балам, каршы түгелләрме икән соң? Ара ерак, ике тапкыр йөреп булмас, әзерләнеп барыйм әле, бәлки, никах та укытып кайтырбыз», – дип җыенды. Мин – Башкортстаннан, безнең авылдан Лениногорскига кадәр 300–400 чакрым. Икенче көнне, чынлап та, никах укыттык. 1989 ел иде бу.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Минем хатынның да әнигә охшаган яклары шактый. Ир-ат гомере буе бала булып кала – шуңадыр бу... Әниләрдән гел еракта тордык. Әмма кайтканда-киткәндә Нурфия әни белән сөйләшеп, чөкердәшеп яшәде. Безнең әнинең киленнәрдән риза булмаган чагы юк иде. «Ул да кеше баласы бит», – дип әйтә торган иде. Үзе 40 ел кайнана белән торган, барысын да белә, аңлый иде.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Безнең дә төрле чорлар булды: хатын берара миннән күбрәк эшләде. Сүз чыкмады, бар тапкан уртак тартмага



салына иде. Бүген исә мин – аның, ул минем күпме эшләгәнне белми. Бер-берсеңә ышаныч булгач, кирәк тә түгелдер дип уйлыйм... Бер танышымның әнисенең үз адвокат конторасы бар. «Әнидән эштә куркалар, калтырап торалар. Ә өйгә кайтып, ишектән керүгә, эти: «Кофе эчәсем килә», – дисә, әни тиз генә өс-башын алыштырып, халат кия дә кофе пешерергә керешә. Безнең эти гап-гади кеше, әмма әни аның янында үзенең җитәкче икәнен оныта», – дип сөйли ул. Ир үзен ничек куя бит инде. Ул абзый махсус эшлидер дип уйламыйм: алар икесе дә шундый тәртипкә электән күнеккән. Тормышта ир малны күбрәк табып та, хатыны аны изеп яшәгән очраклар да җитәрлек анысы.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Болай да аны һәрвакыт ул беренче булып белдерә! Ир-ат гашыйк булып йөрсә дә, хатын-кыз аны ошатмый икән, ул аның янына берничек якын килә алмый. Гашыйк булуны белдерү «мин сине яратам» дип әйтү түгел бит ул. Моны сиздерүнең хатын-кызның үзе генә белгән мең юлы бар аның.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Бу очракта тышкы кыяфәт дип кенә әйтеп булмый. Әлбәттә, яшүсмер вакытта тышкы кыяфәт, матурлык та мөһим анысы. Үзе моны аңламаса да, хатын-кыз туачак балаларына – эти, үзенә терәк, таяныч булырдай кеше эзли. Берсе дә ирем эчкече, сугыш чукмары булсын дими. Әмма ирнең алга таба нинди булачагы хатын-кыздан да тора. Элеккеге эш урынымда бер егет бар иде. Яшь, өйләнмәгән, әмма эчәргә ярата. «Каратыгыз шуны үзегезгә», – дим кызларга. «Эчә бит», – диләр. «Өйләнгәч туктый ул», – дим. Гаиләсен белгәнгә әйттем бу сүзләрне: әнисе укытучы, элеккеге сөрелгән байлар нәселеннән, этисе – мулла токымы. Канны, геннарны берни эшләтә алмыйсың! Хатын-кызның дилбегәне үз кулына алып, азрак юл күрсәтеп җибәрүе дә җитә мондый очракларда...

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Өйдәге җиһаз гомер буе бер урында торса да, ир-ат аңа игътибар итмәскә мөмкин. Ә хатын-кызны ул бик тиз туйдыра: йә ул аның урынын күчерә, чыгарып ташлый, йә яңасын ала... Мин моңа каршы түгел, тик... миңа гына тимәсеннәр. Бәлки бу мәсьәләдә сүлпәнрәкмендер, консервативтыр. Йокы бүлмәсе кысанрак безнең. Нурфия: «Шкафны чыгарыйк», – дип бик озак сөйләде, минем яктан бер адым да булмагач, үзе тотынды. Кушылмый чара калмады... Ә менә вак-төяк кайбер әйберләрнең гел бер урында булуы бик мөһим минем өчен. Моның өчен тавыш та күтәрә алам. Ир бит әле мин! Әни мәрхүмә шулай өйрәткәндер: ул секунды белән әйберне урынына куеп, күз алдыннан юк итә иде. Авыл өе, биш бала – башкача ярамагандыр. Ашауга табак-савыт юылмау да минем өчен зур трагедия. Анысы да – әнидән. «Табак-савытны юмыйча ятып йоклаган кешегә аптырыйм», – дия иде.

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Бөтен ир-атлар кебек мин дә һәрвакыт үземне хаклы дип саныйм. Әмма хаклы булмаган очракларның да шактый икәнлеген аңлыйсың. Андый чакта эндәшмим. «Ярар», – дим дә бетерәм. Бигрәк тә, яулык алыргамы, әллә бүрекме дигән кебек вак-төякне хәл иткәндә. Мондый мәсьәләләр соңрак барыбер сүнә, вакыт узу белән үзеннән-үзе юкка чыга. Проблемаларның 50 проценты – без үзебез уйлап тапкан проблемалар. Бу инде исбатланган.

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин арыдым дип, диванда кырын ятып тора...

– Өйдә тик яткан хатыннар турында сүз барса – бер нәрсә. Ә иең дә эшләсә – икенче мәсьәлә. Берәү дә тимер түгел. Аннан проблема ясарга кирәкми. Һәрхәлдә, җылытып алырга өйдә һәрвакыт нәрсәдер бар. Әгәр бу хәл еш кабатлана икән: «Башың авыртмыйдыр бит?» – диярга мөмкин. Димәк, хатын-кыз синнән нәрсә өчендер үч ала... Соң кайтырга туры килгән чаклар бар. «Мин яттым инде», – ди ул. Соңаруыма ачуы килгәне шуннан аңлашыла. Чәй куеп, әзер ризыкны җылытып ашый алам, билгеле. Ашамаска да булдырам. Бу очракта үчне кем ала – белеп булмый. «Нәрсә булды, дөнья җимерелгәнме әллә?» – дим андый чакта. Шулай уза... Кыз бала һәрвакыт, телиме-юкмы, әнисен кабатлый. Өйләнер алдыннан булачак әби-бабаңның үзара мөнәсәбәтләренә карап, нәтиҗә ясый белергә генә кирәк. Нурфиянең эти-әнисе бик матур яшәде. Әби бабайны инсульттан соң 24 ел тәрбияләде. Андый чир белән исә биш-алты елдан китеп баралар. Бабай аңа бик рәхмәтле иде. «Үзем исән булганда атагызны берегездән дә каратмыйм. Ул минем этиләрне өйле, сыерлы иткән кеше», – диде әби. Сугыштан соңгы еллар була. Бабай – фронтовик. Йорт салырга бүрәнә кайтарып аудара. Әмма аннары: «Без әле яшь, үз тормышыбызны корырга өлгерербез, башта синең эти-әниеңә йорт салабыз», – ди. Сыерны да башта аларга алып бирә. Бабай шундый кеше иде. Нибары 4 класс белемле, әмма фикер сөрешe буенча академиклардан калышмый. «Уку акыл бирми шул...» – дия иде ул. Өстәлгә салфеткасыз утырмады. Шулай күнеккән. Бу этикет аңа ничек салынган, кайдан сеңгән, белмим. Шәһәр йорты белән торалар иде алар. Без йокы бүлмәсендә булсак, шакымыйча кермәделәр. Икесе дә гап-гади авыл балалары югыйсә!

13 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Нурфия – математик, аның логикасы миңа карагандa яхшырак эшли. Бүләкнең дә кирәген сайлый белә. Әле бер-ике көн элек кенә ишек тоткасының шөребе бушаган иде. Шуны борып куйыйм дип, отверткалар наборы чыгардым. Очрашып йөргән чакта ук 23 февральгә бүләк иткән иде ул аны миңа... Ә үзем аңа беркайчан өй өчен дә булсын дип, бүләк алмыйм. Хатын-кыз үзе генә тотардай бүләк сайлыйм. Күбрәк бизәнү әйберләре алырга тырышам.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru

Яңа ел табынына – бытбылдык



Бытбылдыктан нидер әзерләр өчен ауга чыгып китәргә кирәкми хәзер. Аны үрчетеп сатучылар арткannan-арта бара. Бу нәзберек йорт кошын үстерү шактый четерекле булса да, итен, йомыркасын яратып кулланучылар бик күп. Без дә Яңа ел табыны өчен үзгә ризык эзләгәндә, тутырган бытбылдык рецептына тукталдык. Аны безгә «Татарстан–Яңа гасыр» каналының «Манзара» тапшыруы хәбәрчесе, уңганбулган Ләйсән ХӨСНУЛЛИНА әзерләде.

Кирәк

- 2-3 бытбылдык;
- 1 яшел алма;
- каражимеш;
- куе каймак;
- 7 бытбылдык йомыркасы;
- тоз, борыч,
- бизәр өчен петрушка, укроп, анар.



Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Чистартылган бытбылдыкларны юып алабыз.
■ Йомыркаларны аерым бер савытка ватып, каймак белән туглыйбыз, чама белән тоз салабыз.
■ Каймак белән йомырка кушылмасын шприцка җыеп, бытбылдыкның муен өлешеннән тире белән ит арасына агызабыз (тутырабыз).
■ Алманы турап, караҗимешнең төшен алып, бытбылдык эченә тутырабыз.
■ Тутырылган бытбылдыкларны кайнап торган суга салып, 20 минут тирәсе пешерәбез.
■ Бу затлы ризыкны гадәттә гарнир белән бирәләр. Ит янына куяр өчен ярып кына бәрәңге пешерергә булдык.
■ Бытбылдыкларны кайнаган судан алып, утка чыдам савытка пешкән бәрәңге белән бергә тезәбез һәм духовкага куябыз. Духовкада бәрәңге кетердәп кыза, бытбылдыкларыбызның өске ягы аллана
■ 15-20 минуттан духовкадан алып, бытбылдык белән бәрәңгене бәйрәмчә бизәп, табынга бирәбез.

БЫТБЫЛДЫК ИТЕНЕҢ ҺӘМ ЙОМЫРКАСЫНЫҢ ШИФАСЫ

Бытбылдыкның ите – диетик ризык булып санала. Ул саруны кайнатмый, мае юк. Йомыркасының сихәте турында японнар күптән аңлаган, алар аны мәктәп укучыларына һәр иртә-кич эчерәләр икән. Тавыкныкы белән чагыштырганда, бытбылдыкларныкында сальмонеллез беркайчан да булмый. Баланың акыл үсешенә, хәтерен яхшыртуга, нерв һәм иммун системасын ныгытуга да ярдәме зур. Бигрәк тә баланың буе үсмәгәндә бытбылдык йомыркасы алыштыргысыз, дип язалар. Олы яшьтәге кешеләргә кандагы артык холестеринны чыгарыр өчен аның итен ашарга киңәш итәләр. Яман шеш белән авыручылар, гастрит, ашказаны җәрәхәте, бронхит, азканлылык, астма, туберкулез, кан басымы уйнаудан, йөрәк авыруларыннан интегүчеләр өчен алыштыргысыз ризык. Ул диатездан интеккән балаларга да бик файдалы. Бытбылдык йомыркасында B_1 һәм B_2 витаминнары тавыкныкыннан — ике, калий, тимер һәм башка микроэлементлар биш тапкырга күбрәк. Бытбылдык йомыркасының кабыгы кешенең сөяк составына охшаш. Ул анемия, рахиттан да шифалы.





Рәхим ит, Яңа ел!

Һе-һе-һей! Чыршылар киенгән, өебез бизәлгән, мандарин исләре таралган, корицалы чәйләр ясалган, бүләкләр барланган һәм... бераз арылган. Ел ахыры бит, ни дисәк тә! Калган эшләрне тәмамларга, нәтиҗәләр ясарга, бурычларны кайтарырга, быелгы вәгъдәләрне үтәргә, хисапларны тапшырырга бик аз вакыт калып бара. Әле тагын яңа хыяллар, өметләр белән тулы Яңа елны дөрес итеп каршы алырга да әзерләнәсе бар! Тычкан елына әзерләнергә, әйдәгез, үзебез булышабыз! Бу елны «Сөембикә» киңәшләре белән башлап карагыз әле!



Узган елны озатабыз

Яңа елны тыныч күңел белән каршы алыр өчен, иске елны дөрес итеп озатып җибәрергә кирәк. Моның өчен: бурычларны кайтарып бетерергә, онытылган вәгъдәләрне үтәргә тырышыгыз. Көндәлек ачуларны онытып, аларны узган елда калдырырга кирәк. Үзегез үпкәләткән кеше булса, шалтыратып, араларны җайларга тырышыгыз яки гафу сорагыз. Өегезне тәртипкә китерегез. Яңа ел алдыннан сабы төшкән, кителгән, ватылган әйберләрне ташларга кирәк. Бәйрәм алды көннәрендә дә тәмләп ашарга киңәш ителә. Иң тәмле ризыкларны Яңа ел табынына гына куярга димәгән. Яңа елны яхшы кәеф белән каршылау мөһим!

Нәрсә бүләк итәргә?

Тычкан юмартлыкны ярата. Тик файдасыз бүләкләр эзләргә кирәкми. Ялтыравык сувенирлар эзләгәнче өйдә кулланып була торган әйберләр карау яхшы: бокаллар, матур чынаяк, эскәтер, хуш исле сабын... Бүләкләрне үз кулларыгыз белән ясасагыз, тагын да әйбәтрәк булыр! Быел бүләкләргә бер яңа мода да өстәлгән әле: матур тартмага салынган сыр яки сыр формасында ясалган әйберләр. Ялгыш кына мәче рәсеме төшкәнен сайлый күрмәгез!



Табынга нәрсә куярга?

Тычкан елы килә дигәч, сыр турында уйлап куйдыгызмы? Әйе, сыр Яңа ел табынында берничә төрле һәм мул булырга тиеш. Чикләвекләр, яшелчә, җиләк-җимеш булуын да яратыр Тычкан, камыр ризыкларын да хуплар. Икенче аш итеп дөге, карабодай, ясмык әзерләсәгез әйбәт булыр. Хәтта табынга кечкенә бер савытка бодай салып куярга кирәк, диючеләр дә бар. Яңа, матур табак-савытны, өстәлнең матур итеп бизәлгән булуын ярата икән быелгы Тычкан. Ел хуҗасы – өй җанлы. Шуңа күрә һәр ризыкның өйдә пешерелүе мөһим, ди! Өстәлгә матурлык өчен кечкенә чыршы уенчыклары, төрле яңа ел бизәкләре, чыршы күркәләре куярга да була. Тычкан елында кызыл төсне мөмкин кадәр аз кулланырга киңәш итәләр. Шуны да белеп торыйк: дөрес итеп әзерләнгән өстәл уңыш, байлык һәм гаилә бәхетен тартып китерергә сәләтле.

Яңа ел төнендә...

Курантлар сукканда берне генә түгел, якты теләкләрне күбрәк теләргә тырышыгыз! Хыяллар чынга ашсын өчен, аларны матур картина итеп күз алдына китерегез! Сәгать унике тулганда чак кына булса да тәрәзәне ачып алырга – иске елны чыгарып җибәрергә, Яңа елны изге теләкләр теләп өйгә кертергә кирәк. Тычканнарга гаделлек өчен көрәш, көчле характер, үз дигәнен итү хас. 2020 – кәбисә елы да. Әмма шикләнеп карарга кирәкми. Быел гаилә кору, гаиләне ишәйтү өчен бик уңышлы ел дип исәпләнә. Ак – чисталык, ихласлык, якты хыяллар төсе булып санала. Уңай юллар белән максатына ирешергә телүчеләргә уңыш киләчәк. Финанс мәсьәләсендә дә уңышлы ел булыр дип көтелә, чөнки Тычкан һәрвакыт арттырырга, ишәйтергә ярата торган җәнлек. Елның икенче яртысында зур үзгәрешләр, көтелмәгән борылышлар булырга мөмкин. Артык борчуларга бирелмәс өчен, гаиләгез белән берләшегез, Тычканнар бит беркайчан да ялгыз яшәми! Тычкан – гади генә билге түгел. Ул хәйләкәр дә, усал хәтерле дә була белә, вакыйгалар агышын үзенә уңайлы якка борып куярга да сәләтле. Шуңа күрә ел буе уяу булырга туры килер!

Нәрсә киярга?

Яңа елны һәркем үзенә уңайлы киемдә каршы алырга тиеш. Купшыланырга телисез икән, рәхим итегез, кибетләрдә сайлау мөмкинлеге бик зур. Кием төсенә генә игътибарлы булыгыз. Быелгы төсләр: аксыл, соры, көмешсу. Тычкан яратмаганы: кызылның барлык төсмерләре, фуксия төсе. Елны ничек тә яңа киемнән каршы алырга диләр. Яңа аксессуар булса да алып куегыз.

Өйне бизәү

Яңа ел – иң якыннар, әти-әни, гаилә белән уздырыла торган кадерле бәйрәм булып санала. Быел да Яңа елны шулай каршы алырга планлаштырыгыз. Өйне декабрь урталарында ук бизи башласагыз була. Балалар да кушылсын! Гирлянда, кулдан киселгән кар бөртекләре, чыршы уенчыклары, киптергән әфлисун кисәкләре... Бәйрәмгә әзерлек чоры бәйрәмнең үзенә караганда да күңеллерәк була! Чыршы турында да истән чыгармагыз! Аны хәзер ничек кенә бизәмиләр! Пыяла уенчыклар гына түгел, атлас бантлар, озын муенсалар, агачтан ясалган бизәкләр... Тычкан – запас җыя торган җан иясе, бернәрсәне дә әрәм-шәрәм итми. Шуңа күрә алдагы елда байлык килсен дисәгез, чыршыга фольгадан тимер акча рәвешендәге уенчык ясап эләргә дә онытмагыз!



Фото: www.pixabay.com

Язылһәм 5 смартфонның берсен от!

Бүләкләр 2020 елның 19 февралендә уйнатылачак



2019 елның 30 декабренә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең кимендә өч басмасына — **ЯЗЫЛ 1**

Язылу квитанцияләренә «Акция» билгесен куеп, копияләрен (телефон номерын язарга онытмагыз!) 420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур. 2 нче йорт яисә podpiska@tatmedia.ru адресына — **ҖИБӘР 2**

Биш смартфонның берсен, юрган һәм башка бүләкләр — **ОТ 3**





Акциянең үткәрелү вакыты, бүләкләр һәм аларны алу тәртибе турында тулырак tatmedia.ru сайтында. Акциянең үткәрелү вакыты 1.11.2019−30.03.2020. Гаризалар 2020 елның 20 гыйнварына кадәр кабул ителә. Оештыручы – «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+

Кучкар. Кызыклы вакыйгалар вәгъдә итә торган ел. Күбрәк үз тормышыгызга, шәхси эшләрегезгә игътибар бирергә кирәк булыр. Ялгыз Кучкарлар яңа елда насыйп ярларын очратып куяр.

Үгезбозау. Иҗади кешеләр өчен уңышлы ел. Бернигә карамыйча, үз-үзегезне җиңеп, каршыга зур максатлар куеп үз юлыгыздан барсагыз – зур уңышларга ирешә торган ел булачак бу.

Игезәкләр. Яңа елда һәрнәрсә җиңеллек белән киләчәк. Башлаган эшләрегезне бу елда эшләп бетерергә тырышыгыз. Эшегездә тырыш хезмәтегезнең уңай нәтиҗәләре өчен зур мактауларга да ия булырсыз.

Кысла. Шәхси тормышта да, карьерада да күтәрелү көтә. Булдыра алмаганны да эшләргә тырышыгыз! Сәламәтлек турында да онытып җибәрмәгез, йөрәк-кан тамырларын тикшертеп торыгыз.

Арыслан. Тормышта күңелле вакыйгалар күп булыр. Яңа кичерешләр, яңа эмоцияләр елы бу. Җаваплылык, дисциплина турында истә тотыгыз. Күптәнге хыялларның бер-бер артлы чынга ашуы да зур тырышлыклар нәтиҗәсе булачак.

Сөмбелә. Йолдызлар сезгә ашыгудан туктарга киңәш итә. Имиджны үзгәртергә, ремонт ясарга, чит илгә барып кайтырга – тормышта кискен үзгәрешләр ясау хуплана. Финанс мәсьәләсендә бар да әйбәт.

Бизмән. Узган ел катлаулы булды, яңа елда җиңеллек, тынычлык килер, наһаять. Интуициягә таянып эш йөртегез. Иң якын кешегез сорауларга җавап табарга булышыр, аның киңәшләренә дә колак салырга онытмагыз.

Чаян. Фикерегездә нык торырга. Максатка ирешер өчен күп көч сорый торган ел. Якыннарыгыз белән уртак тел табып яшәргә тырышыгыз. Мәхәббәт өлкәсендә йөрәгегезне тыңласагыз – ялгышмассыз.

Укчы. Эчке ягымлылык белән һәртөрле эшләрне хәл итә беләсез. Бу сыйфат яңа елда да булышыр. Иң мөһиме – үз-үзегез белән уртак тел таба белегез. Финанс мәсьәләсендә уңыш килер.

Кәҗәмөгез. Яңа ел сезне ныклыкта сынар. Тормышыгызда үзгәрешләр булуы мөмкин. Яңа юнәлештә белем алуыгыз да ихтимал. Бу ел якты эмоцияләр белән истә калачак. Ни генә булса да, бәхет кошы сезнең кулда булыр!

Сукояр. Укуда һәм бизнес өлкәсендә яңа уңышларга әзер булыгыз. Яраткан кешегез белән икәү генә сәяхәткә чыгып китүегез бар. Комарлы гадәтләрдән ераграк торыгыз, бер башласагыз, туктау авыр булачак.

Балык. Иң кадерле хыялыгызны чынга ашырыр вакыт җитте! Уйларыгыз кайда – энергиягез шунда булыр. Максатларга ирешү юлын сайлаганда берәү дә кыерсытылмасын. Тормышның финанс ягын кайгыртыгыз.

ХЫЯЛЛАРНЫҢ ЧЫНГА АШУЫ...

Бер ир-ат бәхетле тормыш турында хыялланган. Яхшы өем, чибәр хатыным, күп акчам булса, мин җир йөзендәге иң бәхетле кеше булыр идем дип уйлаган.

Бервакыт аның юлына Тылсымчы очраган.

Уйларыңны ишеттем, – дигән Тылсымчы. – Мин сиңа ярдәм итәргә әзер. Әйт, ни телисең, шуны чынга ашырам!

Ир бик шатланган моңа, үзенең бәхетенә үзе ышанмый икән хәтта.

– Чынлап та бөтен теләгемне чынга ашыра аласыңмы? Ә алмашка миннән ни телисең? – дип сораган ул.

Тылсымчы, миңа берни кирәк түгел, дигән.

– Бик яхшы! – дип куанган ир. – Миңа зур, яхшы йорт, ашарга әзерли белә торган чибәр хатын кирәк. Һәм һәрвакыт бик күп акчам булуын телим.

– Ярар, – дигән Тылсымчы. – Иртәгә иртән торган җиреңә барысы да булыр, ә хәзер тынычлап йокла.

Чыннан да, икенче көнне иртән ир зур, затлы өйдә уяна, каршында елмаеп чибәр хатыны басып тора, иртәнге ашка чакыра. Барысы да ул теләгәнчә, ул хыялланганча! Банкта аның исеменә исәп-хисап счеты да ачылган, күпме генә акча туздырса да, байлыгы тулыланып кына тора икән.

Көн артыннан – көн, ай артыннан ай үтә, ирнең тормышы һаман шулай бай, җитеш икән. Ул инде тормышында берни үзгәрмәгәнгә борчыла башлый, бертөрлелектән кәефе төшә. Үзе теләгән бәхетнең әле һаман табылмаганын аңлап, янәдән Тылсымчыны чакырта.

– Бөтен әйберем дә бар, ләкин боларның берсе дә миңа шатлык китерми, – дип зарлана аңа ир.

– Мин синең теләкләреңне чынга ашырдым. Бәхетеңә ләззәтләнеп яшә! – ди Тылсымчы.

– Зур өемдә мин – ялгыз: чибәр хатыным шатландырмый, байлыгым канәгатьләндерми. Ни өчен шулай? Җавап бир, Тылсымчы?!

– Син миннән өй сорадың, әмма өйдәге җылы мөнәсәбәтне сорамадың! Чибәр хатын сорадың, ләкин мәхәббәт һәм аңлашып яшәү серен сорамадың! Акча теләдең, ләкин байлыкның рәхәтен тоеп яшәү бәхетен сорамадың! – дип җавап кайтара Тылсымчы.

– Рәхмәт! – ди ир шатланып. – Үземнең хатамны аңладым, мин боларның барысын да телим!

– Әгәр аңлагансың икән, бик әйбәт, калганы үзеңнән тора инде, – ди дә Тылсымчы, күз ачып йомганчы юкка чыга.

* * *

Могҗизаларга тормышта һәрвакыт урын табыла, бары тик аны тормышка кертергә әзер булырга гына кирәк.

Олег Рой (1965, язучы).

Бәхеткә ирешүгә теләкләрнең артык күплеге һәм аларның бөтенесен канәгатьләндерергә теләү комачаулый.

Артур Граф (1848–1913, итальян язучысы).

Кеше үз тормышын үзе бизәргә тиеш. Дөнья – матур, якты. Тик шул матурлык, шул яктылык белән файдалана белергә кирәк.

Кәрим Тинчурин (1887–1938, драматург).

зирәк кешедән зирәк сүз

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Раилә ХӘЯЛИЕВА әзерләде.

ТААРУГА – ТАУ ЧӘЧӘГЕ

Иң элек мине остаханәнең ТААРУГА (фин-угыр телендә – тау чәчәге) дигән исеме үзенә җәлеп итте. Аннары – киемнәре, хуҗасының үз эшен генә түгел, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне һәм, әлбәттә, кешеләрне яратуы. Әнә шундый сыйфатларга ия булган кеше генә хатын-кызларның һәркайсын бизәрлек киемнәр уйлап таба ала. Үлчәмнәр, буй озынлыклары, комплекцияләр, җәмгыятьтә тоткан урын – берсе дә мөһим түгел бу очракта. Беренче чиратта син – хатын-кыз! Татьяна Ефремова – әнә шуны шул кагыйдәне яхшы белгән осталарның берсе.

Мода дөньясында инде бөтенесе яулап алынган кебек, ләкин безгә һәрвакыт нидер җитми. Һаман күбрәк, матуррак булсын. Вакытында тукталып, артка әйләнеп карый белгән ханымнар да бар, әлбәттә. Әйе, нәкъ менә артка! Мода тенденцияләрен күзәтеп баручылар дөньяда бөтен әйбер циклда икәнен белә бит. Яңа тенденцияләр, мода коллекцияләре дә – онытылган кичәге матурлык лабаса.

ТААРУГА киемнәре сыйфаты, бәяләре, сайлап алучылары күплеге һәм, әлбәттә, матурлыгы белән үзенә җәлеп итә. Һәрвакыт һәм һәр җирдә арзанлы да, модалы да, табигый дә булган киемнәрдән йөри дә алмыйсың әле. Ә брендлар авторы Татьяна Ефремова менә шуңа ирешкән! Ачык күңелле, игътибарлы, тамчы да тәкәбберлек юк аңарда, талантлы, тырыш... Мөгаен, шул сыйфатлары белән үзенә тартып торадыр ул. Балачак, һәр ике яктан да әби-бабаларының күплеге аңа күп нәрсә биргән: белемен дә, күнекмәләрен дә, осталыгын да... Тегәргә, чигәргә, челтәрләр бәйләргә өйрәнгән. 90 нчы елларда теккән киемнәрен базарда саткан, 2000 нче еллар башында, тәвәккәлләп, үз эшен ачып җибәргән һәм уңышларга ирешкән: Россия мода индустриясендә ул лаеклы урында.

Бүген Татьяна модельләре – этно һәм пред-а-порте классына караган киемнәр. Прованс стиленең модалы тенденцияләре Урал халыкларының традицион мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән, алар фин-угор мотивлары белән кушылып китә. Төрле тукымаларны аралаштырып теккән күлмәкләр әбиләребезнекен хәтерләтә. Ул күлмәкләрне юганнар да кигәннәр: тузмаган да, сыпылмаган да. Текстильнең сыйфаты яхшы булган. Минем алда гына кызлар әниләренә дип тә, намаз укыганда, ашка барганда кияргә дип тә күлмәкләр сатып алдылар.

Вак чәчәкле штапель күлмәкләр берничә сезон инде тренд саналды, киләсе елда да популяр булачак алар. Күлмәкләрдәге флористик орнаментлар лидерлык позициясен ала. Югары сыйфатлы твидтан, трикотаж йоннан тегелгән пальто, камзол, жилетлар кемгә дә ошарлык. Акча алу белән ТААРУГАга чыгып чаптым. Үземә, энигә, кызыма киемнәр сатып алдым. Балалар өчен генә коллекцияләр юк иде. Тиздән алары да булыр, Татьяна коллекциясендә текстиль уенчыклар бар инде. Шат күңелле Кыш бабай, төлке-куяннар, 3 яшьлек сабый гәүдәле гаҗәеп курчаклар... Кечкенә балалары булганнар белә инде: уенчыклар бик кыйбат тора! Ә йомшак текстиль уенчыклар ватылмый да, искерми дә. Еллар узган, яшь барган саен тынычка, җылыга, рәхәткә ихтыяҗ арта. Үзегезне шушы халәттә тоясыгыз килсә, ТААРУГАга килегез. Зифа буй-сынлы, шәмдәй төз гәүдәле ханымнар ТААРУГА күлмәкләреннән тагын да сылурак күренә.

Рәмзия КАШАПОВА

Модель: К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисты Резеда Сәлахова.



мастерская Тааруга

Кибетнең адресы: Казан шәһәре, Бауман ур., 51/50 нче йорт, ГУМ.

www.taaruga.com/o-kompanii-taaruga

ok.ru/taaruga

instagram.com/taarugashop

vk.com/taaruga

РЕКЛАМА

2020







АПРЕЛЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

МАЙ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

ИЮНЬ

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	

ОКТЯБРЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	31
Я	4	11	18	25	

НОЯБРЬ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

ДЕКАБРЬ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	31
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

Рәссам Гайшә РАХМАНКУЛОВАның бу эшләрен «Ренессанс» антиквар салонында алырга мөмкин. Казан шәһәре, Бауман урамы, 44 нче йорт, «Родина» мәдәни-күңел ачу үзәге, 1 нче кат.





ALEXANDER BOGDANOV

Казань, «SUVAR PLAZA», 1-й этаж
тел: 8 (843) 267 17 37
alexanderbogdanov.com

РЕКЛАМА

